ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ISSN 0130-2418

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

№ 3 (350)
МАРТ 2021



ӘДӘБИЯТТА ХАТЫН-КЫЗ СҮЗЕ

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина, vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров, sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары: Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире: Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре: Олеся Бондаревская, Ольга Туманская, Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Илдус Заһидуллин, Ксения Сёмина, Ландыш Фәезова
Фотографлар: Александр Ефремов, Лилиана Вәлитова
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Олег Бурилов
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыкта: язучы Гүзәл Яхина. Александр Ефремов фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1977 елда Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 450 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: Е-640
Басарга кул куелды: 09.03.2021
Басмадан чыкты: 15.03.2021
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе: Миләүшә Байрашева, milyaushanb@tatmedia.com
Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе: Алсу Троицкая, alsu_1970@list.ru
тел.: (843) 222-09-79
Коммерция директоры: Юлия Фәсәхова, 89272483384_pr@mail.ru
тел.: (843) 222-09-76, +7-9272-483-384

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4800 данә

Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

«ТАТАРСТАН»НЫҢ 101 НЧЕ ЯЗЫ

«Татарстан» журналы йөз ел инде яз каршылый. Язлар төрле була. Ачлы-туклы да, салкын да, сугышлы да, җиңүле дә... Ташулары белән басып киткәне дә, кышкы бураннарына уралганы да, чәчәк бакчаларының хуш исе белән исерткәне дә, җылы җилләре белән җылытканы да, күз күрмәгән чирләре белән куркытканы да бар аның... Яз шундый инде ул – үзсүзле, җилле, алмашынучан. Шул ук вакытта көтеп алынган, яраткан ел фасылы. Ул биек кар көртләренә җиңел генә килеп куна да аларны күңелле гөрләвекләргә әйләндерә, шәрә агачларга орынуы була – тегеләре шунда ук яшел күлмәккә төренә. Ир-егетләребез, яз исен тоюга, шигырь белән генә сөйли башлый. Кайчак шигырь юллары рифмага туры килеп бетмәсә дә, хикмәт анда түгел, ә темада – ул, әлбәттә, мәхәббәт турында.

Ил буйлап 101 нче яз атлый: табигать җанлана, кар астыннан беренче чәчәк-үләннәр борын төртә, ир-егетләр рифма белән сөйли, ә мәчеләр җырлый башлый. Якынлашып килүче яз белән сезне, татарстанлылар! 2021 елның язы имин-бәрәкәтле булсын!

Язны көтүче редакциягез

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы: «ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла
Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **942 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

100 яшь «Татарстан» журналына

Татарстанның 100 җәүһәре
бары тик Татарстанда

Корыч «Дуслык»

Дөньядагы иң эре «Дуслык» магистраль нефтьүткәргече үз юлын Татарстанда башлый. «Калейкино» нефть куу станциясендә куелган мемориаль элмә тактада болай дип язылган: «1964 елның 4 ноябрендә шушы урыннан татар нефте тынычлык һәм дуслык хакына үзенең юлын башлады». Шунысы кызыклы: «Дуслык» юлын Куйбышев өлкәсеннән башланачак дип билгеләгән булалар. Әмма ул төбәктә кирәк кадәрле күләмдә чимал табылмый. Һәм Татар нефтьүткәргеч идарәсе башлыгы В. Стрижков кара алтынны экспортка чыгара торган нефтьүткәргеч торбаларын Татарстаннан башларга тәкъдим итә.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

4. Бәхетле киләчәккә таба
Гайдар форумында футурологлар нәрсә турында сөйләште

10. Ноль зур плюс булганда
«Калдыкларсыз» яшәү рәвешенең файдасы нәрсәдә

14. Бик җилле идея
Яңадан торгызылган энергия чыганаклары кайчан эшләп китәчәк

18. Россия чынбарлыгы оазислары
Тормыш сыйфаты рейтингын кайсы төбәкләр җитәкли

20. Татарстан территорияләре: чагыштырабыз
Район һәм шәһәр округлары рейтингы нәрсәне күрсәтте

игелекле эшләр

24. Хатын-кызларыбыз
Республика язмышында гүзәл затларыбызның роле турында

28. Мәхәббәт саннарда һәм процентларда
Хатын-кызлар турындагы статистика ни сөйли

32. Гомер бүләк итүчеләр
Республика балалар клиник хастаханәсеннән репортаж

50. Һөнәрле хур булмас
Атланмайны кайда атлыйлар

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
protatarstan.ru

мәңгелек кыйммәтләр

56. Тел... Мари Элга илтә
Татарстаннан читтәге татарлар ничек яши

64. Кышның иң гүзәл мизгелләре
«Татарстан» журналы призы өчен кем көрәште

70. Онытылмас исемнәр
Шәфыйка Котдусова: «Сөеп һәм сөекле булып яшәдем»

76. «Сәмәркандка эшелон». Тагын бер бестселлермы?
Гүзәл Яхинаның яңа романы нәрсә турында

79. Тарихи сәхифәләр
Йосыф Акчура: татар тарихындагы эзе

82. Татар авыллары
Кәгазь башмаклы авыл кайда урнашкан

88. «Татарстан» журналының тугыз гомере
Күргәзмәнең сәяхәте ни өчен Базарлы Матактан башланды

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

21.02

Рөстәм МИҢНЕХАНОВ, Татарстан Республикасы Президенты, – Халыкара туган телләр көне уңаеннан татарстанлыларга мөрәҗәгатендә:

– Кешеләр Җир шарының төрле почмакларында аралаша, сөйләшә һәм яза торган күпсанлы телләр – һәр халыкның дөнья цивилизациясе барышында ирешкән мәдәни казанышы. Нәкъ менә туган телебез милли үзаңыбызның нигезен билгеле һәм буыннан буынга ана сөте белән тапшырыла торган уникаль мәдәни кодыбызны формалаштыра.

11.02

Дамир ФӘТТАХОВ, ТР яшьләр эшләре министры, – «Штаб» креатив индустрияләр резиденциясендә узган «Иҗтимагый-сәяси институтларның кризисы» дискуссияләр сессиясендә:

– Яшьләрнең үз фикерен әйтергә мөмкинлеге булырга тиеш. Кешеләргә үзара аңлашыр һәм сөйләшер өчен мәйданчыклар күбрәк булган саен, тулаем җәмгыятьтә проблемалар азрак булачагына ышанам. Бик күп кыенлыклар кешеләрнең үзара аңлаша алмавы нәтиҗәсендә килеп чыга. Бу бит үзе бер сәнгать, күнекмә...

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР



18.02

Юрий КУКЛАЧЁВ, Мәскәүнең Мәчеләр театры җитәкчесе, Россиянең халык артисты, – Татарстанның Мәскәүдәге Тулы вәкаләтле вәкиллеге каршындагы медиаклуб утырышында:

– Татарстан үсешен игътибар белән күзәтеп барам, Казанны бик яратам. Күптән түгел Иннополиста булып кайттым, бик ошады. Әгәр дә анда булмагансыз икән, барып күрегез. Андый шәһәрләр бөтен Россия буйлап булырга тиеш! Иннополис сезнең республикада кешеләр һәм алар өчен уңайлылыклар тудыру турында уйлауларын күрсәтеп тора.

акыллы гамәлләр/

Акыллы гамәлләр

Мәңгелек кыйммәтләр

Игелекле эшләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Футурологлар киләчәгебезне НИНДИ итеп күрә

«Калдыкларсыз» тормышның файдасы НӘРСӘДӘ

Иң яхшы яшәү урыннары КАЙДА

Татарстан районнары бер-берсеннән НӘРСӘ белән аерыла

БӘХЕТЛЕ КИЛӘЧӘККӘ ТАБА

Автор: Ольга Туманская

Ихтимал, футурологлар түгәрәк өстәле быелгы Гайдар форумының иң мавыктыргыч мәйданчыгы булгандыр. Алар безнең киләчәкне ничек күзаллый? Татарстан экспертларын да җәлеп итеп, без бәхәскә кушылырга карар кылдык.

Иллюстрацияләр ачык чыганаклардан алынды

N ЕЛЛАРДАН СОҢ

…2031 ел иртәсе. Михаилның көче дә, энергиясе дә ташып тора. Хәер, бүген генә түгел, кичә дә, бер атна элек тә шулай иде… Яңа йокы гаджеты үзен тулысынча аклады – хәзер ялның сыйфаты аның күпме вакытка сузылуына бәйле түгел.

Нәрсә белән тамак ялгарга икән? Иртәнге ашны сайлау мөмкинлеге артык зур булганга күрә генә, шактый катлаулы мәсьәлә бу. «Бүген, мөгаен, сөмбаш, авокадо һәм песто соусы белән бутерброд ашармын», – дип хәл итә ир-ат һәм кухнядагы принтер төймәсенә баса. Бер минуттан соң инде сыйланырга да була. Шул арада шәхси редакторы Елизавета иң кирәклесен генә сайлап, туплап куйган яңалыклар, аналитика һәм өйрәтү контенты материалларына күз йөртеп чыгарга өлгерә…

– Әгәр элегрәк без, киләчәк – нинди дер технологик сингулярлык, кешедән күпкә акыллырак машиналар патшалыгы, дип расласак, хәзер исә сәламәтлек, гомер озынлыгы һәм кешегә уңайлылык тудыру белән бәйле проект һәм бизнеслар өметлерәк кебек тоела. Инде бүген үк әлеге үзәккә кешене куя торган икътисадка юнәлтелгән тренд тизләнде, – дип, үзенең киләчәкне позитив күзаллавы белән уртаклаша «Русские инвестиции» Компанияләр төркеме директорлар советы рәисе Кирилл Игнатьев.

«Томаннан футурологлар көче белән чыгу» дискуссиясе Гайдар форумында үтте һәм фән вә IT-бизнесның төрле өлкәләреннән танылган белгечләрне үзенә җыйды. Секциянең беренче минутларында ук безгә якын киләчәкне – бу гасырның 20 нче елларын – күрсәтәләр: кулдагы кәгазь акчадан тулысынча баш тарту, космостагы туристлык, электр транспортының бензин двигательле автомобильләрне җиңүе… Хәер, боларны күзаллау өчен футуролог булырга да кирәкми. Форумда сөйләнгән иң мөһим нәрсә, мөгаен, менә шулдыр: яңа технологияләр продукт һәм хезмәтләрнең шәхсиләшүенә китерәчәк.

Казан федераль университеты Мәгълүмати технологияләр һәм интеллектуаль системалар институты директоры Михаил Абрамский да бу мәсьәләдә Мәскәү экспертлары белән килешә. Алдарак без нәкъ менә шул Михаилның киләчәгенә бераз күз салып алдык та инде. Әлеге фантастиканың тәүге күренешләрен без инде бүген үк күзәтә алабыз. Мәсәлән, соңгы елларда популярлашкан акыллы беләзекләр безне тиз йокы фазасында уятырга сәләтле. Ә Казан галимнәренең ризык принтингы өлкәсендәге казанышлары, ихтимал, бик тиздән безнең өчен кулинариянең яңа эрасын ачачак.

Азык-төлек технологияләре өчен 3D-принтерда ясалма ит бастыру проекты – Прецизион һәм регенератив медицина фәнни-клиник үзәге директоры, КФУның Фундаменталь медицина һәм биология институты генетика кафедрасы профессоры Альберт Ризванов лабораториясе казанышларыннан берсе. Галимнәр кеше әгъзаларын 3D-бастыру нечкәлекләре белән шөгыльләнә, ясалма ит булдыру – әлеге юнәлешнең нинди дер бер «спин-офф» тармагыдыр сыман.

– Әлеге киләчәк технологиясе традицион фермаларны составы буенча «тере» иткә тәңгәл булган ит җитештерә торган биотехнология фабрикалары белән алыштыру мөмкинлеген бирәчәк. Алай гына да түгел, стейкны теләсә кайда – планетаның һәм Галәмнең теләсә кайсы ноктасында, мәсәлән, Марста, бастырып булачак, – дип сөйли Альберт Ризванов.

…Михаил кулындагы акыллы беләзек тибрәнә. «Посылка китерелде!» – дип хәбәр итә ул. Ир-ат балконга чыга – бер сәгать элек кенә заказ бирелгән кешелеккә кия торган костюм инде почта әрҗәсендә ята…

– Товарны өйгә китереп бирү сервислары киләчәктә тагын да камилләшәчәк, ихтимал, бу эшкә дроннар җәлеп ителер, – дип фаразлый Михаил Абрамский. – Әгәр дә без тагын бер 20 елдан соңгы киләчәк хакында сөйлибез икән, шәһәрдә пилотсыз технологияләр үсеше һәм очу аппаратларын транспорт сыйфатында файдалану чынбарлыкка әйләнергә мөмкин. Эшкә үзебезнең балконнан ук түгел, әмма, мәсәлән, түбәдә махсус җайланган мәйданчыклардан очып китүебез бик ихтимал. Пилотсыз технологияләр ярдәмендә кешене һава буйлап күчерергә сәләтле киләчәк аэротаксиларының гади аналоглары инде бүген үк Сколковода сынала.

Сүз уңаенда, тизйөрешле пилотсыз транспорт… авылны җанландырырга мөмкинлек бирә алачак. Зур үзәкләргә тиз арада барып җитү проблемасы хәл ителгәч, авыл халкының шәһәргә күченүе дә туктарга мөмкин. Авылда да эш табу җиңеләячәк: телисең икән – югары технологияле авыл хуҗалыгы җитештерүендә хезмәт куй, теләмәсәң – үзеңнең яшелчә бакчасындагы шезлонгта яткан килеш чит ил корпорациясендә эшлә.

– Пандемия безгә, элемтә сыйфатын идеалга җиткереп, медиабагланышларны камилләштерү зарурлыгын күрсәтте, – ди Михаил. – Кешенең голографик проекцияләре пәйда булуны фаразлыйм – «Йолдыз сугышлары» яки «Марвел» фантастик фильмнарындагы кебек. Чөнки дистанткa күчкәннән соң, безнең күбебез тере аралашу җитмәвенә төшенде. Голография исә аны имитацияләү мөмкинлеген бирәчәк.

Сүз дә юк, виртуаль дөньялар пәйда булу кешелек үсеше өчен яңа вектор сызачак. Күп кенә һөнәрләр киләчәктә үзгәрәчәк, дип саный Абрамский. Ихтимал, аларның кайберләре чынбарлыктан уйдырма дөньяга да күчәр. Мәсәлән, виртуаль дөньялар архитекторы яки шундагы иминлек буенча белгечләр. Ә бәлки, уен процессы барышында алынган виртуаль җәрәхәтләрне дәваларга тиешле табиб та пәйда булыр?

Цифрлы технологияләр һәм элемтә алгарышы гамәлдәге һөнәрләргә дә үзгәрешләр кертәчәк. Якын киләчәктә кранчы югарыда, төзелеш краны башында утырмастыр инде мөгаен, ул җирдән, махсус кәнәфидән генә идарә итәчәк. Билгеле, техника белән ерактан торып идарә итү төзелеш тармагына гына кагылмаячак, инде бүген үк КФУда авыл хуҗалыгына бәйле шуңа охшаш проектлар бар. Бик тиздән пилотсыз аппаратлар уңыш турында кайгыртуны үз өстенә алачак. Мәсәлән, корткычларга каршы чараларны билгеле бер секторларга гына сиптерәчәк. Гомумән, Николай һәм киберавыл турындагы көлкеле ролик – хәзер инде әллә ни фантастика да түгел, дип саный Михаил. Һәм цифрлаштыру авылны юкка чыгармаячак, ә бәлки, киресенчә, аны торгызыр, дигән өмет тә бар.

ГАЛИМНӘР СУПЕРБАКТЕРИЯЛӘРГӘ КАРШЫ

Бүгенге эпидемияләр – киләчәктәге зур афәтләрнең бик кечкенә бер авазы гына. Әгәр чираттагы вирус кеше уйлап тапкан булса, аның күләме, таралуы искиткеч куркыныч булырга мөмкин. Форумда «Наука

“

– Әгәр элегрәк без, киләчәк – ниндидер технологик сингулярлык, кешедән күпкә акыллырак машиналар патшалыгы, дип расласак, хәзер исә сәламәтлек, гомер озынлыгы һәм кешегә уңайлылык тудыру белән бәйле проект һәм бизнеслар өметләрәк кебек тоела.

за продление жизни» фонды вице-президенты Алексей Турчин шундый пессимистик фараз белән чыкты.

Казан вирусологы Альберт Ризванов та биотеррорчылыкны якын киләчәктәге иң зур куркынычка саный.

– Кешелекнең мондый хәлгә әлегәчә тарымавы гаҗәп. Биокорал җитештерү буенча лаборатория төзү әллә ни катлаулы бурычка саналмый. Бу сиңа искиткеч күп капиталь кертемнәр таләп иткән һәм космостан күренеп торган атом-төш программасы түгел. Ә инде биологик материал, мәсәлән, качаклар лагере, кул сузымында гына икән, бигрәк тә... Дәүләт сугышлары дәрәҗәсендә моның белән беркем дә шөгыльләнмәячәк – чөнки күпләп юк итү коралы «читләрне» дә, «үзеңнекеләрне» дә аямаячак. Ә менә террорчылык карашыннан – безнең барыбызга да чын куркыныч бу.

Яңа эпидемия хәвефе вируска гына да бәйле булмаска мөмкин. Галимнәр чаң суга – соңгы берничә дистә елда антибиотиклар белән дәвалау өлкәсендә бернинди яңалык та уйлап табылмаган, ә менә мондый препаратларны контрольсез куллану бернигә дә бирешми торган үтергеч супербактерияләр барлыкка китергән. Алар инде кешеләрне үтерә дә башлаган.

– Бүгенге медицина аларга каршы бөтенләй көчсез, – ди Альберт Ризванов. – Дару чаралары эзләп табуда химиянең куәте бетеп килә – фармкомпанияләр кытлык кичерә башлаган инде. Медицинада яңа гасыр – биологик препаратлар гасырына аяк басабыз. Һәм бу – бүген нәкъ менә без шөгыльләнә торган нәрсә.

Бүген ренессанс кичерә торган фаготерапия антибиотикларга нәтиҗәле алмаш була ала. Теләсә нинди бактериягә аны юк итәрлек, «ачкыч – йозак» принцибы буенча эшли торган фаг табарга мөмкин булачак. Һәрвакытта да универсаль фаг ясау мөмкин булмаганга, конкрет пациент өчен фагларны персональләштереп табу системасын эшләргә туры килмәгәе.

Киләчәк фармакологиясенең икенче юнәлеше – геннар терапиясе, ул авыру сәбәбенә төгәл тәэсир итә торган ген препаратлары ясау мөмкинлеген бирәчәк. Бу да КФУның Фундаменталь медицина һәм биология институты галимнәре тикшеренүләренең берсе булып тора.

– Инде хәзер үк җирдә сирәк очрый торган, орфан чирләр бик күп, алар өчен дәвалау ысуллары бөтенләй юк, – ди Альберт Ризванов. – Алар якынча 10 меңләп, шуңа тулаем алганда мондый пациентлар күп, тик алар барысы бергә бердәм базар түгел, бәлки бик «чуар» төркемне тәшкил итә. Фармкомпанияләр алар өчен традицион дару препаратлары ясарга атлыгып тормый – базар бик кечкенә, әмма геннар терапиясе ысуллары үсеше пациентларның кечкенә төркемнәре өчен дә шәхси диярлек дарулар булдыру мөмкинлеген бирә.

Вакциналар белән дә шул ук хәл. Сүз уңаенда, Илон Маск инде РНК синтезаторы уйлап тапкан – ул РНК-вакциналар булдыру һәм аларны кыска вакыт эчендә теләсә кайда – хәтта Марстамы йә Төньяк полюстамы да – «бастыру» мөмкинлеге бирә, моның өчен мәгълүмат пакетын интернет буенча шунда җибәрү

дә җитә. Мондый җайланмалар ярдәмендә генетик препаратларны заказ буенча синтезлап булачак. Һәм бу өлкәдә бер Маск кына эшләми, бары аның исеме телдән төшмәгәнгә генә әлеге яңалык тиз арада бөтен җиһанга тарала. Ә менә Альберт Ризванов җитәкчелегендәге лаборатория турында, мәсәлән, бик аз кешегә генә мәгълүм.

– Инде хәзер үк без геннар терапиясе нигезендә Covid-19 га каршы вакцинаның ике прототибын булдырдык. Шулай ук сирәк орфан чирләрне дәвалау өчен дару препаратларының дүрт прототибын эшләдек. Шулардан берсе – умырткалык мускуллары атрофиясен (СМА) дәвалауда файдаланыла торган, дөньядагы иң кыйбатлы «Золгенсма» даруының биоаналогы. Россиядә бер инъекция бәясе 150 миллион сумга тәңгәл. Безгә шул үзебез уйлап тапкан дарубызны теркәтер өчен, биш ампулага бәрабәр сумма кирәк. Ә тагын ун «ампула» бәясенә без илебездәге шундый бөтен пациентларны диярлек (якынча мең кеше) сихәтләндерә алыр идек.

Асылда, элегрәк озак еллар буе тикшеренү таләп ителгән нәрсәләрне бүген галимнәр берничә ай эчендә эшли ала. Һәм бүгенге эпидемия моны раслады. Әмма, шуның белән бергә, «үлемсезлек таблеткасы» һаман да чын фантастика булып кала бирә – хәтта футурологларның иң кыю фаразларында да. Ихтимал, аларны 60 тан 120 яшькә кадәрге хәзерге коридор кысаларында гомер озынлыгын ничек арттыру мәсьәләсе күбрәк борчыйдыр. РФА профессоры, Ми һәм нейротехнологияләр федераль үзәге җитәкчесе Всеволод Белоусов форумда бөтен дөнья галимнәрен нәкъ шуны өйрәнүгә өндәде. Казанда исә бу эш күптән бара инде.

Казан федераль университеты белән Казан дәүләт медицина университетының уртак проекты кысаларында галимнәр Альцгеймер чире гены яки амиотрофик склероз гены кертелгән хайваннарның гомерен геннар терапиясе ярдәмендә шактый озайтуга ирешкән. Сәламәт хайваннарның гомер озынлыгы нибары 2 ел булган очракта – 2-3 айга! Казанлылар шулай итеп нейродегенератив авырулардан саклану юлын эзли, әлеге чирләр, кешелекнең гомер озынлыгы артуга бәйле рәвештә, гасырның иң куркыныч медицина афәте булыр, дип фаразлана бит.

– Кеше тәне 40 ел эшләүгә исәпләнгән, шуннан артканы – «гарантиядән соңгы чор», – ди Альберт Ризванов. – Җитмәсә, медицина казанышлары табигый сайланышны юкка чыгара язган, димәк, популяция генофондында мутацияләр тупланачак. Шунлыктан без югары үсештәге медицинадан башка чыннан да яши алмаячакбыз инде.

Югары технологияле киләчәк турында хыялланып, Альберт Ризванов көнкүреш диагностикасына исәп тота – ул чакта хәзерге кебек пульс, кан басымы һәм сатурацияне үлчи торган гына түгел, бәлки УЗИ һәм ЭКГ ясый, тире төсен һәм күзнең челтәр катламындагы үзгәрешләрне билгели, үпкәдәге хырылдауны ишетә һәм кул калтыравын сизә торган мобиль гаджетлар киң таралачак... Канның яки бәвелнең микроскопик тамчысы буенча әлеге җайланма бихисап биохимик параметрларны ачыклаячак һәм аларны, телемедицина ярдәмендә, дәвалаучы табибка җибәрәчәк. Ә аннары – әгәр бүгенге көнегелгән чал чәчле медицина профессоры урынына сезгә диагнозны ясалма интеллект куйса да, гаҗәпләнмәгез.

Әмма бу, әлбәттә инде, табиб һөнәре тулысынча юкка чыгар һәм без роботлар кушуы буенча өйдә генә дәваланачакбыз, дигән сүз түгел әле. Шәхсиләштерелгән медицина – инде галимнәр бүген үк кулланa торган вектор – ихтимал, әлеге тармак барачак төп юлга әйләнер. Кеше геномының шифры ул туганчы – яралгының ана канында йөрүче күзәнәкләре буенча ук ачыкланачак. Яки бөтенләй ЭКО этабында, эмбрионны күчереп утырткaнчы ук беленәчәк. Генетик паспорт һәр конкрет кешенең авыруларын кисәтү һәм дәвалау нигезенә әйләнәчәк. Яраксызга чыккан, тузган әгъзаларны яңалары белән алыштыру да гадәти хәл булачак.

> “
>
> Асылда, элегрәк озак еллар буе тикшеренү таләп ителгән нәрсәләрне бүген галимнәр берничә ай эчендә эшли ала. Һәм бүгенге эпидемия моны раслады. Әмма, шуның белән бергә, «үлемсезлек таблеткасы» һаман да чын фантастика булып кала бирә – хәтта футурологларның иң кыю фаразларында да.

Инде бүген үк донор әгъзалары кытлыгы проблемасын төрле ысуллар белән хәл итәргә маташалар – кеше генетик материалын дуңгызга кертеп үстерүдән башлап донор күзәнәкләре реципиент күзәнәкләренә алыштырыла торган мәет материалын файдалануга кадәр. Казан галимнәре исә әгъзаларны 3D-принтерда бастыру юнәлешен өйрәнергә карар кылган.

– Әлбәттә, безнең нәтиҗәләр камиллектән ерак әле. Әмма инде бүген үк галимнәр ниндидер бик гади әйберләрне бастыра ала. Мәсәлән, тиренең идеаль булмаган эквивалентын. Яисә, безнең Мәскәүдәге коллегаларыбыз кебек, тычканның калкансыман бизен, – ди Альберт Ризванов.

ГУГЛ КЫЯФӘТЛЕ ТЕРМИНАТОР

Суыткычта катып беткән брокколидан башка нәрсә булмаганда нишләргә? Пицца китертергә!

– «У Рената» пиццериясеме?

– Сез Гугл-пиццага шалтыратасыз. Безнең кампания «У Рената» пиццериясен сатып алды.

– Мин заказ бирергә әзер...

– Сезгә гадәттәгечәме? Шалтыратулар тарихыннан күренгәнчә, сез соңгы 12 тапкырда зур «Дүрт сыр» пиццасын китерткәнсез. Безнең цуккини һәм томатлы вегетариан пиццасын авыз итәсегез килмиме?

– Юк, рәхмәт.

– Чынлапмы?

– Әйе. Яшелчәләрне куралмыйм...

– Аңлыйм, әмма ул сезгә файдалы булыр иде – сезнең холестерин микъдары 246 мг тәшкил итә, ә 200 дән артыграк күрсәткеч, белүегезчә, йөрәк-кан тамырлары авырулары ихтималына ишарәли...

Кыска метражлы «Брокколи» фильмын төшерүчеләр нибары өч минутка киләчәкнең төп дилеммасын

сыйдыра алган – уңайлылык һәрвакытта да яхшымы соң? Фильм бер үк вакытта көлкеле дә, куркыныч та булып чыккан. Пицца китертергә шалтыратып кына да, герой үзенең шәхси тормышының тулы картинасына ия була – сәламәтлеге турындагы белешмәдән алып банктагы акча күчерүләре һәм салым түләүләре хакында тулы мәгълүмат ала.

Бу мәсьәләдә форум экспертлары да уртак фикергә килә алмады.

– Шәхсиләшләштерү бөтен тармакларга үтеп керде. Алгоритмнарның безгә ризык һәм кием сайларга, такси чакыртуга булышуына без инде күнектек... Тиздән шәхсиләштерелгән укыту тренды барлыкка киләчәк. Сез кешеләрнең ни өчен укуларын ташлавы хакында уйланганыгыз бармы? Чөнки кайсыдыр бер моментта аларның мотивациясе бетә. Яңа тренд әлеге проблеманы да хәл итәчәк, – дип тасвирлый цифрлы киләчәкнең сөенечле перспективаларын форумда катнашучылардан берсе, Skyeng онлайн-мәктәбенең идарәче партнеры Александр Ларьяновский.

– Шәхси мәгълүматлар мәсьәләсе якындагы ун елның иң зур проблемасы булачак, – дип каршы төшә аңа МДУның икътисад факультеты деканы Александр Аузан. – Инде бүген үк әлеге мәсьәләгә дөньяда караш төрле. Шәхси мәгълүматлар булмаган, бөтен информация дәүләтнеке саналган Кытайдан башлап, шәхси мәгълүматлары махсус дәүләт институтлары тарафыннан якланган Европага кадәр. Киләчәктә бу ничек булачак? Цифрлы тоталитарлык пәйда булу ихтималы әлеге сорауга бирелгән җавапка бәйле, ул чакта гомер озынлыгын 10–30 елга озайту фактын кешелек срокны озайту, дип кабул итәчәк.

«Брокколи» авторлары күрсәткән галәмәтне Алексей Турчин цифрлы үлемсезлек, дип атый. Ул аңарда куркыныч күрә. Әмма мөмкинлекләр дә артачак.

– Үземнең моделемне төзеп, корпорацияләр минем үз-үземне тотышымны билгели. Мөгаен, бу цифрлы үлемсезлекнең бик үк яхшы формасы түгелдер. Әмма башкасы да бар. Инде бүген үк табигый телдәге текстны генерацияләү системасы пәйда булды, ул теләсә нинди теманы дәвам итә һәм аны урыны-урыны белән кеше дәрәҗәсендә диярлек ача. Якындагы берничә елда көчле ясалма интеллект барлыкка киләчәк. Ә аның белән бергә – инде үлгән кешеләрне «аларның» яңа текстларында һәм әсәрләрендә тулылынча тергезү мөмкинлеге.

Нәрсә килеп чыга инде – кичә без ясалма интеллектны киборг Терминатор кыяфәтендә, бүген – «явыз Гугл» сыйфатында күз алдына китерсәк, киләчәктә исә, мәсәлән, «терелгән» Толстой белән аралашачакбызмы? Ясалма интеллектка безне буйсындыру тагын да җиңеләячәк алайса?

– Мин бу мәсьәләдә радикаль позициядә торам, – ди Михаил Абрамский. – Мин ясалма интеллектны табигый интеллектка тиңләүгә каршы. Бу мөстәкыйль карарлар кабул итүче шәхес түгел, бәлки кеше гамәлләрен интеллектуаль модельләштерү һәм автоматлаштыру омтылышы гына. Еш кына бу кеше өчен бик җиңел, ә компьютер өчен бик катлаулы булып чыга. Мәсәлән, эт фотосын мәченекеннән ничек аерырга? Нейрон челтәрне моңа өйрәтеп карагыз әле! Шунлыктан мин ясалма интеллектның безне кол итәчәгенә бик ышанмыйм. Ә менә шундый технологияләргә ия булган кешеләр чыннан да куркыныч тудырырга мөмкин...

Бүген КФУ ның Мәгълүмати технологияләр һәм интеллектуаль системалар институты робо-

тотехника лабораториясендә эзләү-коткару роботлары өчен алгоритмнар эшләнә, дип сөйли Михаил. Алар инде үзләре маршрут сыза ала, һәм киләчәктә мондый коткаручылардан файдалануның, мәсәлән, химик йогышлану зонасына кешене җибәрүгә караганда нәтиҗәлерәк һәм куркынычсызрак булуы бәхәссез.

Әмма коткаручы һөнәре роботлар кешеләрдән өстенрәк булган бердәнбер һөнәр түгел. Мәсәлән, форумда катнашучылар «электрон» табиблар пәйда булуны фаразлый, бу очракта кешегә диагнозны ясалма интеллект куячак. Ә кеше нишләргә тиеш? Инде хәзер үк, уңышка ирешер өчен, без «күп бурычлылык режимында эшләргә» һәм «стресска чыдам булырга» тиеш. Безнең арада көндәшлек көчәерме, һәм анда роботлар да катнаша башлармы? Ә бәлки, ниһаять, әлеге якты – һәм цифрлы! – киләчәккә килеп җиткәч, без, тигез хокуклылыкка һәм демократиягә төрелеп, ниһаять нирванага ирешербез?!

– Теләсә никадәр хыялланырга була, әмма көндәшлек киләчәктә һаман көчәячәк. Чын тормышта нигезендә кеше хокуклары һәм ирекле яткан «Европа юлы» юк. Бу, мөгаен, ирешмәслек идеалдыр. Социаль гаделлек хакында инде XIX гасыр башында ук күп язылган, әмма аны гамәлгә ашыру катлаулы шул, – дип нәтиҗә ясый социология фәннәре докторы, КФУның Социаль-фәлсәфә фәннәре институты директорының фән буенча урынбасары Мария Ефлова.

Галим әйтүенчә, цифрлаштыру чорында җәмгыятьнең катламнарга бүленүе артачак кына. Алда безне рәхәтлек түгел, ә яңа һөнәри батырлыклар көтә. Кеше тагын да катлаулырак күнекмәләргә һәм компетенцияләргә ия булырга тиеш. Бу үзгә – интеллектуаль – элита пәйда булуга һәм җәмгыятьнең кабат катламнарга аерылуына китерәчәк.

– Безнең кулланучылык мөмкинлекләребез беркайчан да тигез булмаячак, – ди Мария Ефлова. – Әмма вакыйгаларның яхшы сценарие дә бар – икътисадый һәм сәяси элиталар түбәнге катламнарга үзләренең потенциалын арттыру һәм гамәлгә ашыру өчен максималь уңайлы шартлар тудырган очрак бу.

Бүген әле безнең сайлау хокукыбыз бар – цифрлы иммигрант яки, киресенчә, цифрлы абориген, аутсайдер, диссидентка әйләнү. Әмма Мария Ефлова «цифрадан» азат булу мөмкинлегенә ышанмый. Без бит үзебез сөенә-сөенә әлеге «цифрлы коллык» кочагына атылабыз – чөнки ризык китертүгә һәм такси чакыртуга онлайн заказ бирү, самолет һәм театрга билетларны онлайн сатып алу үзебез өчен уңайлы. Ә хәвефләр... Әлбәттә, алар бар.

– Цифрлы чорда безне дәүләтләр генә түгел, төрле базар агентлары да контрольдә тотачак. Һәм моны тыныч кабул итәргә кирәк – артка юл юк.

МӨГАЕН, ИҢ МӨҺИМЕДЕР

Рэй Бредбериның мәгълүм гыйбарәсен хәтерлисезме: «Кешелеккә космоска күтәрелү мөмкинлеген бирделәр, тик ул сыра эчеп, сериал карап кына ятарга тели»? Мөгаен, ул бүген аеруча актуальдер...

– Минем марттан бирле ашамлык кибетендә булганым юк, – дип дискуссиядә катнашучыларга серен ача Александр Ларьяновский. – Бөтен нәрсәне өйгә китереп бирәләр. Бүген без үз вакытыбызның 3–5 сәгатен нәтиҗәсез сарыф итүдән азат. Әмма карап карыйк, без аны ничек үткәрәбез соң? Үз белемебезне арттыругамы, бу дөньяны бераз яхшыртугамы, әллә инде (и Раббым, кичер) тагын берничә сериал карауга тотабызмы?

ЧҮП ЧИЛӘГЕН «СҮТҮ»

Автор: Ольга Туманская

Гүзәл Макарова янына без кунакка... чүптә казынырга килдек. Ул үзе дә каршы түгел! Zero waste («Ноль калдык») фәлсәфәсе кагыйдәләренә таянып яшәүче экоактивистка чүп калдыкларыннан башка яши белү рецепты белән уртаклашырга һәрвакыт әзер.

– Соңгы тапкыр чүп чиләген без Яңа елга кадәр чыгардык, аңа кадәр – җәен, – дия-дия, Гүзәл чүп чиләген ала. – Монда эшкәртүгә тапшырып яисә компостка салып булмый торган калдыклар ята. Уртача алганда, безнең өч кешелек гаиләдән аена 200 грамм тирәсе шундый чүп җыела.

Мондый яшәү рәвеше Гүзәл тормышына 2016 елда килеп керә. Кыз «Пластик йөз елдан артык таркала» дигән язуга игътибар итә. «Нәрсә инде бу, мин күптән бакыйлыкка күчкән булам, мин кулланган пластик савытлар әле чүплектә җыелып ятачакмы?!» – дип уйлап куйдым ул чакта, ди.

– Мин өемә якында гына пластик савытларны утильләштерү контейнерлары эзли башладым һәм социаль челтәрләрдә «ЭкоЛогично Казань» төркеменә тап булдым. Анда барлык пунктларның да картасы эленгән иде, чүп-чарлар һәм Zero waste турында тагын әллә никадәр файдалы мәгълүмат та таптым. Активистларга кушылдым, ә аннан соң «Икенчел чимал һәм кием-салым кабул итүнең мобиль пункты» дигән үз проектымны эшләп конкурска тапшырдым, оттым да.

ПРИНЦИПКА БАРУ

Гүзәлнең фатирында чүп-чарны аерып тутырыр өчен савытлар да күренми. Пластик, картон һәм пыяла кайда саклана икән соң? Һәм менә хуҗабикә кухня гарнитурының ишекләрен ачып җибәрә.

– Бездә барысы да бик җыйнак, – ди ул. – Күз алдына китерегез, менә бу кечкенә генә картон өеменә соктан бушаган тугыз кап тыгызлап таслап куелган! Эшкәртүгә тапшырырмын, дим. Ә менә йомшак пластиктан торган бу пакет ярма, макарон капларыннан, чәй һәм конфет кәгазьләреннән тора...

Без чүп-чарны аермыйча ташлаган вакытта үзебез «эшләп чыгарган» калдыкларның күләменә бәя бирә алмыйбыз, дип саный Гүзәл. Һәм инде өйдә аера һәм бер җиргә җыя башлауга чүп-чар бәласенең масштабына шакката башлыйбыз. Күз алдына гына китерегез, уртача алганда бер кеше елына якынча 400–500 килограмм чүп ташлый.

Zero waste принципларын 5R-пирамида рәвешендә күз алдына китерү җайлырак. Иң югары һәм төп баскыч – refuse, ягъни артыгыннан баш тарту. Бераз түбәнрәк – reduce (кыскарт), алга таба-reuse (кабат куллан). Һәм бары тик әлеге баскычларда әлегеп тора алмасаң гына – recycle (эшкәрт) һәм rot (компостка сал).

– Башта чүп-чарны аерырга тырышасың, җыясың, эшкәртүгә кая тапшырыйм икән, дип баш ватасың, ә аннан соң, Ходаем, бу тартмаларны күпме җыярга, пакетларны күпме юарга була соң дигән фикергә киләсең. Бер сүз белән әйткәндә, иртәме-соңмы сортларга аеру иң мөһиме түгел, дип уйлый башлыйсың. Иң мөһиме – артыгын кулланмау! Җитмәсә, теләсә кайсы продукт тотылган ресурслар һәм «тормышының» барлык стадияләре – җитештерүдән һәм транспортлаудан алып, утильләштерү һәм эшкәртүгә кадәр булган чорларында зарарлы калдыкларны чыгару рәвешендәге тискәре экоэз калдыра.

REFUSE. БАШ ТАРТУГА КИЛДЕК!

– Бигрәк инде, бусы артыграк, дисезме? – дип көлә Гүзәл. – Әлеге кагыйдәне үз тормышыгызның кайбер өлкәләрендә генә булса да кулланып карагыз.

Берничә ел элек ул үз коллегаларына бәйрәмнәрдә файдасыз, кирәге булмаган сувенирлар бүләк итешмәскә тәкъдим итә, аның урынына уртак өстәл

Фото: Александр Ефремов

әзерләргә була бит. Гел вакыт җитми торган җылы аралашу – хәзер традициягә әверелгән.

Шул рәвешле акрынлап, Гүзәл тормышына аек минимализм керә. Бүген берәр нәрсәне сатып алыр алдыннан ул җитди уйлый. Бу әйбер аңа чыннан да кирәкме соң? Бәлки, моңа охшаш әйбере бардыр да? Сатып алган әйбере бер айдан, ярты елдан, бер елдан аңа шундый ук шатлык китерерме?

– Ничектер бервакыт үзе үк фотоларны ясый торган фотокамера рекламасына күзем төште. Кызыгып куйдым. Әмма бераз көтәргә булдым, бер айдан соң шул ук сорауга җавап биреп карармын, дидем. Вакыт үтте, мин фотоаппаратның кирәге юклыгын танырга мәҗбүр булдым. Сүз уңаеннан, теге яисә бу экогадәтне кертеп без еш кына бонуслар алабыз – гаилә бюджеты яисә сәламәтлек өчен файда... Ә кайчак – тегесе дә, бусы да.

Гүзәл кызын тудырырга әзерләнгәндә үк тиздән аның «зеровейст»-тормышында бер тапкыр кулланышлы подгузниклар проблемасы туачагын аңлый. Сүз уңаеннан, планетабызның экологиясе өчен бик зарарлы булган әйбер ул. Әмма аңардан ничек баш тартырга соң? Шулай да юл табыла – сатуда күп тапкыр кулланыла торган подгузниклар пәйда була. Табигый материаллардан тегелгән подгузник бала тәнендә аллергия дә, парник эффектын да тудырмый. Махсус кремнар да, дарулар да кирәкми. Юып куясың, киптерәсең – кидерәсең... Әлбәттә, иязләшергә вакыт таләп итәлә, әмма файдасы бик зур, дип саный Гүзәл. Әйе, нәтиҗәдә ике түгел, өч куянның койрыгын тотасың: җир шарында чүп-чар азая, сабыйның сәламәтлеге өчен файдасы зур, гаилә бюджетына да экономия.

Гүзәл өстәлгә тагын берничә экотабышны тезеп куя. Беренчесе – гигиена әйберләре. Агачтан ясалган кечкенә мамык таяклар, күп тапкыр кулланышлы киҗе-мамык дисклар, аларны, мамыктан гына ясалганнарыннан аермалы буларак, кер машинасында да юарга була, бамбук савытка салынган минераль дезодорант, ул берничә елга җитә, төргәксез, үсемлек майлары катыштырылып ясалган каты шампунь...

Сүз уңаеннан, азык-төлек пленкасын балавызлы тастымал алыштыра, тәмле сулар өчен пластик көпшәләрне – пыяла һәм металлдан эшләнгәннәре, бер тапкыр кулланылышлы бахилаларны – аяк киеме өчен тегелгән чүпрәк тышлыклар. Без күргән барлык бу әйберләр диярлек безнең җирле осталар тарафыннан эшләнгән. Хәер, бу ассортиментны онлайн-кибетләрдә дә табарга мөмкин.

REDUCE. КЫСКАРТУГА КҮЧ

Бүген, дөнья белән маркетинг идарә иткәндә, төргәктән тулысынча баш тарту идеясе – утопиягә тиң. Әмма аны минимумга кадәр кыскарту – хәлдән килерлек эш.

Мөгаен, Гүзәл гаиләсе чүп-чарны киметү эшен гадәттә кибеттә бирелә торган полиэтилен пакетлардан баш тартудан башлагандыр. Иң авыры гаилә башлыгына туры килә – ир супермаркетка чүпрәк сумка тотып йөрүдән шундук баш тарта. Гүзәл сатып алынган полиэтилен пакетны искергәнче йөртергә, ә аннан соң эшкәртергә илтергә тәкъдим итә. Үзең белән яисә машинада тотылган пакет йөртү гадәте шуннан килә. Әлеге проблеманы күпмедер дәрәҗәдә хәл итәргә яңа рюкзак ярдәм итә. Җитмәсә, уңайлы да булып чыга!

Сүз уңаеннан, иң киң таралган экоялгышларның берсе – үзеннән-үзе таркала торган биопакетлар турындагы миф.

Гүзәл берничә экотабышын күрсәтә. Шуларның берсе – үсемлек майлары катыштырылып ясалган каты шампунь...

– Безне мондый пакетларның зарарлы булмавына ышандырырга тырышалар, әмма, ни кызганыч, бу алай түгел, – дип сөйли Гүзәл. – «Гринпис» экспертлары фикеренчә, алар тиз арада микропластикка әверелә, әмма, азык-төлек чылбыры буйлап йөреп, шактый озак таркала. Ә кукуруздан ясалган пакетлар компостка салганда гына зарарсыз матдәләргә бүленә. Чүп-чар өеменә ташлаган очракта алар башка пакетлардан аерылып тормый. Ә чүп-чарны аерып җыю шартларында – тагын да начаррак. Ялгыш уртак өемгә эләгеп, бөтен партияне бозарга мөмкин. Бары тик органик калдыкларны аерып җыйганда гына яхшы булачак. Ләкин бездә органик калдыкларны аерып җыю системасы юк.

Гүзәл үзе пакетлар аркасында берничә мәртәбә мәзәк хәлгә юлыга. Бервакыт сатып алынган әйберләрнең күләмен уйлап бетермәгәнгә күрә, сумкасы тулгач, продуктларның кайберләрен бала арбасының кесәләренә тутырырга мәҗбүр була. Юлда кайтканда сатып алган тавыгын төшереп калдыра, әмма үз принципларына тугры кала. Хәзер инде, тәҗрибәгә таянып, барысын да төгәл планлаштыра.

Үтә күренмәле пакетларны шулай ук минимум куллана. Җиләк-җимеш, яшелчә, яшел тәмләткечләр өчен Гүзәл махсус чүпрәк капчыклар булдырган. Әгәр инде көтмәгәндә сатып алырга туры килә икән, янчыкта һәрвакыт ипи сатып алгандагы пакет йөри. Төргәктә сатылган ипидән калган пакетны «икенче цикл» буйлап җибәрергә була.

Кызганычка каршы, коела-буяла торган продуктларга килгәндә, мондый вариант бөтенләй туры килми дияргә була. Макаронны яисә ярманы үлчәп, килолап алу – бик сирәк. Күпмедер дәрәҗәдә Гүзәл базарда сатучыларга ярдәм итә: сөтне банкага салдыра, ит сатучы тавык итен дә күп мәртәбәләр кулланыла торган зип-лок пакетка салып үлчәп бирә.

– Сүз уңаеннан, Казанда савыт-саба, кер юу матдәләрен үз савытыңа агызып алырга мөмкин булган урыннар бар, – дип аңлата Гүзәл. – Ләкин, табигый ки, төргәк мин игътибар иткән бердәнбер әйбер түгел. Юа торган матдәләрнең һәм гельләрнең, савыт-саба юу машинасы өчен таблеткаларның составларын өйрәнәм, экосертификатларның булу-булмавын тикшерәм. Интернетта матдәләрнең зарарлымы-юкмы икәнлеген тикшерергә булыша торган сервислар бар – ингредиентларны

гына санап чыгарга кирәк. Бер тапкыр тикшерәм, аннан соң гел шуны гына сатып алам. Әлбәттә, табигый матдәләргә өстенлек бирәм. Шул рәвешле мин үз гаиләмнең сәламәтлеген һәм планетаның чисталыгын сакларга үз өлешемне кертәм, зарарлы матдәләрне туфракка чыгарасым килми.

Шул ук сәбәп аркасында Гүзәл касса чеклары санын да минимумга калдырган. Термокәгазьдә зарарлы булган бисфенол А матдәсе бар икән. Табигать өчен генә түгел, үзеңнең сәламәтлегең өчен дә куркыныч ул. Агу тирегә үтеп керсен өчен, берничә секунд җитә. Кайбер кибетләр кәгазь чек урынына электрон чек бирә башлады инде. Банкоматларда да алардан баш тартырга мөмкин. Иң яхшы чүп булмаган чүп бит ул.

REUSE. КАБАТ КУЛЛАН

Гүзәлнең һәр очрак өчен үзенең кызыклы «зеровейст»-тарихы бар. Шуларның берсе бүдәнә йомыркасы, төгәлрәге, йомыркаларны салып сата торган пластик савытлар турында. Аларны икенчел чимал һәм киемсалым кабул итүнең мобиль пунктына өлкән яшьтәге бер ханым алып килә. Маркировкасында мондый савытны эшкәртүгә тапшырып булмый дип язылган. Гүзәл бу турыда әлеге ханымга әйтергә генә җыенганда, вазгыятькә ире кушыла.

– Әгәр син аңа бу турыда әйтәсең икән, ул кәефсезләнәчәк, ихтимал, башка чүп-чарны аерып та җыймас!

Шул рәвешле бу савытлар Гүзәлнең өенә кайта. Бер ел диярлек ул аларны нишләтергә белми, ә аннан соң тота да интернетка игълан бирә. Бераз вакыттан соң аларны бер фермер алып китә.

– Әгәр сезгә ниндидер әйбер кирәкми икән, бу әле аның башкаларга кирәкмәвен аңлатмый, – ди Гүзәл. – Әз генә тырышырга кирәк, яңа хуҗа һичшиксез табылачак. Бәйләнеп бетмәгән свитермы, кирәк саналмаган тасмамы, савыт-саба комплектыннан калган бердәнбер кашыкмы – нәрсә генә булмасын – һәркайсына ия табып була!

Эшкәртүгә җибәргәнче әйберләргә икенче гомер бирү – Zero waste яшәү рәвешендә төп принципларның берсе. Чөнки эшкәртү, беренчел җитештерү буларак, ресурсларны тотуга китерә. Ә «ноль калдык» барлык этапларда да табигатькә сакчыл мөнәсәбәтне күз уңында тота. Менә шуның өчен дә «зеровейст»-тормыш тарафдарлары кирәкмәгән әйберләрне кирәклеләренә алыштырып булган гаражлардагы сатуларны, фримаркетларны хуплый, шулай ук алар үз әйберләрен «яхшы кулларга» тапшыру мөмкинлеге биргән онлайн-форумнарны да яклый. Әле искермәгән, әмма инде бераз туйдырган әйберләрне урнаштыруның тагын бер ысулы бар – Татарстанда шактый күп хәйрия фондлары һәм складлары эшли. Алар әйберләрне кабул итәләр, аннан соң мохтаҗларга тараталар.



Мөгаен, Гүзәл гаиләсе чүп-чарны киметү эшен гадәттә кибеттә бирелә торган полиэтилен пакетлардан баш тартудан башлагандыр.

Кибеттә соңгы тапкыр кайчан кием сатып алганымны хәтерләмим, ди Гүзәл. Бәлки, дүрт ел элек тер, бәлки, аңардан да элгәрәктер. Моның кирәген күрмим, ди ул.

– Минем күлмәгемә карагыз – ул миңа бушка килде. Танышыма кирәкми башлады, ә миңа ошый. Кызым өчен әйберләр дә – проблема түгел. Игълан элеңгән интернет-сервисларның теләсә кайсына күз салыгыз – анда белдерүләр шундый күп, җаның теләгәнне сайлап алырга була.

Хәер, тотылган кием-салым сатып алу яисә танышлар белән савыт-саба, кирәк-яраклар алмашу сезнең өчен экстримның бер төре булып чыкса да, Zero waste яшәү рәвешеннән баш тартырга ашыкмагыз. Гүзәлнең киңәше: иң җиңеленнән башлагыз.

– Безнең тормыш экомифларга төренгән. Шуларның берсе: бер тапкыр кулланылышлы пластик стаканнар – начар, ә кәгазьләре, янәсе, – яхшы. Экотемага тирәнрәк кергән саен, шуны аңлый башлыйсың: яхшы ул – әйберне озак куллану, чөнки бер тапкыр кулланыла торган предметның экологик эзе, нинди генә материалдан эшләнгән булса да, күп тапкырлар сатып алуларга тапкырлана. Ә кәгазь стаканнарны гомумән эшкәртүгә бик сирәк кабул итәләр, чөнки аларда полиэтилен элпә бар. Сезнең мондый стаканны ташлавыгыз, асылда, чүп савытына бер агач кисәге ыргытуга тиң.



– Әйбер сатып ала башлаганчы, аның маркировкасын өйрәнәм, – ди экоактивистка.

Кофены үзегез белән алу сезнең көндәлек гадәтегезгә әверелгәндә нишләргә? Термокружка алу турында уйларга! My Cup, Please җәмгыятенең экоактивистлары сезнең өчен онлайн-карта әзерләгән. Анда яраткан эчемлегегезне үз савытыгызга бер проблемасыз агызып алып була торган урыннар билгеләнгән. Кайберләрендә хәтта экоаңлылык өчен ташламалар да каралган.

RECYCLE. ӨЙРӘН ҺӘМ ХУҖА БУЛ!

– Әйбер сатып ала башлаганчы, аның маркировкасын өйрәнәм, – ди Гүзәл һәм шкафыннан теш пастасыннан калган тюбикны алып күрсәтә. Ул икегә киселгән, юылган – утильгә тапшыру кагыйдәләре шундый. Пычрак, юылмаган икенчел чималны кабул итмиләр.

Сүз уңаеннан, пычракны гына түгел. Пластикның барысын да эшкәртүгә тапшырып булмый – һәм бу яңа гына Zero waste тарафдарлары сафларын арттырганнар өчен күңелсез ачыш. Гомуми ташкыннан «кирәклене» аерып алу – җиңел эш түгел.

– Җиңел юлдан китүне яратам, – дип, үз тәҗрибәсе белән уртаклаша Гүзәл. – Татарстан эшкәртүчеләре 2/4 маркировкасы булган пластик тюбикларны бернинди проблемаларсыз кабул итә, шуңа күрә әлеге саннарны эзлим. Бәхеткә, «кабул итү» ассортименты киңәя бара. Кремнардан бушаган савытлар белән катлаулырак. Аның каравы шампунь һәм гельләрдән бушаган ПЭТ-шешәләр белән җиңел – шәһәрдә аларны утильгә җыя торган челтәр контейнерлар урнаштырылган. Аларның кайберләренә металл банкаларны да ташларга мөмкин.

Чүп-чар белән мондый катлаулылыклар артык мәшәкать кебек тоела. Яратып, бик җиңел сатып алабыз бит. Ә аннан соң боларның барысын да дөрес иттереп утильләштереп кара! Пластикны маркировкалауның дистәләгән билгесе, күп составлы әйберләр һәм чүпрәкләр, тагын әле – батарейкалар, кәгазь һәм пыяла...

– Әгәр аерырга кыен икән, чүп-чарыгызны безнең икенчел чималны һәм кием-салымны кабул итүнең мобиль пунктына алып килегез. Бергәләшеп эшләп карарбыз, – дип тә тәкъдим итә Гүзәл.

Аена бер-ике мәртәбә Гүзәл һәм проектны тормышка ашыручы башка активистлар гадәти пунктларга тапшырып булмый торган икенчел чималны кабул итәләр. Без күнеккән ПЭТ-шешә һәм макулатурадан тыш, аларга теш щеткаларын һәм кырыну әйберләрен, пластик карточкалар һәм пакетларны, майонезлардан калган дой-пакетлар һәм CD-дискларны тапшырырга мөмкин... Боларның кайберләрен без складларда туплыйлар һәм эшкәртү өчен башка шәһәрләргә җибәрәләр.

– Бизнеска бу әлегә файдалы эш түгел, ә безнең өчен идея мөһим – проектыбыз күбрәк агарту юнәлешендә, – дип сөйли Гүзәл. – Зур калада кечкенә генә активистлар төркеменә икенчел чималны җыю реаль эш була алмый, әмма без кешеләргә шуны җиткерәсебез килә: чүп-чар чиләгенә эләккән калдыкларның күп өлешен эшкәртүгә җибәрергә була!

Мобиль пунктның кайчан һәм кайда эшләячәге турында игъланны проектның социаль челтәрләрдәге битләрендә табарга мөмкин. Ул эшләгән вакыт эчендә активистлар тарафыннан 100 тоннадан артык чүп-чар утильләштерелгән.

ROT. ЧҮП-ЧАРДА АКЧА ЭШЛӘРГӘ

Компост өеме безнең Zero waste буенча сәяхәтебезне тәмамлый. Гүзәл азык-төлек калдыкларын компостка сала. Һәм азык-төлекнекен генә түгел – целлюлозадан ясалган савыт-саба юу губкалары да шунда ук китә. Әйе-әйе, без иялләшкән поролоннан аермалы буларак, аннан да компост ясарга була.

Гүзәл үз йорты белән яшәгәнгә, бу яктан үзенә җайлы дип саный, чөнки теләсә кайсы зурлыктагы өемнәрне сакларга була. Бу шул ук кукуруз пакетларын яисә экокафеларда янәсе биологик таркала торган дип бирелә торган чәнечкеләрнең «ныклыгын» сынап карау рәвешендә аңа хәтта экспериментлар ясарга да мөмкинлек бирә,

Хәер, күпкатлы йортларда яшәүчеләр өчен Zero waste шулай ук мөмкин булган яшәү рәвеше. Гүзәлнең фикердәшләре күптән инде азык-төлек калдыкларыннан компост ясап караган. Кечкенә генә агрегат кухня гарнитурының гадәттә чүп чиләге куела торган урында черемә ясау фабрикасын оештырырга булыша. ЭМ-контейнерларда азык-төлек чүп-чары – махсус микроорганизмнар тәэсирендә, ә вермикомпостерларда яңгыр суалчаннары ярдәмендә ферментлаша.

Сөйләгәндә бик матур түгел кебек, ә болай хәтта нәзберек шәһәр кешесе өчен дә начар күренми. Зур булмаган пластик савыт яңгыр суалчаннарын да, тәмсез исләрне дә яшерә. Шундый бер агрегат 3–4 кешелек гаиләгә җитә, дип аңлаттылар миңа.

– Минем гумусны сатар өчен ясый торган танышларым да бар, – дип дәвам итә сүзен Гүзәл. – Игълан аша саталар, танышларына тәкъдим итәләр. Узган елда шундый бизнес-проектын эшләтеп җибәргән ханымны беләм. Кешеләрдән азык-төлек калдыкларын җыя да, эшкәртеп, файдалы ашламага әйләндерә. Казанда үз калдыкларының өчтән берен диярлек компостка әйләндерә торган кафе эшли. Үзләре ясаган гумус-яшел тәмләткечләр үстерү өчен, җәен чәчәк түтәлләрен ашлау өчен кулланыла.

Бер сүз белән әйткәндә, теләге булганнар – мөмкинлекләр, теләге булмаганнар сәбәп эзли.

Гүзәл компостка азык-төлек калдыкларын гына түгел, савыт-саба юу губкаларын да сала. Алар целлюлозадан ясалган.

СҮЗ АХЫРЫНДА

– Кайчандыр мин җәмгыятебезне үзгәртү өчен бары тик 5 процент кеше генә кирәк дигән фикер ишеткән идем, – ди Гүзәл. – Берничә ел элек миңа фрикка караган кебек карыйлар иде. Ә бүген йолдызлар Инстаграмга үзләренең чүп-чарны сортларга аеруларын күрсәткән видеолар эләләр. Безнең җәмгыятьтә Zero waste яшәү рәвеше белән кызыксыну күп мәртәбәләргә артты. Намуссыз җитештерүчеләр үз товарларының тышына тикмәгә генә «Био» дип язып куймыйлар, гәрчә аларда әлеге бионың эзе булмаса да. Барысы да кулланучы өчен бу триггер булганга! Кайчандыр без эре сәүдә кибетләреннән аларда чүп-чар җыю акцияләрен үткәрү өчен рөхсәт сорый идек. Һәм алар баш тарталар иде. Ә бүген алар үзләре шундый тәкъдимнәр белән безне эзләп табалар. Шуңа күрә мин ышанам: тиздән безнең җәмгыятьтә әлеге дә баягы 5 процент кеше пәйда булачак. Безнең рәтләр арта бара. Сез дә кушылыгыз!

«ЯШЕЛ ВАКЫТ»

Автор: Ксения Сёмина

Үзеңнең җил куу генераторың булган бакчаңда куе натураль ромашка нектары эчә-эчә, суүсемнәрдән алынган биоягулыкта йөри торган өр-яңа автомобилеңә сокланып карап яту – татарстанлылар өчен әллә ни ерак вакыт калмаган идиллия.

Иллюстрация ачык чыганаклардан алынды

100 МЕТРДАГЫ ТАБЫШ

– Энергиянең яңартыла торган чыганаклары (ЭЯЧ) үзләштерелмәгән бушлык түгел, ул глобаль, шулай ук җирле энергетика тармакларының тирән үзгәрешенә алып бара торган шактый мөстәкыйль тармак. ЭЯЧ хисабына акрынлап энергетика укладын алыштыру процессы бара, аның елдан-ел көчәюе күзәтелә, – дип сөйли эшкуар, инженер, техник фәннәр кандидаты Азамат Девятов.

Яңартыла торган энергия чыганаклары белән ул берничә ел элек кызыксына башлый. Аның эре нефть эшкәртү предприятиеләренең берсендә эшләгән чагы. Дөнья энергетика һәм нефть агентлыкларының отчетларын карап утырганда, аның игътибарын кайбер илләрдә альтернатив энергетиканың традицион белән көндәшлеккә сәләтлелеге һәм шактый көчле үсешкә ия булуы җәлеп итә. Безнең республиканың инде берничә ел мондый проектларны гамәлгә ашыру мөмкинлеген тикшерүе турында белеп алгач, Девятов «Энергонәтиҗәлелекле технологияләр һәм яңартыла торган энергетика – Татарстан Республикасының яңа үсеш нокталары» дигән темага доклад яза һәм шуның нигезендә монография бастыра. Бу хезмәтен 2017 елда ТР Хөкүмәтенә юллый. Монографияне әзерләгәндә автор укыганнары, өйрәнгәннәре белән шулкадәр илһамлана ки, үзенең брендын булдырырга һәм ЭЯЧ өчен җиһазлар эшләп сата торган компания ачарга уйлый. Һәм ача да. Күптән түгел генә предприятиенең эшли башлавына өч ел булган. Компания үз бренды астында җил куу генераторлары, кояш панельләре һәм коллекторлары ясап, Россиянең барлык төбәкләренә диярлек озата. Җил куу генераторлары һәм кояш панельләре, Девятов сүзләренә караганда, киң кулланучының ихтыяҗын канәгатьләндерә – гади йорт хуҗаларыннан алып, сәнәгать предприятиеләренә кадәр. Аларга сорау үзәкләштерелгән электр белән тәэмин итү булмаган яисә электр уты төрле сәбәпләр аркасында еш сүнә торган урыннарда бигрәк тә зур.

– Татарстанда әлегә яңартыла торган энергия чыганакларына ихтыяҗ зур түгел, әмма без моны үзмаксат итеп куймыйбыз. Якын киләчәктә әлеге төр продукцияне җитештерә торган предприятиебезне үстерү юлы аша республикада икътисад үсешенең яңа ноктасын булдырырга үз өлешебезне кертәбез, – дип аңлата Азамат Девятов. – Яшел энергия генерацияләү – төбәктә яңартыла торган энергия чыганакларын кертү нәтиҗәсенең бер ягы гына. Икенче ягы – җитештерү предприятиеләренең, тиешле инфраструктураның пәйда булуы һәм ЯЭЧ сферасында уникаль интеллектуаль тәҗрибә туплау һәм компетенцияләрне үстерү нәтиҗәсендә гаять көчле мультипликатив эффект булдыру. Бу үз чиратында күпьеллык тырыш хезмәтне таләп итә. Мондый белем һәм тәҗрибәнең РФнең башка субъектларында гына түгел, чит илләрдә дә кирәге чыгарга бик мөмкин.

Шул ук вакытта Татарстанда беренче җил паркларының пәйда булуына күп калмаган. 2019 елда Казан дәүләт энергетика университеты белгечләре республиканың берничә районында җил көчен үлчәү эшенең тәгәлләнүе турында хәбәр иттеләр. Республика территориясендә җил паркларын төзү белән «Роснано», «Росатом», «Фортум», «Энел Россия» кебек илнең ЯЭЧ базарында иң эреләре саналган компанияләр төрле дәрәҗәдә кызыксынуларын күрсәтте.

– Җил куу генераторын кайсы ноктада урнаштырсаң да була, ул энергия эшләп чыгарачак. Эш бары тик моның нинди дәрәҗәдә нәтиҗәле булуына гына бәйле. Без менә шул җайланмаларны урнаштыруның иң кулай урыннарын сайлау өчен төрле үлчәүләр үткәрү белән шөгыльләнәбез, – ди Казан дәүләт энергетика университетының ЯЭЧ кафедрасы мөдире Наил Тимербаев. Аның сүзләренә караганда, «коммерцияле» җил 70 метр һәм аннан да биегрәк урыннарда исә. Татарстанда мондый территорияләр 30 га якын. Сүз әлегә 20–40 җил куу турбинасы урнаштырырлык 7 җил паркы турында бара. Җайланма дөрес итеп урнаштырылган очракта җил паркы операторы берничә елдан челтәргә энергия сатудан файда ала башлаячак. Сүз уңаеннан, «Электроэнергетика турында» Федераль законга 2019 елда кертелгән төзәтмәләр нигезендә, челтәргә энергияне шәхси затлар да сата ала (әгәр җайланма 15 кВт тан да куәтлерәк булмаса). Дөрес, чит илләрдән аермалы буларак, шәхси эшкуар энергияне күмәртәләп сату бәясеннән генә бирә, ә алганда – базар бәясеннән.

2019 елга Россиядә куәте 100 кВт лы җил куу генераторлары урнаштырылган һәм рәсми исәпкә алынган җайланмалар саны буенча лидерлар – Кырым, Чукотка һәм Ульяновск өлкәсе. Татарстанда әлегә ЯЭЧ урыны-урыны белән генә гамәлгә ашырыла, күбрәк эре сәнәгать компанияләре тарафыннан. Әйтик, агымдагы елның гыйнвар ае ахырында «Татнефть» ГАҖ беренче чиратта үтә үзле нефть чыгару объектлары өчен җил энергетикасы җайланмаларын төзү, кече гидроэнергетика һәм җылылыкны тирәнтен утильләштерүне үстерү максатын күздә тоткан проектларны хуплады.

КМТТУ-КХТИның җылылык технологияләре кафедрасында биодизель ягулыгы табуның сынау җайланмасы.

Фото КМТТУ-КАИ матбугат хезмәтеннән алынды

Наил Тимербаев билгеләп үткәнчә, Татарстанда «коммерцияле» җил парклары һичшиксез булачак. Аның фикере буенча, Россиядә 2024–2035 елларга яшел энергетиканы үстерүгә ярдәм итүнең федераль программасына беренче сайлауларда (2021 елда узачак) Татарстанның 1–5 җил паркы катнашачак. Аларны булдыру республиканың «2030 елга кадәрге чорга Татарстан Республикасының ягулык-энергетика комплексын үстерү стратегиясе»ндә дә (соңгы редакциясе – 2019 елның 6 августы) күздә тотыла. ЯЭЧна ярдәм итүнең дәүләт программасы буенча 2024 елга Россиядә 3350 МВт егәрлеккә ия җил генерациясе файдалануга кертеләчәк, шул исәптән Татарстан Республикасы территориясендә 2022 елда 100 МВт (якынча 1 мең гаилә елына шулкадәр энергия тота), диелә документта. Өч иң перспективалы районда 11 ай дәвамында алып барылган үлчәүләр шуны күрсәтә: Спас районында 100 метр биеклектә искән җилнең уртача еллык тизлеге – 7,4 м/с, Кама Тамагында – 7,7 м/с, Балык Бистәсендә – 7,3 м/с. Өч районның суммар энергетик егәре 600 МВт тан артык.

ЯГУЛЫК ТӘХЕТЕНӘ

Стратегиянең яңартыла торган энергия чыганакларына багышланган бүлегендә башка технологияләр дә карала. «Татарстанда билгеләнгән куәтләрнең 15 процент дәрәҗәсендәге (ЯЭЧ куәтләрен тапшыру турындагы килешү конкурсында катнашу өчен, ким дигәндә, 14 процент кирәк. – Авт. иск.) коэффициентлы кояш электростанцияләре төзелеше өчен кояш инсоляцияләренең җитәрлек күләме бар», дип билгеләп үтә авторлар. Әмма документта конкрет проектлар язылмаган. Башка перспективалы альтернатив юнәлешләр буларак, авторлар урман эзерләү калдыкларын кулланып җылылык станцияләре төзүне, тирестән һәм кош-корт тизәгеннән биогаз җитештерүне, органик калдыклар чыгарган газны куллануны, шулай водород кулланып җыела торган энергия эшләүне атыйлар.

Шул ук вакытта Татарстан университетлары республикага «яшел энергиянең» тагын бер чыганагын – биодизельне тәкъдим итә. Әлеге ягулык, үсемлек майларыннан ясалган дизель, дөньяда инде 20 еллап кулланыла. Шул исәптән кайбер илләр аның ярдәмендә энергиянең казылма чыганакларын (ташкүмер, газ) куллану күләмнәрен, димәк, парник газларын да кыскартырга ниятли. Биодизельне төп кулланучылар – Европа, Төньяк Америка, Латин Америкасы һәм Азия-Тын океан регионнары. Ягулык күләмендә биодизельне куллануның мәҗбүри нормасы түбәндәгечә: Парагвайдагы һәм Канададагы 1–2%тан Коста-Рика һәм Һиндстандагы 20%ка кадәр. Россиядә әлегә мондый нормативлар юк, шулай да биоягулык куәте илебез экспертлары һәм фәнни җәмәгатьчелек

тарафыннан актив тикшерелә. Татарстанда биоягулык проектларын нефть тармагы предприятиеләре гамәлгә ашыра. Республика галимнәре әлеге процессларны төрле үсемлекләрнең һәм суүсемнәрнең майларын реакция тирәлеге сыйфатында үтә критик флюидлар технологиясен куллану ярдәмендә оптимальләштерергә тәкъдим итә.

– Гәрчә биоягулык әлегә безнең илгә бик кирәкмәсә дә (нефть һәм газга көндәш әзерләүнең мәгънәсе юк), технологияләрне булдырырга кирәк, – ди КМТТУ-КХТИ ның җылылык техникасының теоретик нигезләре кафедрасы мөдире Фәрит Гомәров.

Әлеге кафедраның төп эш юнәлешләренең берсе – билгеле бер температура һәм басым йогынтысында универсаль диярлек эреткечкә әверелә торган үтә критик флюидлар – этанол, су, углекислый газ һәм башка катнашмаларның үзлекләрен һәм куллану ысулларын өйрәнү. Аларны куллану диапазонын лазер технологияләрен яисә программалаштыру телләрен куллану белән чагыштырып булыр иде. Мондый флюидлар сәнәгать катализаторларын торгызу, нефтьне, тотылган суларны төрле кушылмалардан чистарту, югары төгәллекле корал өчен оптиканы эшкәртүгә киткән чыгымнарны күп тапкырларга киметә. Гади кешегә якынрак юнәлешләрнең берсе – экстрактлар табу. Аптека ромашкасының гадәти спирттагы эремәсендә алтыга якын биологик актив компонент исәпләнә. Ромашка чималының үтә критик флюидлар белән эшкәртү нәтиҗәсендә шундый 16 компонент алырга мөмкин. Һәм спирттагы эремә кирәк булмаячак.

– Биодизельне шулай ук үсемлек майлары липидлары белән спирт арасындагы химик реакция ясап табып була. Нәтиҗәдә майлы кислоталар катнашмасы барлыкка килә, ул биоягулык итеп кулланыла. Әгәр спирт сыйфатында үтә критик метанол кулланабыз икән, реакциядән барлыкка килгән продуктларның чыгышы шактыйга арта, – дип аңлата Фәрит Гомәров. Үтә критик флюидлар ярдәмендә биоягулык табу юлында ике зур киртә тора – Татарстанда әлеге флюидлар өчен сәнәгать күләмендәге генераторның һәм арзан үсемлек чималының булмавы.

Икенче проблеманы хәл итү юнәлешендә КФУның экологик биотехнологияләр һәм биомониторинг лабораториясенең микробиология кафедрасы белгечләре – кафедра доценты Эльвира Җиһаншина һәм аспирант Светлана Булынинина эшли.

– Биоягулыкның иң перспективалы чыганакларының берсе – микросуүсемнәр. Алар, мәсәлән, рапс кебек майлы культуралерга караганда күпкә продуктлырак. Моннан тыш, бу азык-төлек һәм фармакология сәнәгате, шулай ук терлек-туар һәм кошкорт азыгын җитештерү өчен бай чыганак, – дип аңлата Эльвира Җиһаншина. – Сәнәгать күләмендә җитештерү өчен бары тик кайбер штаммнар гына туры килә. Менә шуларны сайлау һәм үстерү белән шөгыльләнәбез дә инде без.

Әмма микросуүсемнәрне үстерү – чыгымлы шөгыль. Шуңа күрә лаборатория белгечләре липидларны алуны максималь дәрәҗәдә файдалы итү максатын куйган. Моның өчен микроорганизмнарны тотылган суларга, шулай ук төрле калдыклар – туклану тирәлегенең арзан аналогларына урнаштырганнар. Монда микросуүсемнәр бик рәхәтләнеп аммоний, нитратларны, фосфатларны, сульфатларны йота һәм чиста су, югары өстәмә кыйммәткә ия пигментлар, липидлар, аксым, биомасса эшләп чыгара.

– Без әле үзебезнең технологияне эре масштабларда сынап карамадык, чөнки сынау урыныбыз юк. Сәнәгать биореакторларында үстерү өчен мәйданчык кирәк. Анда биомассаны эшләп, алга таба күзәнәкләрдән метаболизм продуктлары алып булыр иде. Әлегә без инвесторны эзлибез, – ди Эльвира Җиһаншина. – Безнең гасырга ягулык җитәчәк, тик аны эшләп чыгару әйләнә-тирә мохиткә авырлык китерә. Дөнья җәмәгатьчелегенең экологик һәм икътисадый мәнфәгатьләре инде хәзер үк биоэнергетика өлкәсендә инновацияле тикшеренүләр үткәрергә кирәклеген таләп итә. Бу яктан караганда, биодизель җитештерү – бик күпне вәгъдә итүче технология.

P.S Еш кына җәмгыять беренче мәлләрдә киләчәк технологияләренә шикләнеп карый, ә инде аннан соң бернәрсәне дә үзгәртә алмый. «Ни өчен сез Фултон уйлап тапкан әйбернең дөньяны үзгәртә алуы турында шулай соң кисәттегез? Әгәр мин моны иртәрәк белгән булсам! Ул бит миңа килгән иде!» – легенда буенча Наполеон Бонапарт инженер Роберт Фултон уйлап тапкан пароходның Гудзон суларын ерып йөргәнен ишеткәч, шулай дип шакката. Берничә ел элек император Александр I Россия империясендә пароход эшен үстерү монополиясен Фултонга тапшырган була...

КФУның экологик биотехнологияләр һәм биомониторинг лабораториясенең микробиология кафедрасында микросуүсемнәр үстерү.

Фото КФУ матбугат хезмәтеннән алынды

РОССИЯДӘ ИҢ ЯХШЫ ЯШӘҮ УРЫННАРЫ

Тормыш сыйфаты буенча РФ төбәкләре рейтингы – 2020*

Рейтинг турында

Рейтингны төзегәндә экспертлар төбәкләрдәге тормыш сыйфатының төп юнәлешләрен билгели торган 70 күрсәткечкә анализ ясады. Керемнәр күләме, халыкның мәшгульлеге һәм хезмәт базары торышы, халыкның торак шартлары, яшәү куркынычсызлыгы, демографик вазгыять, экологик һәм климат шартлары, халыкның сәламәтлеге һәм белем дәрәҗәсе, социаль инфраструктура объектлары белән тәэмин ителгәнлек, икътисадый үсеш дәрәҗәсе, кече бизнес үсеше дәрәҗәсе, территорияләрнең үзләштерелгәнлеге һәм транспорт инфраструктурасы үсеше.

Лидерлар

Мәскәү, Санкт-Петербург һәм Мәскәү өлкәсе рейтингта күп еллар дәвамында беренче урыннарда баралар. Алар тоткан урын әле озак еллар дәвамында башка төбәкләр өчен буй җитмәслек булып кала бирәчәк, дип саный экспертлар. Беренче өчлекнең төп өстенлекләре – инфраструктураның киң үсеше, икътисадның, социаль сфераның алга таба да җитди үсеш куәте шәйләнгән югары үсеш дәрәҗәсе. Беренче унлыкка кергән башка төбәкләр дә икътисадый үсешнең югары дәрәҗәсен күрсәтә:

82,164 балл

МӘСКӘҮ

80,634 балл

САНКТ-ПЕТЕРБУРГ

76,068 балл

МӘСКӘҮ ӨЛКӘСЕ

66,624 балл



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

64,769 балл

БЕЛГОРОД ӨЛКӘСЕ

63,714 балл



КРАСНОДАР КРАЕ

1 2 3 4 5 6

Татарстан, Белгород өлкәсе, Краснодар крае, Ленинград һәм Воронеж өлкәләре, Ханты-Манси автоном округы – Югра, Калининград өлкәсе. Гомумән алганда аларның өлешенә федерация субъектларында булдырылган суммар тулаем төбәк продуктының, ваклап сату әйләнешенең, төп капиталга инвестицияләрнең 40%ка якыны туры килә. Сүз уңаеннан, 2019 елгы рейтинг белән чагыштырганда, беренче унлыкның составы үзгәрешсез калган.

Мөһим

Җыелма рейтинг баллы бер ел эчендә 40 төбәктә арткан, ә 45ендә кимегән. Шул ук вакытта төбәкләрнең күпчелегендә баллар аз гына үзгәреш кичергән. Димәк, тормыш сыйфатын чагылдыручы күрсәткечләр дә күпкә үзгәрмәгән. Бары тик тугыз төбәктә генә рейтинг баллы ике пункттан артыгракка үзгәргән. Бишесендә – позитив динамика, ә дүртесендә тискәре динамика теркәлгән.

Аутсайдерлар

Рейтингның аутсайдерлары арасында – Калмыкия, Кабардино-Балкария, Ингушетия, Курган өлкәсе, Алтай Республикасы, Бурятия, Еврей автоном өлкәсе, Карачаево-Черкесия, Забайкалье крае, Тыва Республикасы. 2019 елгы рейтингта әлеге төбәкләрнең күпчелеге шулай ук соңгы унлыкка кергән. Барлык аутсайдерларга социаль-икътисадый үсешнең түбән дәрәҗәсе, халыкның керемнәре буенча артталык һәм эшсезлекнең югары дәрәҗәсе хас. Җыелма рейтинг баллары соңгы унлыккка кергән барлык төбәкләрдә дә 35тән кимрәк, бу ил буенча булган уртача күрсәткечтән шактый түбән.

Мөһим

2020 елгы рейтингта барлык төбәкләрдә рейтинг баллының медиан күрсәткече 45,774не тәшкил итте, бу 2019 елгы рейтингта теркәлгән медиан күрсәткечтән 0,395кә түбәнрәк.

* Рейтинг Яңалыклар РМА заказы буенча Рейтинг РМА экспертлары тарафыннан әзерләнгән (2019–2020 еллар өчен Росстат, Сәламәтлек саклау, Финанс министрлыклары, Үзәк Банк һәм башка ачык чыганаклардан алынган мәгълүматлар буенча).

61,600 балл



ЛЕНИНГРАД ӨЛКӘСЕ

61,046 балл

ВОРОНЕЖ ӨЛКӘСЕ

60,523 балл



ХАНТЫ-МАНСИ АВТОНОМ ОКРУГЫ – ЮГРА

59,253 балл



КАЛИНИНГРАД ӨЛКӘСЕ

57,916 балл



ЯМАЛ-НЕНЕЦ АВТОНОМ ОКРУГЫ

57,865 балл



ЛИПЕЦК ӨЛКӘСЕ

2020 ЕЛНЫҢ ГЫЙНВАР–ДЕКАБРЬ АЙЛАРЫ ӨЧЕН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОННАРЫНЫҢ ҺӘМ ШӘҺӘР ОКРУГЛАРЫНЫҢ СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДЫЙ ҮСЕШ РЕЙТИНГЫ



Рейтинг турында

2020 елның гыйнвар-декабрь айлары өчен Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларының социаль-икътисадый үсеш рейтингы ТР Икътисад министрлыгы тарафыннан төзелгән. Территорияләрне чагыштырганда ундүрт төп күрсәткеч күздә тотылган, шул исәптән: хезмәт хакының минималь кулланучылык бюджетына нисбәте; эшсезлек дәрәҗәсе, җан башына исәпләнгән өстәмә кыйммәт (гыйнвар-сентябрь); өстәмә кыйммәт (гыйнвар-сентябрь); җан башына исәпләгәндә төп капиталга кертелгән инвестиция күләме (бюджет акчаларыннан тыш) (гыйнвар-сентябрь); төп капиталга кертелгән инвестиция күләме (бюджет акчаларыннан тыш) (гыйнвар-сентябрь); җан башына исәпләгәндә кулланышка тапшырылган торак йортларның гомуми мәйданы; җан башына исәпләгәндә салым һәм салым булмаган керемнәр; салымнар һәм салым булмаган керемнәр; җан башына исәпләгәндә икътисадый эшчәнлекнең чиста төрләре буенча җитештереп озатылган товар күләме; бер эшләгән кешегә туры килгән тулаем авыл хуҗалыгы продукциясе; тулаем авыл хуҗалыгы продукциясе.

Мөһим

2019 елның гыйнвар-декабрь айлары белән чагыштырганда рейтингта иң югары сикерешне Мөслим районы күрсәткән, ул 26 урын югары күтәрелеп, 13 нче урынга чыккан. Яшел Үзән (+16, 16 нчы урын) һәм Алабуга (+11, 9 нчы урын) районнары үз позицияләрен шактыйга яхшырткан.

697,2

мең сум – республика буенча уртача җан башына исәпләгәндә төяп-озатылган продукция күләме.

Әлеге күрсәткеч буенча муниципаль берәмлекләре лидерлары:

4113,5 мең сум Әлмәт районы

1691,4 мең сум Түбән Кама районы

1573,1 мең сум Алабуга районы



КАЗАН

ӘЛМӘТ РАЙОНЫ

ТҮБӘН КАМА РАЙОНЫ



ЛАЕШ РАЙОНЫ

ТУКАЙ РАЙОНЫ



ЮГАРЫ ОСЛАН РАЙОНЫ



1,9%

республикада теркәлгән эшсезлек дәрәҗәсе (2021 елның 1 гыйнварына карата).

37 муниципаль берәмлектә әлеге күрсәткеч уртача республика күрсәткеченнән түбәнрәк. Эшсезлекнең иң түбән дәрәҗәсе Актаныш (0,29%), Алексеевск (0,37%) һәм Балык Бистәсе (0,4%) муниципаль районнарында теркәлгән.

Чагыштыру өчен

Питрәч районы, 2019 елның гыйнвар-декабрь айлары белән чагыштырганда, рейтингта 14 пунктка түбәнгә төшеп, 23 нче урынга калган. 38 нче урынны алган Аксубай районы да 12 пунктка түбән тәгәрәгән.

Кызык

Рейтингта Тәтеш муниципаль районы бер ай эчендә 12 урынга югарыга күтәрелгән, бу – гыйнвар-ноябрь айлары белән чагыштырганда. Алга китүнең чыганаклары: эшсезлек дәрәҗәсенең кимүе, төп капиталга инвестицияләр кертүнең артуы, тулаем авыл хуҗалыгы продукциясенең, салым һәм салым булмаган керемнәрнең артуы.

0,687

кв. метр гомуми торак мәйданы 2020 елның гыйнвар-декабрь айларында Татарстанда кулланышка тапшырылды, бу җан башына исәпләгәндәге сан.

Әлеге күрсәткеч буенча алдынгылар:

4,518 кв. метр **Питрәч районы**

4,067 кв. метр **Лаеш районы**

2,983 кв. метр **Тукай районы**

ЯҢА ЧИШМӘ РАЙОНЫ

ЯР ЧАЛЛЫ



АЛАБУГА РАЙОНЫ

ЧИРМЕШӘН РАЙОНЫ



БИЕКТАУ РАЙОНЫ

САБА РАЙОНЫ

www.protatarstan.ru
ТАТАРСТАН
Әһәмиятле
Игелекле
Мәңгелек
Вакцина әзер
Сайттагы яңалык
Яңалыклар
Реклама 16+

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

игелекле эшләр /

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

Бу санда тәкъдим итәбез:

Гүзәл затларыбыз республика язмышын **НИЧЕК** үзгәртә

Сабыйларның гомерен **КЕМНӘР** саклап кала

Әбиләребез **НИЧЕК** матурлана

Атланмайны **КАЙДА** атлыйлар

PRESSA

ТАТАРСТАН ХАТЫН-КЫЗЛАРЫ: ЮЛ ЯРУЧЫЛАР, ҺӨНӘР ОСТАЛАРЫ, ИЛҺАМ БИРҮЧЕЛӘР

Ната Смирнова фотосы

«Ел хатын-кызы. Ел ир-егете: хатын-кыз карашы» Республика конкурсы алдыннан «Татарстан хатын-кызлары» Төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе, ТР Иҗтимагый палатасы рәисе Зилә Вәлиева республика язмышында хатын-кызларның роле турындагы фикерләре белән уртаклашты.

Автор: Татьяна Вафина

СӨЕМБИКӘДӘН БАШЛАП

– Зилә Рәхимҗановна, Татарстан тарихын үзгәрткән ун хатын-кыз исемен атый аласызмы?

– Ун исем белән генә чикләнеп булырмы икән? Алар бик күп. Сөембикәдән башлап... Мин Мөхлисә Бубины аерып билгеләр идем. Абыйлары белән ул мөселманнарны агарту юнәлешендә бик күп эшләр башкара. Мөхлисә Россия Мөселманнарының үзәк диния нәзарәте составына сайлана, анда казый була. Ул бик абруйлы вазыйфа, хөкемдар кебек, аңа ихтирам һәм ышаныч белән карыйлар. Аның үрнәге бик күп хатын-кызларга йогынты ясагандыр, дип уйлыйм. «Казан Кремле» музей-тыюлыгында аңа һәм мөслимә хатын-кызларга багышланган почмак бар. Мин һәрвакытта да Ислам дәүләтләреннән Казанга килгән югары вазыйфаи затларга аның турында сөйли идем, ә алар Мөхлисә Бубиның фотосы каршында озак басып торалар, чөнки бу ханым чыннан да тәэсирләндерә һәм олы ихтирам уята. Аны 1937 елда репрессияләүләр. Камал театрында Ркаил Зәйдулланың аңа багышлап «Үлеп яратты» спектакле куелды... Миңа калса, Мөхлисә мисалы – традицион киртәләрне җимергән очракларның иң көчлесе. Беренче чиратта, ул хатын-кызның тигезлеккә ирешергә, халыкны мәгърифәтле итү өчен сизелерлек өлеш кертергә омтылышы. Ул абыйлары белән беррәттән, мәдрәсәдә укыткан, укыту программасына традицион дини гыйлемнәр белән янәшә дөньяви белем бирү дәресләре дә керткән. Шул рәвешле алар имамнарның белем дәрәҗәсен үстергәннәр. Мөхлисә Буби – Татарстан өчен әһәмиятле шәхес.

Тагын бер мәгърифәтле хатын-кыз – Фатиха Аетова. Ул хатын-кызларның белем алу мәсьәләсен кайгырта. Кияүгә чыкканда да, аның булачак бай киявенә төп шарты мөселман кызлары өчен мәктәп төзү була. Казандагы шундый беренче мәктәпне ул ача.

Сынлы сәнгать музеенда игътибарымны һәрвакытта да Ольга Сергеевна Александрова-Гейнс портреты җәлеп итә. Ул Казанның иң бай хатын-кызларының берсе була. Милли музей барлыкка килүдә, Александр приютының яңа бинасын төзүдә аның өлеше зур. Мөселман һәм христианнарны укыту өчен хәйрия фондларына беренче булып акча бирә. Аның гаиләсенеке булган Александр пассажы бинасын шәһәргә тапшыра. Ксения хатын-кызлар гимназиясенең бинасын сатып ала... Шуңа да без аның турында күбрәк белергә тиеш, ул моңа лаек. Бүген хәйриячелекнең социаль престижы күпмедер дәрәҗәдә югалып бара. Хәлле кешеләрнең барысы да хәйрия белән шөгыльләнергә әзер түгел. Тренд булсын иде ул, чөнки акчалы кешеләр ярдәмендә хәл ителә торган мәсьәләләр бар. Акчалы кешеләрнең һәрбер проблемага җаваплы мөнәсәбәте – безнең шәһәрнең, республиканың тарихында булган традиция ул. Хатын-кызлар, нигездә, башлап җибәргәннәр, калганнар алар үрнәгенә ияргән. Хатын-кызның табигатенә хас сыйфат ул – дөньяны яхшы якка үзгәртү, игелек, хәйрия үрнәкләре күрсәтү.

Казан университетында беренче хатын-кыз укытучы, республиканың беренче хатын-кыз прокуроры, беренче хатын-кыз сынчысы Рада Нигъмәтуллина... Хәзер рак күзәнәкләрендәге аксымның аерым бер участогы барлыгын аерып чыгарган профессор Рәмзия Кыямованың тикшеренүләре турында күп сөйлиләр... Хатын-кызлардан башка гына тормыш бармый, әмма кайсыларыдыр беренче адымны ясый, соңыннан гына ул нормага әйләнә. Хәзер инде хатын-кыз мөгаллимнәр дә, прокурорлар да күп, һәр өлкәдә, һәрбер һөнәрдә бар алар. Миңа калса, бу да үзенә күрә йогынты, югыйсә нәрсә дияргә була моны? Хатын-кыз мөмкинлекләренең олы потенциалының гамәлдә кулланылуы.

Бөек Ватан сугышында катнашкан хатын-кызларның батырлыгы! Мәгубә Сыртланова кебекләр бик күп кызлар өчен үрнәк була. Ул вакытта һәммәсе дә хатын-кызлар космонавтикасы турында хыяллана иде. Бәлки, барысы да хыялларын чынга ашыра алмагандыр, иң мөһиме – хыялланалар һәм шуңа омтылалар иде.

Республиканың беренче нефтьчеләре – шулай ук хатын-кызлар. Ромашкинодагы нефть яткылыклары турында һәркем белә. Ул сугышка кадәр үк барлыкка килгән. Казанда ул хатын-кызларны ничек олылаганыбызны хәтерлим. Алар инде өлкән яшьтә иде, шунда берсе нефть фонтаны аттырасы төнне күргән төшен сөйләде: «Якты бер көн, мин авыл урамы буйлап барам. Шунда: «Скважина! Скважина! Шунда йөгерегез!» – дип кычкыра башладылар. Без йөгереп килсәк, скважинадан фонтан бәрә. Ә аннан кечкенә генә ап-ак, бөдрә йонлы сарык бәрәннәре чыга. Чыгалар да чыгалар – бөтен кыр алар белән тулды. Ә иртәнгә скважинадан нефть бәреп чыкты! Төшем рас килде». Ромашкино нефть яткылыгы – Татарстан гына түгел бит. Шул вакытта СССРның күп проблемаларын хәл итү мөмкинлеге дигән сүз була ул.

Азәрбайҗанга баргач, аларның беренче профессиональ актрисасы турында ишеттем – ул да татар кызы. Азәрбайҗан театрының күренекле актрисасы! Шуңа да без тормышны үзгәрткән хатын-кызлар турында сөйләгәндә, алар күп, алар һәркайда дип әйтә алабыз. Алар тормышны Татарстанда гына түгел, бөтен җирдә үзгәрткәннәр һәм үзгәртәләр.

Элек хакимияттә хатын-кызлар, нигездә, социаль өлкәдә, мәдәнияттә була иде. Хәзер инде аларны

һәрбер өлкәдә күрергә була, һәм аларның керткән өлеше дә сизелерлек. Җитәкче хатын-кызларыбызның күп булуы да сөендерә. Җәмгыять үзгәрә.

– Сочида массакүләм мәгълүмат чаралары фестивалендә без башкорт делегациясе белән очраштык, аларның журналистлары Сезне – якташларын – Татарстан тарихына йогынты ясаучы хатын-кыз дип саный...

– Әйе, мин Башкортостанда туганмын. Башкортостанда танылган якташлары турында китап чыгарганнар иде. Ул китап минем өчен шул ягы белән кызыклы булды: мине ни өчендер танылган якташлар исемлегенә түгел, ә башкасына кертkәннәр иде. Аның тарихы болайрак булды: мин Казанга 1982 елда килдем, 1990 елда депутат булып сайландым, 1992 дә – парламент Рәисенең беренче урынбасары идем. Шунда, билгеле, төрле фаразлар башланды да инде: мине кем һәм нәрсә өчен шулай күтәрә? Кем генә булмадым мин! Шәймиевнең никахтан тыш туган кызы да, Рәхимовның никахтан туган кызы да булдым һәм ул Шәймиевтән мине урнаштыруын үтенгән, имеш... Тагын башка фаразлар да күп булды. Татарстанда туып-үсмәгән кеше бит. Ә теге китапны язган журналист җитди тикшеренү эшләре алып барган һәм патша вакытында үткәрелгән беренче җанисәп документларын эзләп тапкан. Анда акка кара белән минем әти ягыннан бабаларым Башкортостанга Казан губернасының Арча районыннан биш бала белән күчеп килгән һәм 1725 елгы җанисәпкә эләккән. Шулай итеп, мин тарихи ватаныма кайткан булып чыгам.

ХАКИМИЯТТӘ ХАТЫН-КЫЗЛАР: ТАТАРСТАН ВАРИАНТЫ

– Хакимияттә хатын-кызлар: Татарстан варианты? Сез үзегезнең коллегаларыгызны ничегрәк сурәтләр идегез?

– Беренче чиратта, алар профессионаллар. Пандемия вакытында тарихның ничек үзгәрүен карагыз. Караңгыда, билгесезлектә юл салырга туры килде бит. Беркем бер нәрсә белми, бөтенләй өйрәнелмәгән вирус. Биредә, һичшиксез, Президентыбызның карары хәлиткеч роль уйнады. Россиянең баш санитар табибы һәм Роспотребнадзор башлыгы Анна Попова Рөстәм Нургали улына Татарстанның пандемия шартларында югалып калмавы, бер минутка да туктап калмыйча, эшне дәвам иттерүе өчен рәхмәт әйтте. Бу эштә дә хатын-кызлар аерылып торды: коронавирус белән көрәш буенча штаб җитәкчесе Ләйлә Фазлыева да, Роспотребнадзорның ТР буенча идарәсе җитәкчесе Марина Патяшина да... Табибларга нинди йөк күтәрергә туры килде! Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш терапевты Диана Габделганиева ничек итеп беренче вируска каршы плазма эшләүләрен сөйләде... Табиблар, шәфкать туташлары тәүлекләр буена кизү торып, авыруларны карыйлар, дәвалыйлар, үлемнән коткаралар! Шундый көчлеләр, кайгыртучаннар! Һәм мондый сугышчан әзерлекле, тәүлек әйләнәсенә барган эш режимы бер елга якын дәвам итә.

Шушы катлаулы елда министрлыклар да, ведомстволар да үзләренең эшчәнлеген яңадан корды. Ирада Әюпова җитәкчелегендәге Мәдәният министрлыгы да, Эльмира Зарипова җитәкчелегендәге Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы да, Талия Миңнуллина җитәкчелегендәге ТРның Инвестицион үсеш агентлыгы да...

> – Хатын-кызның табигатенә хас сыйфат бар – дөньяны яхшы якка үзгәртү, игелек, хәйрия үрнәкләре күрсәтү.

– Сез ничек уйлыйсыз, кайсы мөһимрәк: сәяси карьерамы, әллә гаиләме?

– Минемчә, хатын-кыз андый сайлау алдында калырга тиеш түгел. Беренчедән, хәзер барысы да инфраструктурага корылган, барысы да шундый тиз үсә-үзгәрә, хәтта берничә баласы булган хатын-кыз да бала туып, бер ел-ел ярым узуга, эшкә чыга ала. Ярдәмчеләр, бала караучылар яллыйлар. Яки баланы бакчага бирәләр. Әмма эшләүләрен дәвам иттерәләр. Хатын-кыз бу җәһәттән ир-аттан көчлерәк бит ул, ул ашарга төн җиткәч тә пешереп ашый ала.

Мин үзем гаилә белән эш арасыннан сайларга теләмәс идем. Минем өчен тегесе дә, бусы да мөһим. 50 яшьлек юбилеем алдыннан кергән куркыныч төшемне әле дә хәтерлим. Имештер, юбилеема әзерләнәм, ә үзем кияүдә түгелмен икән әле. Һәм котым алынып, төшемдә кунаклар исемлеген карыйм – моны чакырырга кирәк, тегесен... Бәлки, берәрсе кияүгә алып куяр. Алса, бала таба алмаячакмын бит инде, дип уйлыйм, имеш. Шул мизгелдә ишектә кыңгырау тавышын ишетәм (чынбарлыкта) – улыбыз шулай икенче төрле итеп баса төймәгә. Ирем ишекне ачарга кирәк, дип сөйләнә... Шунда йөрәгемә рәхәтлек иңде. Йа Ходай, нинди куркыныч төш керде бит, дип уйлыйм үзем! Алай да була ала иде бит. Гаилә бөтен кеше өчен дә мөһим. Гәрчә башкача да була ала. Актриса Мирошниченконың интервьюларында эшемне, рольләремне аңлы рәвештә сайладым дип, берничә тапкыр ассызыклап әйткәне бар. Калганын һаман артка чигерә килгән. Һәм кайсыдыр бер мизгелдә, соңга калганын аңлаган. Мин хатын-кызның андый сайлау хокукы юк дип әйтмим, үзем өчен «мондый сайлау алдында калырга язмасын!» дип саныйм.

ҺӘРБЕР КЕШЕ – ҮЗЕ БЕР ДӨНЬЯ

– «Ел хатын-кызы» конкурсы рәисе буларак, Сезнең күңелгә уелып калган катнашучылар бармы?

– Ел саен жюри әгъзалары белән йомгак ясарга утырганда бер проблема килеп чыга: пьедесталга күтәрәсе килгән хатын-кызлар һәрвакытта да урыннар һәм номинацияләр санынннан күбрәк була. Галимә хатын-кызлардан башлап, хуҗабикәләргә кадәр. Алар сокландыра, тәэсирләндерә, әсир итә. Кешеләр төрлечә яши. Кемдер гомере буена күршесе белән ярыша, икенче берәү үзенең кумирын кабатлый, ә безнең конкурста катнашучылар беркемне кабатламыйча, мөстәкыйль рәвештә үз бәхетен үзе кора, һәм ул ихлас була. Катнашучыларның барысы да җиңүче була алмый, әмма тирән тормыш фәлсәфәсе белән хәтердә кала. Мәсәлән, Ютазы районының Урыссу бистәсеннән Абрамовлар гаиләсе. Бөгелмәдә зона турында алар сәхнәгә чыккач, тамаша залында соклану дулкыны узды. Ике кыз, яшь, чибәр әниләр рус милли костюмнарында иде. Аларның киемнәре кул эшләре буенча осталык үрнәге иде, һәм бу осталык серләре аларның гаиләсендә кадерләп саклана. Әниләре Ирина – тегү остасы, әтиләре Евгений – агач эшләре остасы, бергәләп, мәктәптә хезмәт итәләр, сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикләнгән балаларны кул эшләренә өйрәтү аша тормыш итү өчен күнекмәләр бирәләр, матурлыкка өндиләр. Бәхетле кешеләр – Абрамовлар кебек үз урынында булган кешеләр. Анна, Мария, Лукерьяның Пелагея исемле сеңелләре туууын ишетеп сөендем. Дүртенче кызлары да әниләре кебек кул эшләре остасы булырмы, юкмы – белмим, әмма ул бәхетле йортта үсәчәк.

Ирина кебек хатын-кызлар дөньяларын бәхетле итә белә, ул дөньяда һәркем үзен рәхәт итеп тоя: ире дә, балалары да, дуслары да, туганнары да. Аллаһка шөкер, бездә андый хатын-кызлар бар.

Былтыр зона турында Әлмәт районы Иске Суркино авылының «Сеспель» ансамбленнән Уняслу Сидуловна Сатыбалова исемле искиткеч бер әби белән очраштык. Үз авылы гадәтләренең чын саксысы! Борынгы чуваш такмакларын саклап кына калмаган ул, яшьләргә дә өйрәткән, үз халкының асыл гореф-гадәтләрен иң кыйммәтле байлык итеп яшь буынга саклап калган. Туксанын узган әби сәхнәгә чыгуга, халык сәнгатенең магиясен тоемлый башлыйсың. Уникаль хатын-кыз! Әлбәттә, һәрбер кеше уникаль, һәрбер кеше – үзе бер дөнья. Менә шундый дөньялар ачылсын өчен шартлар тууына шатланырга гына кала.

Мин бу конкурсны яратам. Янәшәдә шундый кешеләр булуына сокланам. Журналистлыктан киләдер инде ул, мөгаен.

Минем өчен кешеләр һәм аларның язмышлары һәрвакыт кызыклы булды. Андый хатын-кызлар белән очрашкан саен илһамланып, көч алып кайтасың. Тормышка башкача карый башлыйсың.

ӘЙБӘТ ГАИЛӘ ҺӘРВАКЫТ ИКЕ КЕШЕДӘН ТОРА

– Хатын-кызлар арасында «Ел ир-егете» ничек килеп керде?

– Бу номинация соңрак барлыкка килде. Һәм конкурска үзенә бер төрле гаделлек алып керде. Без бит囗 эштә дә, өйдә дә ир-егет янәшәсендә. Хатын-кыз тормышны үзе генә тартып бара алмый, алай булмый ул. Шуның ачык мисалы – Гәүһәр һәм Харис Хөснетдиновлар, гаиләгә бала алып, конкурста катнашкан беренчеләр. Аларның өч баласы үзләренеке, сигезне балалар йортыннан алганнар.

Гәүһәр мине төрле яклап сокландырды. Бигрәк тә балалар йортларыннан алган балаларының барысын да дәвалап, гади мәктәпкә укырга бирүе белән. Ул аларны сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен махсус учреждениеләрдән алган.

Проблемаларым булганда, мин аларга килергә ярата идем. Килсәм, ул балаларының аяк киемнәренә карап утыра – 11 пар өр-яңа итек тезелеп тора, барысының да авызлары ачык. Арзанрак дип, бөтен балаларына берьюлы Кытайда эшләнгән аяк киемнәре сатып алган булган, ә алар бер тапкыр урамга киеп чыкканнар һәм менә нәтиҗәдә – шушылар. Ә иртәнгә барысының да мәктәпкә барасы бар. Менә Гәүһәр иртәнгә кадәр 11 пар аяк киемен каян гына табыйм икән дип утыра.

Мин шунда ук айнып киттем: минем проблемалар аныкы янында чүп кенә икән бит. Аннан соң балалар миңа концерт куйдылар – җырладылар, биеделәр, бергәләп чәй эчтек. Ире булмаса, Гәүһәр боларның барысын да үзе генә тартып бара алыр идеме?! Харис тыйнак ул үзе, ә баш очында гүя нур балкый. Ул өйгә керүгә балалар «Әти!» дип, аның кочагына ташланалар. Шундый ышанычлы таянычың булмаса, бу кадәр балаларны тәрбияли алмас идең.

Әйбәт гаилә икән – анда һәрвакыт икәү бар. Ә бит балалар, бигрәк тә авыр язмышлылары, ятим калганнары – аларга бит итекләр генә түгел, аларга әти-әни җылысы да кирәк. Ә күпме җылылык бирергә кирәк аларга! Мин андый кешеләр алдында тезләнергә әзер.

2020 елның «Ел хатын-кызы. Ел ир-егете: хатын-кыз карашы» конкурсыннан истә калган мизгелләр

Фото: «Татар-информ» МА

ТАТАРСТАН ХАТЫН-КЫЗЛАРЫ САННАРДА

Беренче язгы айның тәүге көннәре алып килгән җылыны һәм матурлыкны бернинди суыклар һәм бураннар да җиңә алмый. Ә инде 8 Март якынлашканда, Казанда гына түгел, Татарстанның иң төньяк районнарында да кыздыра башлый. Көчле затлар гүзәл затларыбызга чәчәкләр һәм башка бүләкләр эзләп, тыз-быз кибеткә чаба. Бу гомер-гомергә шулай. Алга таба да шулай булачак. «Татарстан» журналы 100 ел дәвамында башка – ир-ат-хатын-кыз көннәре белән бергә, әлеге бәйрәмдә генә хатын-кызлар көнен генә яктыртып, барысын да яхшы хәтерли: рәсми котлауларны да, шигъри юлларны да, матур фотопроектларны да, әдәби әсәрләрне дә... Ләкин нинди генә заманны алсак та, статистика барыннан да кызыграк тоела. Статистика белән бигрәк тә 1926 елгы, ул вакытта «Спутник партийного активиста» дип аталган «Татарстан» мавыккан. Үз битләрендә төрледән-төрле статистик хисаплар бастырган, анда аерым баганаларда һәрвакытта да хатын-кызлар билгеләп (саналып һәм теркәлеп) үтелгән.

1926 ел. «Спутник партийного активиста»


СПУТНИК
ПАРТИЙНОГО АКТИВИСТА
ЕЖЕМЕСЯЧНЫЙ ОРГАН
ТАТАРСКОГО ОБЛАСТНОГО КОМИТЕТА ВКП (б)
№ 4–5
1 СЕНТЯБРЯ 1926 ГОДА
КАЗАНЬ

Татреспублика **12** кантонны яисә **125** волостьны берләштерә, анда **2 942 875** кеше яши, шуларның **1 145 512**се – хатын-кыз.

ПАРТИЯГӘ КАБУЛ ИТЕЛГӘННӘР САНЫ БУЕНЧА:

1926 елның **1** гыйнварына карата партоешма торышы мәгълүматлары буенча, без – **4551** партия әгъзасына (шул исәптән **420** хатын-кыз), **3984** кандидатка (шул исәптән – **568** хатын-кыз) ия.

908 кеше партиягә **1926** елның беренче **2** аенда кабул ителде, шуларның **148е (16%ы)** – хатын-кыз.

20 хатын-кыз (кергәннәрнең **55**е) партиягә Горрайонда кабул ителде.

1 хатын-кыз (кергән **10** арасында) партиягә Әгерҗе кантонында кабул ителде.

По полу мы имеем следующие результаты в приеме:

Название ВУЗ'ов	Мужчин		Женщин	
	Подано заявлений	Принято	Подано заявлений	Принято
Каз. гос. ун-т	608	156	530	136
Каз. вет. ин-т	232	76	32	18
Ин-т с. хоз. и лес. . . .	278	173	88	21
Вост. пед. ин-т	223	161	204	121

Во всех ВУЗ'ах число принятых мужчин превышает число женщин, особенно же велик мужской сектор в сельско-хозяйственных ВУЗ'ах.

ХАТЫН-КЫЗЛАРНЫ ЯҢАДАН ӘЗЕРЛӘҮ БУЕНЧА

1926 елның май–июнь айларында крестьянкалар арасында женкомиссияләр өчен хезмәткәрләр әзерләү буенча өлкә күләмендә ай ярымлык курслар оештырылды.

Курсларны 52 кеше тәмамлады, шуларның 14е – рус хатын-кызы, 28е – татар, 9ы – милли азчылыктан.

ШӘҺӘР-АВЫЛ ХӘБӘРЧЕЛӘРЕ САНЫ БУЕНЧА

2043 эшче хәбәрчесе Татреспублика газета-журналларында эшли.

Шуларның 152се – хатын-кызлар.

1379 авыл хәбәрчесе Татреспублика газета-журналларында эшли.

Шуларның 81е – хатын-кызлар.

ХАТЫН-КЫЗЛАР АРАСЫНДАГЫ ЭШСЕЗЛЕК БУЕНЧА

Татреспубликада 1925 елда 6753 эшсез хатын-кыз теркәлгән.

Татреспубликада 1926 елда 8364 эшсез хатын-кыз теркәлде.

Бер ел эчендә хатын-кызлар арасында эшсезлек 1611 кешегә артты.

Эшсезлек белән көрәш максатларында шәһәр советы тарафыннан оештырылды:

30 кешелек кер юу урыны;

583 кешелек ташламалы туклану ашханәсе;

7023 хатын-кыз Казанда кооперациягә берләште.

2021 ел. Татарстанстат

САН һӘМ ЯШЬ ТУРЫНДА

Татарстанда **2 094 251** хатын-кыз яши

Шуларның:
1 633 206 – шәһәр хатын-кызлары
461 045 – авыл хатын-кызлары

Шәһәрдә хатын-кызлар ир-атларга караганда 26, 5 меңгә КҮБРӘК
Авылда хатын-кызлар ир-атларга караганда 21 меңгә КҮБРӘК

Кызлар малайларга караганда **1026** га азрак туа

Шәһәрдә кызлар малайларга караганда **871** гә азрак туа

Авылда кызлар малайларга караганда **155** кә азрак туа

Татарстанда **1 808 637** ир-ат яши

25 лет
яшькә кадәргеләр арасында шәһәрдә ирләр хатын-кызларга караганда күбрәк

25тән **55** яшькә кадәргеләр арасында авылда ир-атлар хатын-кызларга караганда күбрәк

БЕЛЕМ ДӘРӘҖӘСЕ ТУРЫНДА

24 709
хатын-кыз җитәкче

Шуларның:

20 470
югары белемле

3280е
урта һөнәри белемле

686сы
гомуми урта белемле

372се
гомуми төп белемгә ия

38 882
хатын-кыз квалификациясез хезмәттә эшли

Шуларның:

2716сы
югары белемле

13 971е
урта һөнәри белемле

13 235е
гомуми урта белемле

8961е
гомуми төп белемгә ия

ХЕЗМӘТ ХАКЛАРЫ ТУРЫНДА

31 773 сум –
Татарстан хатын-кызларының уртача хезмәт хакы

44 238 сум –
Татарстан ир-атларының уртача хезмәт хакы

Ирләрнең уртача хезмәт хакы хатын-кызларның уртача хезмәт хакыннан **12 465 сумга** АРТЫГРАК

* Хезмәт хакы турында мәгълүматлар сайлап тикшерү нигезендә (кече эшкуарлык субъектларын кертмичә) 2019 елның октябре өчен китерелә. Тикшеренүләр 2 елга 1 мәртәбә үткәрелә.

Ир-ат җитәкчеләрнең хезмәт хакы хатын-кыз җитәкчеләрнекенә караганда **26 650** сумга КҮБРӘК

Квалификация таләп ителмәгән эшләрдәге (җыештыручылар, төзелеш эшчеләре һ.б.лар) ир-атларның хезмәт хакы **4060** сумга КҮБРӘК

Сак хезмәтендә эшләүче ир-атларның хезмәт хакы шул ук эшне сайлаган хатын-кызларныкына караганда **8256** сумга КҮБРӘК

Авыл, урман хуҗалыгы, балыкчылык һәм балык тоту тармагында эшләүче квалификацияле ир-ат хезмәткәрләрнең хезмәт хакы хатын-кызларныкына караганда **2845** сумга КИМРӘК

Чүп-чар җыюда эшләүче ир-атларның хезмәт хакы шундый төр эштә эшләүче хатын-кызларныкына караганда **2189** сумга КИМРӘК

НИКАХ ТУРЫНДА

Татарстанда 16 яшьтән өлкән **1 730 354** хатын-кыз яши

Шуларның:

806 307се – рәсми рәвештә кияүдә
95 779ы – гаилә хәлен рәсми рәвештә теркәмәгән
331 899ы – беркайчан да кияүдә булмаган
152 650се – рәсми рәвештә аерылган
25 138е – ирдән аерым яши
316 635е – тол

ТРнда бер анидән туган максималь бала саны
13

ТОРМЫШ БҮЛӘК ИТҮЧЕЛӘР

Автор: Руфия Фазылова

Яшәү белән үлем арасы... Республика балалар клиник хастаханәсенең патология белән туган һәм җитлекми дөньяга килгән балалар бүлегеннән чыккач, әнә шулай дип куйдым. Күздә – яшь, тамакта төер иде... Бүлекнең җитәкчесе – РФнең атказанган табибы, ТРның атказанган табибы, табиб-неонатолог Фатыйма Казакованың биредә эшли башлавына 40 ел була. Шул вакыт эчендә авыр хәлдәге нинди генә сабый белән очрашмаган ул...

Фото: Лилиана Вәлитова

ЯҢА ШАРТЛАРГА ИЯЛӘНҮ

Якты, киң коридорлар. Ара-тирә палаталарда сабыйлар тавышы ишетелеп ала. Дөньяга тууга, яшәү өчен көрәшә башлаган гөнаһсыз җаннар шул рәвешле нидер әйтергә тели сыман. Бәлки, берәр җирләре авыртадыр, бәлки, янәшәләрендә әниләре юклыгын сизенәләрдер, бәлки...

Әнине юксыну, дигәннән. Пандемия башланганнан бирле бүлектә сабыйлар үзләре генә ята. Дүрт урынлык «Ана һәм бала» палаталарына хәзер биш, алты сабыйны салганнар. Шәфкать туташлары тәүлек әйләнәсе яннарында кизү тора икән.

– Әлбәттә, әниләре дә биредә торса, безгә җиңелрәк булыр иде, – ди Фатыйма Казакова. – Тик яңа шартларда яңача эшләргә өйрәнергә туры килде. Дөресен генә әйткәндә, әлегә безнең аналар өчен урын да юк, чөнки балалар саны күп. Казан шәһәренең 1 нче балалар хастаханәсендә ковид диагнозы куелганнарны дәвалыйлар, шуңа күрә патология белән яисә җитлекми туган сабыйларның барысын да монда алып киләләр.

Журналистлар өчен биредә язарга «җим» күп. Нинди генә авыр сабыйларны аякка бастырмаганнар. Аеруча күңелгә тия торган очраклар бар.

...Фатыйма Мусаевнаның эшли башлаган гына чоры. Республика балалар клиник хастаханәсенә авыр хәлдәге бер сабыйны алып киләләр. Диагнозы «сепсис». Мондый очракта гомерне кан салу гына коткарырга мөмкин. Вакыт бик чикле. Әтиәнисенең кан группасын тикшереп утырган арада баланың гомере өзелергә мөмкин. Яшь табиб, сабыйның кан группасын күргәч, куанып җибәрә: нәкъ аның группасы, резус-факторлары да туры килә. Шул рәвешле санаулы минут эчендә табибә донорга әйләнә.

– Ул вакытта әле турыдан-туры кан салалар иде, – дип искә алды Фатыйма Мусаевна. – Сабый яткан бокс янына кушетка куеп, кан бирдем. Шулай итеп ул баланы коткарып калдык.

Республика балалар клиник хастаханәсенең патология белән туган һәм җитлекми дөньяга килгән балалар бүлегендә 500(!) граммлы сабыйларны да аякка бастырганнар. Бүген дә бүлектә 26 атналык, авырлыгы бер килога да җитмичә туган бер ир бала ята. Үпкәләре белән проблемасы зур икән.

– Үпкә, баш мие, күзләр – гадәттә җитлекми туган сабыйларның күбесендә шушы әгъзалар белән бәйле проблемалар була.

– Ничә атналык балаларны коткарасыз? – дим табибка.

– 2012 елдан Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы 22 атнадан башлап, авырлыгы 500 граммнан артык булган балаларның исән калу мөмкинлеге бар дигән нәтиҗәгә килде. Һәм без, табиблар, аларның гомерләре өчен көрәшергә тиешбез. Мөстәкыйль сулый, ашый башласа, даими рәвештә авырлык җыйса, йомышларын тоткарлыксыз үти алса, бала тернәкләнүгә бара дигән сүз.

Табиблар, сабый ана карынында сәламәт булып яралса, аерым сәбәпләр аркасында йөклелекнең вакыты кыскарса да, бик куркыныч түгел дип саный. Иң мөһиме – бала дөрес җитлексен. Тиешле тәрбия бирелсә, куркыныч диагнозлары булмаса, андый балалар үз яшьтәшләрен 1,5–3 яшьләрендә куып тота.

«КҮЗЛӘРЕНӘ ГАШЫЙК БУЛДЫМ...»

Фатыйма Мусаевна Үзбәкстанда туган. Дөрес, тамырлары Татарстаннан аның. Әби-бабайлары исән калу өчен, 1921 елгы ачлыктан качып, Урта Азия якларына чыгып киткән. Кызга әби-бабасы Татарстан турында еш кына сөйли торган була. Шуңа да яшь Фатыйманың Казанга – әби-бабаларының кендек каны тамган җиргә барып укыйсы килә. Әнисе дә кызының Татарстанда белем алуын тели. Ташкентта урта мәктәпне тәмамлагач та, Фатыйма Казанга килә. 1974 ел була бу. Зур конкурс аша Казан дәүләт медицина университетының педиатрия бүлегенә керә.

– Безнең нәселдә табиблар бар, – диде Фатыйма ханым. – Шуңа да медицина юлыннан китүем көтелмәгән хәл түгел иде. Ә менә табиб-неонатолог булуыма укытучым Ирина Белова этәргеч бирде. Дүртенче курста ул безне неонатологиядән укытты. Яңа туган балалар янына да беренче тапкыр ул алып барды. Укытучыбыз безгә сабыйларның аяк-кулларын ничек сөртергә, эшкәртергә кирәклеген аңлатты. Шулвакыт мин аларның күзләренә гашыйк булдым. Алар әле сөйләшә, аңлата алмый, ә карашлары җаныңа үтеп керә. «Апа, мин яшәр өчен тудым, миңа синең ярдәмең кирәк!» – дип әйтәләр иде сыман. Мин балаларның барысын да яратам, әмма яңа туган сабыйлар... Алар бит фәрештәгә тиң.

Фатыйма Мусаевнаның эшкә урнашырга килгән шәфкать туташларына беренче соравы: «Балаларны яратасызмы?» Чөнки нинди генә профессионал булсаң да, беренче урында балаларны ярату кирәк, дип саный ул.

– Берничә ай эшләгәч, кире китүчеләр дә бар, – дип сүзен дәвам итә табибә. – Бездәге сабыйлар аерым мөнәсәбәт сорый. Бу эш кенә түгел, күңел халәте булырга тиеш.

Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы мәгълүматларына караганда, дөньяда ел саен якынча 15 миллион бала вакытыннан алда дөньяга килә. Бу һәр унынчы бала җитлекмичә туа дигән сүз. Алга киткән илләрдә әлеге күрсәткеч түбәнрәк. Россия соңгылары исәбенә керә. Тик ничек кенә булмасын, бу сан бездә дә үсә бара.

– Медицина алга бара. Элек бала табарга сәләтле булмаган хатын-кызлар да бүген ана булу бәхетенә ирешә, – диде Фатыйма Мусаевна. – Җитлекмичә туучы сабыйлар саны менә шуңа да арта. Әлбәттә, беренче сәбәпләр ул түгел. Хатын-кызның сәламәтлеге, тәгаен алганда, ана карынындагы инфекцияләр вакытыннан алда бала табуга китерә. Калкансыман биз, бөерләрнең дөрес эшләмәве, грипп, ОРЗ, ангина, һ.б.лар – барысы да йөклелекнең вакытын кыскарта.

КҮЗ ЯШЬЛӘРЕ АША...

Фатыйма Мусаевна белән җитлекмичә туган балаларны карап чыктык. Авыз, борыннарында махсус аппаратлар, нәни генә кул-аякларында исә нәзек көпшәләр. Мондый система аша сабыйлар азык ала.

...Минем баштан да узды әлеге хәлләр. Игезәк кызларым җитлекмичә – утыз атнадан туды. Безнең диагнозларны саный китсәң... Табиб ике бит тутырып язган иде. Шул чактагы йокысыз төннәр, башка килгән мең төрле начар уйлар... Моны сөйләп-аңлатып бетереп тә булмый. Нәзек көпшә аша шактый ашаганнан соң, беренче тапкыр бирелгән ун грамм «смесь»не сабый организмы кабул иткәнгә сөе-

нүләрем! Кайбер балаларның ашказаны ризыкны бөтенләй кабул итми, кире чыгара бит. Аппаратсыз сулый башлауларын белгәч, шашып елауларым...

Авырлыклары ике кило ярым булгач, хастаханәдән чыктык без. Бер ел дәвамында неврологта исәптә тордык. Безнең кебек җитлекмичә туган сабыйларны махсус бер көнгә чакыралар иде. Һәм менә шунда гына вакытыннан алда дөньяга килүнең бөтен проблемаларын күрдем – гарип балалар күп иде. Аналар үзара сөйләшә – бер ишләренең күзләре начар күрә, икенчеләрендә ашказаны, үпкә белән проблемалар бар икән. Өченчеләренең үсешендә тоткарлыклар... «Менә бу бик яхшы массажист», – дип, бер-берсенә телефоннар бирешәләр, тернәкләндерү үзәге адреслары белән бүлешәләр. Шулай булгач, ничек кенә матур итеп күрсәтергә тырышсак та, проблема зур – җитлекмичә туган балаларның киләчәктә гарип калу куркынычы бар. Хәер, моны Республика балалар клиник хастаханәсендә яшермиләр дә.

– Җитлекмичә туган балаларның якынча 60–70 процентының алга таба сәламәтлекләре белән теге яки бу проблемалары кала, – диде Фатыйма Мусаевна. – Табиб бөтен кешегә, шул исәптән һәр балага ярдәм итәргә тиеш. Без шуның өчен Гиппократ анты бирәбез. Ә баланың бездән тулысынча сәламәт булып чыгып китүе... Кызганыч, монысы бездән генә тормый. Әлбәттә, күп нәрсә анага кайтып кала – алга таба баласы белән ничек шөгыльләнәме, туклану режимын дөрес көйлиме һ.б.лар. Иң мөһиме – ана баланың исән калачагына, аякка басачагына ышансын. Тугач та, сабыйлар гел йоклый, берни аңламый кебек, тик алар аналарын тоя. Һәм менә бу нарасыйга яшәргә көч бирә.

ҖЕПЛӘР ӨЗЕЛҮ

Тою дигәннән искә төште, кызларым белән хастаханәдә ятканда, үзем өчен бер нәтиҗә ясаган идем. Гадәттә, әниле балалар янына бер ташландык сабыйны салалар. Балаларын ашаткан арада аналар теге балага да булыша, «смесь» ашата. Безнең палатада да шундый бер нарасый бар иде. Ул башкаларга караганда тыныч, еламый иде. Ә карашы әлегә кадәр күз алдымда! Гүя үзенең нинди язмышка дучар булганын сизә, аңлый, шуңа да начар холкын күрсәтми. «Әниләре баш тарткан балаларның күбесе шулай тыныч була», – дип сөйли иде шәфкать туташлары.

Моның белән Фатыйма Мусаевна да килеште:
– Ана белән бала арасында безгә күренми торган җепләр була. Кендекләр киселсә дә, сабый анасын тоя. Ә менә баласыннан баш тарткач, шул күзгә күренми торган җепләр кисеп ташланган кебек була. Һәм бала шушы зур галәмдә яшәү өчен үзе генә көрәшә башлый. Чынлыкта аңлатып булмый торган гаҗәп әйберләр бу... Әлбәттә, тугач та һәр бала яшәү өчен көрәшә башлый. Без моны нәни пациентларыбызда ачык күрәбез. Ә менә ата-анасы баш тарткан сабыйларда бу инстинкт аеруча көчле була.

Бүген дә бүлектә берничә ташландык бала бар икән. Фатыйма Мусаевна башка сыймаслык бер хәл турында сөйләде: күптән түгел Чита шәһәреннән ирле-хатынлы пар килгән. Хатын баласын монда тапкан, Даун синдромы диагнозы куелганга, аңардан баш тарткан.



Фатыйма Мусаевна белән җитлекмичә туган балаларны карап чыктык. Авыз, борыннарында махсус аппаратлар, нәни генә кул-аякларында исә нәзек көпшәләр. Мондый система аша сабыйлар азык ала.

– Алар Казанга махсус бала табарга, аннан соң калдырырга, дип килгәннәр инде, – диде табибә. – Балада Даун синдромы икәнлеге ана карынында чакта ук ачыклана. Ир белән хатын шул рәвешле бала белән бөтен элемтәләрне юкка чыгарырга теләгән.

– Күбрәк авыру балалардан баш тарталармы? – дим.

– Әйе, тик төрле очраклар була. Ялгыз хатын-кызлар бар. Яшәр урыны, төпле эше булмаска мөмкин. Нишләргә белмәгәнлектән, ул баласыннан баш тартырга уйлый. Без андый әниләр белән кат-кат сөйләшәбез. Психологлар эшли. Соңгы дистә елда дәүләт андый аналарга карата йөз белән борылды, дип әйтер идем. Хатын-кыз матди хәлен яхшыртканчы, торак белән бәйле проблемаларны хәл иткәнче, баласын сабыйлар йортында калдырып тора ала. Аны аналык хокукыннан мәхрүм итмиләр. Теләгән вакытта баласын барып күрә, алып китә ала. Мин моны бик хуплыйм. Әллә нинди авыр язмышлар бар. Без бит барыбыз да кешеләр, бер-беребезгә ярдәм кулы сузарга тиешбез.

...Менә шундый табибә Фатыйма Мусаевна. Ак халаты кебек күңеле дә пакь тоелды аның миңа. Җәй көне мәрхүм булган әнисе турында күз яшьләре белән сөйләде. Аерым яшәсәләр дә, иртә-кич көн саен янына барып йөргән. «Ана белән бала арасын бәйләүче җепләр аеруча көчле иде безнең», – ди ул моңсу гына. Үзенең дә ике кызы (алар да Казан дәүләт медицина университетын тәмамлаган, берсе-офтальмолог, икенчесе – теш табибы) белән мөнәсәбәтләре бик җылы. Шушы кыйммәтләрне җуймаган, аңлаган табибәнең яңа туган сабыйлар белән эшләве сөенечле.

P.S. Республика балалар клиник хастаханәсендә 460 граммлы сабыйның гомерен саклап калганнар. Ә дөньяда аннан да кечкенә балаларның исән калу очраклары бар. Мисал өчен, АКШта 2006 елда Тэйлор исемле кызчык 22 нче атнада дөньяга аваз салган: аның авырлыгы – нибары 284 грамм, буе 24 сантиметр булган. Кызчык өч ай эчендә ике килограммнан артык авырлык җыйган.

ӘБИЛӘР НИЧЕК ҮЗГӘРӘ

4

«Татарстан» журналы тарафыннан һәр елны март аенда үткәрелә торган «матурлык десанты» быел үзен көткән җиргә – Өлки картлар йортына бара алмады. Татарстанда әби һәм бабайларны коронавирус йоктырудан саклыйлар, һәм әлегә алар янына чит кешеләрнең керүе тыела. Шуңа күрә, TNL матурлык салоны белән бергә, без үзебезнең әниләребез һәм әбиләребезгә гүзәллек бәйрәме оештырырга уйладык. Һәрвакыттагыча безгә «Татарстан гүзәле-2021» һәм «Казан гүзәле-2021» булышты. Бәйрәм бик матур булып чыкты!

Күркәм әбекәйләребезнең – үткәнгә, ә гүзәл булышчыларыбызның киләчәккә язган хатларын сезнең хозурга тәкъдим итәбез.

Үзгәрешләрдән соң әбекәйләребез, яшь гүзәлкәйләргә сокланып һәм үзләренең яшь чакларын искә алып, үткәнгә, яшьлекләренә хат язды: язмыш ничек булып чыгар, нәрсәгә өметләнергә, нидән курыкмаска, гомер юлын ничек лаеклы итеп узарга – шул турыда фикерләрен ак кәгазьгә төшерде.

фото: Ната Смирнова

Әнвәрия Нурулла кызы Сираҗиева,

туган елы – 1943, 22 сентябрь.

Биләр районы (хәзерге – Аксубай районы) Такталы авылында туа. Чистай медицина училищесын тәмамлый. Питрәч районы Кибәк Иле авылына эшкә җибәрелә. Әлеге авылда 36 ел, лаеклы ялга чыкканчы, фельдшер-акушер булып эшли. Һәрвакыт бик яхшы укый, медицина институтына керергә хыяллана, әмма кияүгә чыга һәм Кибәк Илендә яшәп кала. Ике бала тәрбияләп үстерә. Хезмәт ветераны, 20 елдан артык авыл советы депутаты була.

Уңышлар сиңа, Әнвәрия!

Куелган максатыңа таба атла, Әнвәрия, бернәрсәдән дә курыкма! Ышан миңа – син бөтенесен дә булдырасың! Үзеңнең медицина хезмәткәре булу һәм кешеләргә ярдәм итү турында балачак хыялыңны тормышка ашырачаксың. Гомерең буе яраткан эшең белән шөгыльләнәчәксең. Беренче ярдәм күрсәтергә һәм кешеләрнең гомерен саклап калырга өйрәнәчәксең. Эшеңне намус белән башкар. Кешеләрне байга – ярлыга, дәрәҗәле – дәрәҗәсезгә бүлмә, һәркайсына ярдәм ит. Һәм сиңа һәркем рәхмәтле булыр. Үзеңнең эшеңне яратып башкаруың, авыруларга армый-талмый ярдәм күрсәтүең эзсез үтмәс, үзең коткарган кешеләрнең рәхмәтен тоеп яшәү искиткеч рәхәтлек бирер. Син бөтен кешегә ярдәм итми булдыра алмаячаксың! Уңышлар сиңа, Әнвәрия!

Синең җаныңның яртысы, өлкәнәйгәне.
Март, 2021 ел

Сания Әхмәтвәли кызы Дудкина (Тимергалиева),

туган елы – 1946, 1 апрель.

Казанда ишле, тату гаиләдә туып-үсә. Әти-әнисе Казан моторлар җитештерү берләшмәсендә эшли. Яшь чагында җәмәгать эшләрендә актив катнаша. 1964 елның августында Казанга СССР җитәкчесе, КПСС ҮКның беренче секретаре Никита Хрущев килә. Югары вазыйфаи затны чәкчәк тотып каршы алуны республика җитәкчелеге Сания Әхмәтвәлиевнага ышанып тапшыра. Бу турыдагы тарихны укучыларыбыз журналыбызның алдагы саннарыннан (2020 ел, №5-6) укып белде.

Бернидән дә курыкма, Сания!

Сания, сиңа, яшь кызга, шуны телисем килә: бернидән дә курыкмыйча, куелган максатыңа таба атла. Хаталан, аннары шул хаталарыңны төзәт – бу куркыныч түгел. Рәхәтләнеп хыяллан һәм үз йөрәгеңә ышан! «Теләмим», «булдыра алмыйм», «эшләмим» сүзләрен оныт! Әниебез шулай өйрәтте. Тормыш бик кызыклы булачак. Хәерле юл!

Сания Әхмәтвәли кызы

Венера Салих кызы Зыятдинова,

туган елы – 1939, 28 ноябрь.

Сарман районы Баткак авылында туа. Сугыш вакытында әнисе тол калгач, Венерага кечкенәдән аңа булышырга туры килә.
Хәләл җефете белән бергә, КАМАЗ Бөтенсоюз удар төзелешендә, Ямал-Ненец автономияле округында нефть-газ ятмаларын үзләштерүдә катнаша.
Хезмәт ветераны: эш стажы – кырык елдан артык, шуның яртысыннан күбрәге – Әлмәт пассажирлар ташу берләшмәсендә хезмәт кую.

Венера, син авылдан качмадыңмы әле?

Минем кадерле Венерам! Нәрсә әйтим инде сиңа? Тормышың катлаулы да, кызыклы да булачак. Ә иң яхшысы – ул әле дәвам итә. Син авылдан качмадыңмы әле? 16 яшеңдә качачаксың! Техникумга укырга керәчәксең һәм шунда калачаксың. Ярый әле 16 яшеңдә качкансың! Алайса хәзер башка карчыклар белән капка төбендәге эскәмиядә утырып, ләчтит сатар идең. Ә болай исә балаларың һәм оныкларың белән зур, матур йортта яшәячәксең, телевизордан тапшырулар карап ял итәчәксең. Бу, әлбәттә, кызыклырак инде! Тик моңа кадәр әле бик-бик ерак! Сиңа гомер юлың буйлап бару, йөгерү, ашкыну һай ничек кызык булачак әле! Тик беркемгә дә: «Ә мин менә синең кебек чакта!», «Ә мин менә болай эшләр идем!» – димә. Тормыш шигарең «Ничек кирәген үзең беләсең» булачак. Бу ахмак киңәшләрдән яхшырак.

Мәңге синеке булган Венераң

Нәзирә Мифтах кызы Бикмөхәммәтова,

туган елы – 1929, 8 март

Питрәч районы Күн авылында күп балалы урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. Әтисен 1931 елда кулакка чыгарып куалар, йортын, җирен, мөлкәтен – барысын да тартып алалар. Сугыш вакытында, мәктәп баласы гына булса да, Нәзирә колхозда эшли. 1950 нче елларда, ире белән бергә, илнең атом-төш калканы – корал плутоние җитештерелә торган Красноярск-26 – СССРның иң ябык шәһәрләреннән берсендә яши. Ике бала тәрбияләп үстерә. Хезмәт ветераны: эш стажы кырык елдан артык, шулардан егерме елга якыны – Казандагы һөнәри-техник белем бирү училищесында укытучы.

Тормыш егермедә дә, туксанда да матур. Үземдә сыналган!

Егерме яшьлек чагыма хат... Ә нигә хат, смайликлы WhatsApp түгел? Оныкларым шундый хат яза бит. Заманча да, егерме яшьлек өчен аңлаешлырак та. Шаяртуларны читкә куеп әйткәндә исә, яшьлеккә хат язу, гәрчә үткәнең син үзең булсаң да, бер дә файдалы эш түгел. Барысын да үзгәртеп, язмышны яңадан язып булмый бит инде. Акка күчереп торасы да юк – язмышымны үзем яздым, беркем дә комачауламады. Шунлыктан оялырлык, йөземә кызыллык китерерлек бернәрсә дә юк үткәнемдә. Егерме яшьлек үземә бары шуны гына әйтә алам: үзең ничек кирәк табасың, шулай яшә. Дөньяда иң кадерле нәрсә акча, уңыш яки карьера түгел, бәлки якын кешеләрең һәм дусларың. Кызганычка, моны дуслар һәм якыннар һаман кими барган чакта гына аңлыйсың...

P. S. Һәм тагын шуны онытма: тормыш егермедә дә, кырыкта да, туксанда да матур. Үземдә сыналган!

P.S. P.S. «Татарстан» журналы редакциясе проектта катнашучыларның барысын да – хатын-кызлар көне белән, ә Нәзирә Мифтаховнаны тагын әле туган көне белән дә котлый!

Ләйсән ТАҺИРОВА,
«Казан гүзәле – 2021»,
21 яшь

Динә ЮНЫСОВА,
«Татарстан гүзәле – 2021»,
18 яшь

Барлык хыялларың тормышка ашсын, Динә!

80 яшь – шулкадәр ерак кебек тоела әле... 80 яшендә синең зур гаиләң буласына, барлык куелган максатларыңа ирешәчәгеңә чын күңелдән ышанам. Барысы да гамәлгә ашачак! Үзеңнең изге хыялыңны тормышка ашырачаксың – модалы кием коллекцияләре булдырачаксың, спорт белән шөгыльләнәчәксең, күп сәяхәт итәчәксең һәм башкаларны да шундый актив яшәү рәвешенә өндәячәксең. Син аларга үрнәк булачаксың!

Уңайлы зур йортыңда ял көннәрендә иң яраткан һәм кадерле кешеләрең җыелачак. Зур, тату гаилә – балалар, оныклар, аларның балалары. Гәпләшә-гәпләшә, тәмле бәлешләр белән сыйланачаксыз, уеннар уйнап, җырлар җырлаячаксыз һәм һәр мизгелнең кадерен беләчәксез...

Мин сиңа гүзәл мизгелләргә бай, хәерле озын гомер телим! Барлык хыялларың тормышка ашсын!

Мин синең бәхетле икәнеңне беләм, Ләйсән!

Ләйсән Эмиль кызы, сиңа инде 70 яшь, һәм мин синең бәхетле икәнеңне беләм! Күзләрең 20 яшьлек чагыңдагы кебек нур чәчә! Нинди гүзәл күренеш – син камин янында иң якын кешеләрең янәшәсендә утырасың... Башыңда бер уй бөтерелә: «Узган гомерем нинди соклангыч!»

ПРОЕКТНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУЧЫЛАР

Татьяна КАТИНА,
TNL матурлык салоннары челтәре идарәчесе

БУ БИК МАТУР, ИГЕЛЕКЛЕ АКЦИЯ

– «Татарстан» журналы белән уртак проектта катнашу минем өчен зур дәрәҗә. Бу бик матур, игелекле акция. Кунакларыбыз күз алдыбызда үзгәрде – күзгәгә күз салгач, үзләрен танымадылар да хәтта. Хатын-кыз теләсә ничә яшьтә дә гүзәл, сөйкемле, һәм ул һәрвакыт матур күренергә, гел сокланулы сүзләр генә ишетергә тиеш! Кызларны һәм ханымнарны күркәмләтү безгә һәрвакыт ләззәт китерә.

Регина ХӘСӘНОВА,
TNL Professional компаниясенең әйдәп баручы визажист-технологы

ГҮЗӘЛ ХАНЫМНАРНЫ БӘХЕТЛЕ ИТҮ – БИК РӘХӘТ!

– Яшьләре 75 тән арткан ханымнар белән эшләү, процесс барышында аларның хисләрен тою, шәрехләүләрен тыңлау минем өчен бик кызыклы булды. Табигый матурлыкларын күрсәтү өчен, мин аларга җиңелчә генә макияж ясадым. Өлкән яшьтәге хатын-кызларның матурлык салоннарына сирәк йөрүе кызганыч, аларны кайвакыт балалары яки оныклары гына алып килгәли. Ә бит матур булу һәрвакыт рәхәт! Матурлык ул яшькә карамый, көн саен үзеңә игътибар бирү кирәк. Әлеге күркәм ханымнарны тагын да бәхетләрәк итү миңа бик рәхәт булды!

Ксения КУКАРИНА,
парикмахер-универсал:

ӘБЕКӘЙЛӘРЕГЕЗНЕ МАТУРЛЫК САЛОНЫНА ЕШРАК АЛЫП КИЛЕГЕЗ

– Хатын-кызларны үзгәртү процессында катнашу, аларны бәхетле итеп күрү миңа бик ошады! Матур картаеп, өлкән яшьтә дә күркәмлеген җуймаган ханымнарга сокланам. Мөгаен, балалары һәм оныкларына игътибарлырак булырга һәм әни-әбиләрен матурлык салоннарына ешрак алып килергә кирәктер – алар үзләрен 8 Мартта гына түгел, ел әйләнәсе патшабикә итеп тойсын. Алар моңа лаек!

Оксана МИРОНОВА,
парикмахер-универсал:

ЙӨЗЛӘРЕ ШАТЛЫКТАН БАЛКЫЙ

– Кызганычка каршы, безнең күркәм әби-дәү әниләребез матурлык салонына бик сирәк йөри. Алар ояла, бу бик кыйбат дип уйлый, йә ялкаулана. Ә менә хәзер, катнашучыларыбызның чәчләрен матурайткач, аларның йөзләре шатлыктан балкый. Алар, мөгаен, «Нигә мин элегрәк тә монда килмәдем икән, матур булу бик рәхәт икән бит!» дип гаҗәпләнәдер. Һәрберебез куанып, якыннарыбызның игътибарын тоеп яшәсен!

ИРИНА ШТЕЙНБЕРГ: «ЯШӘРГӘ, СӨЯРГӘ, ЭШЛӘРГӘ»

Хатын-кызлар бәйрәме алдыннан Чаллы һәм, гомумән, Татарстан өчен легендар шәхес, эшкуар, җитәкче һәм меценат Леонид Данилович Штейнбергның кызы, «Кама-Тракс» транспорт-экспедиция компаниясе ҖЧҖ генераль директоры Ирина Штейнберг үз тормышындагы иң мөһим нәрсәләр, анда әтисенең роле һәм хатын-кызның тормыштагы урыны турында сөйләде.

– Исәнмесез, Ирина Леонидовна! Әтиегез турында сөйләгез әле, нindирәк кеше иде ул?

– Исәнмесез! Без барыбыз да тормышка балачактан киләбез. Шушы әти-әниемнән дөньяга килүем – зур бәхет. Әнием Людмила Андреевна – дус та, укытучы да, аңа бу сәләт Аллаһтан бирелгәндер. Әтием Леонид Данилович гайре табигый кеше иде. Бервакыт сигезенче сыйныфта укыган чакта имтиханда әтием турында «Кызык язмышлы кеше» дигән инша яздым. Ул вакытта миңа 14 яшь иде. Мин бик җитди һәм беркатлы идем. Бүген миңа 50 яшь, һәм мин инде андый ук җитди дә, андый ук беркатлы да түгел... Тик аның хакында баш хәрефтән «Кеше» дип язылган һәр бәяләмәне биш куллап раслыйм. Менә әни әтигә болай дип язган: «Сине ихластан хәтта вак-төякләрдә дә намуссызлыкка юл куймаучы, гаделсезлек кылмаучы чын Ир-атларның берсе дип саныйм». Без аның белән һәрвакыт үзебезне ышанычлы хис иттек. Әти янында һәрвакыт кайгыртучанлык, игелек һәм чын дуслык мохите хөкем сөрә иде.

– Аның сезгә тормышта биргәннәреннән иң мөһиме нәрсә дип саныйсыз?

– Ул миңа биргәннәр турында беркайчан да уйлаганым булмады. Мөгаен, бу геннардыр. Мин дә, апам да бер-беребезгә һәм гаиләбезнең күпсанлы дусларына карата мәхәббәт, җылылык һәм хөрмәт мохитендә үстек. Әни белән әти нигез итеп алган һәм икесенең дә карашларына туры килгән («бер каннан» диләр бит, алар нәкъ шундый иде) бу тормыш принципларын без үзебезгә сеңдереп үстек. Һәм бездәге һәр уңай сыйфат, һәр яхшылык – әни белән әтидән килә.

– Аның сезгә калдырган төп мирасын нидә күрәсез?

– Менә 2017 елда югары трибунадан яңгыраган докладтан берничә юлны мисалга китерергә телим: «Транспорт предприятиеләре оештырып, без эш урыннары булдырабыз. Һәм без сезнең белән зур йөк машиналары йөртүче һөнәрен ничек абруйга ия һөнәргә әйләндерү турында сүз алып барырга тиеш. Чын хезмәт, тир түгеп башкарылган хезмәтнең бүген кадере кими. Ә безнең тармакта династияләр эшләсен иде! Менә шул чакта ахыр нәтиҗә белән кызыксыну көчәя, җаваплылык арта. Чөнки һәр хезмәткәр бөтен гаиләсе эшли торган предприятиене саклап калырга теләячәк бит! Бу – табигый теләк. Безнең компаниядәге 52 кеше – бер-берсенең туганы ул: ир белән хатын, аларның үсеп җиткән балалары, хәтта оныклары. Без мондый традицияне хуплыйбыз, ул компанияне берләштерә һәм ныгыта. Хезмәт биржасына чират һәм эшсезлек буенча пособие булмаганда, дәүләт тә ныгый». Ул һәрвакыт проблемаларны күреп-ачып бирә белде. Чын көрәшче иде, әмма сугышып-ызгышып йөрүче түгел. Кешеләр белән элемтәләр кора белде, теләсә нинди эшне соңыннан йөзгә кызыллык килмәслек югары дәрәҗәдә оештырды. Һәм һәрвакыт шәһәребез, республикабыз һәм ватаныбыз патриоты булды.

– Сезнеңчә, хатын-кыз көченең сере нәрсәдә?

– Минемчә, көч турында сөйлибез икән, рухи ныклык турында сүз алып бару дөрестер. Әмма бу төшенчәләр җенескә бәйле түгел. Рухи көч шәхеснең нигезе буларак карала ала. Ул тормыш юлын лаеклы узу мөмкинлеге бирә. Әгәр дә хатын-кыз турында сөйләшәбез икән, аның серлелеге, тормыштагы урынын искә алу урынлы. Һәм монда, минем карашка, иң мөһиме – ана булу сәләте. «Бүреләр белән йөгерүче хатын» китабындагы сүзләр искә төшә: «Тирән интуиция, нәселенә, иренә һәм, гомумән, җәмгыятькә карата ихлас кайгыртучанлык күрсәтү. Хатын-кызлар өзлексез үзгәреп торган шартларга оста яраклаша, тугрылык мәсьәләсендә чик-чама белмәүчән һәм искиткеч кыю була». Һәм бу гасырдан гасырга шулай дәвам итә.

– Сездә нәрсә эшкә кызыксыну уята? Каян илһам аласыз?

– Беләсезме, миңа бернәрсә дә комачауламый. Башка фикерләр дә, теләкләр дә юк, бары тик – яшәргә, сөяргә, эшләргә! Урамда буран буранлыймы, коеп яңгыр явамы – һич мөһим түгел. Иртән уянып, бер чынаяк каһвә эчү, барлык якыннарыңның да сәламәт һәм янәшәңдә булуын белү дә җитә. Ә илһамга килгәндә, аны яхшы күңелле, акыллы кешеләр белән аралашудан, китаплардан алам. Балалар, онығым белән табигатькә чыгып йөреп кайтулардан. Минем өчен яраткан шөгыль – өй эшләре, китаплар һәм кино. Онығым, туганымның улы һәм бөтен гаиләм. Табигатькә чыгып керү, скандинавиялеләрчә йөрү.

– 8 Март бәйрәме алдыннан хатын-кызларга нинди теләкләрегезне җиткерер идегез?

– Яраткан шагыйрәм Римма Казакова шигыре белән җавап бирәм:

«И склеивать разбитые на части,
И мелочи отбрасывать, как жмых,
И снова честно очень верить в счастье,
Которое должно быть в нас самих».

Фото «Кама-Тракс» ТЭК ҖЧҖ тарафыннан бирелде

Ольга Айдуганова, Бөгелмә торба продукциясе заводының «Инженерлык-җитештерү үзәге» ҖЧҖ директоры һәм хуҗасы

«МИҢА ЭШЛӘГӘН ЭШЕМ ОШЫЙ»

Былтыр мин «Ел хатын-кызы» бәйгесенең «Бизнес-леди» номинациясендә җиңү яуладым. Күпләр сәхнәдән минем ничек завод белән дә җитәкчелек итәргә дә, укырга да, балалар тәрбияләргә дә өлгерүем турында сөйләвемне көтте... Ләкин хакыйкать бөтенләй башкада. Гаилә, дуслар, хезмәттәшләрем ярдәменнән башка мин күп нәрсәгә ирешә алмаган булыр идем – чыгышым шул хакта булды.

Мин шактый күптәннән җитәкче урында – 24 яшемдә бүлек башлыгы, аннан соң хокук мәсьәләләре буенча директор урынбасары булдым. Бөгелмә торба продукциясе заводын өч ел элек җитәкли башладым, һәм бу теләп алынган эшем түгел иде. Әлеге предприятиегә нигез салган һәм аның хуҗасы булган әтием 2018 елда бакыйлыкка күчте. Әйе, без, завод хуҗаларының, яллы җитәкче чакыру варианты да бар иде, тик завод директоры мин булырга тиеш, дип карар кылдык.

Ул ел минем өчен бик авыр булды. Бу хакта элек беркайчан да ачыктан-ачык сөйләмәдем. Кызыма өч авыр операция көтелә иде. Аларның һәрберсеннән соңгы тернәкләнү чоры өч яшьлек баланың озак вакыт гипста ятуын таләп итте. Моңа кадәр мин биш елымны бала карау өчен бирелә торган ялда үткәрдем һәм һәрчак балаларым янәшәсендә булдым. Ә хәзер исә, шундый кирәк вакытта эшкә чыгарга туры килде, әле тегенди-мондый гына урынга түгел – завод директоры булып! Якыннарым: «Әйдә, тотын! Ярдәм итәрбез!» – диде. Һәм бергәләп йөкне тарта алдык.

Һәркем, хәтта хезмәткәрләр дә ярдәм итте. Күз алдына китерегез әле: җитәкче кеше һәм предприятиенең бердәнбер хуҗасы вафат була – 120 кеше шок хәлендә кала һәм ни эшләргә белми. Һәм менә заводка яңа директор – инде шактый күптән Бөгелмәдә яшәмәгән ханым килә. Мөгаен, мин алар урынында куркып калып, башка эш эзли башлар идем... Цехта барлык хезмәткәрләр катнашында ничек җыелыш уздырганыбызны, аларга барысы да яхшы булыр, дигәнебезне хәтерлим әле. Һәм безгә ышандылар – берәү дә эштән китмәде. Берәү дә.

Кешенең үз гамәле, эше өчен җавап биргәнен хөрмәт итәм. Барысы да үз җаваплылыгы чикләрен аңласын иде. Миңа һәрнәрсәне ниндидер тышкы йогынтылар, чит сәбәпләр белән аңлатырга әзер торган кешеләр ошамый. Үз-үземне шулай акларга маташам икән, бу сыйфат үземнең күңелемә дә хуш килми.

Узган ел авыр, әмма кызыклы булды. Һәм без аны яхшы гына тәмамладык. Тик март аенда, дөресен генә әйткәндә, барысы да бик начар булыр, дип уйлаган идем. Күпләр, шул исәптән минем өчен дә, 2020 ел уйланулар, күп нәрсәләргә төшенү чоры булды. Иң мөһиме, үзем өчен шуны аңладым: мин – план буенча яшәүче кеше. Миңа план кирәк! Эшләр план буенча бармаган очракта да башка план уйлап табарга була. Көндәлегем инде хәзер үк бер елга алдан тутырып куелган. Ә бит элегрәк бу мәсьәләдә проблемаларым бар иде. Бу исә өстенлекле юнәлешләрнең кайчак бик дөрес билгеләнмәвенә сәбәп булды. Эш-эш дип, балаларым тормышындагы күпме вакыйганы күрми калдым! Әмма мин иң дөрес тарафны таптым – гаиләм, якыннарым, дусларымны алгы планга куеп, тормышта барысын бергә алып барырга өйрәндем.

Миңа калса, бәхет ул ниндидер чагыштырма төшенчә түгел. Хатын-кыз яки ир-ат бәхете булмый. Һәм аның ниндидер универсаль рецепты да юк. Күптән түгел Энне Бурда турында искиткеч фильм карадым. Бу ханым озак вакыт хуҗабикә була, ә соңыннан ул иренең сөяркәсе барлыгын белеп ала, җитмәсә, бу сөяркә кием өлгеләре баса торган журнал турында Энненең идеясен тормышка ашырып йөргән икән! Мин Энне Бурданың кайсы мизгелдә бәхеткә тиенүен белмим, тик, фильмнан күренгәнчә, ул шул хыялын чынга ашырганда бик бәхетле була. Миңа бу фикер бик ошый. Бәлки, кемнеңдер хыял-нияте – пляжда аунап ятудыр. Ә минеке исә – менә хәзерге вакыттагы эшем.

Мин эшкә чыккач, балалар әни кешенең нигә кинәт өйдә сирәк күренә башлавын аңламады. Алар миннән бу хакта гел сорап йөдәтте, ә мин исә, «акча эшләргә кирәк бит» дип, акланып карадым. Тик соңыннан мондый җавапның кабул ителмәвен аңладым, чөнки балалар өчен акча мөһим түгел. Алар барыбер миңа үпкәләп йөри. Шул чакта уйладым-уйладым да әйтеп салдым: мин завод эше белән йөрим, командировкаларга барам, кешеләр белән очрашам, чөнки бу миңа ошый! Машина төзелешендә җитәкче хатын-кыз бәлки кемгәдер сәер тоеладыр, тик миңа эшем чыннан да ошый. Әйе, җитештерүне планлаштыру һәм маркетингны үстерү мәсьәләләренә карашым беразбашкарак. Ул ир-атларныкыннан аерыла, әмма үз нәтиҗәсен бирә.

Нәрсәдән көч аламмы? Кешеләр белән көндәлек аралашудан. Озын-озак, кызыклы әңгәмәләрнең кадерен беләм – совет чорында андый фәлсәфи гәп аш-су бүлмәсендә бара иде. Күптән түгел бер җыелышта Барнаулдан машина төзелеше тармагы буенча хезмәттәшемне очраттым. Дүрт сәгать гәпләшеп утырдык, һәм менә миннән инде яңа идеяләр, илһам ташый. Уку, белем эстәү дә тормыш дәртен арттыра. Күптән түгел санап караган идем: университетка 12 ел йөргәнмен икән – минем өч югары белемем бар. Хәзер дә укуымны дәвам итәм. Бәлки, квалификация күтәрү курслары әллә ни күп нәрсә бирмидер дә, әмма андагы тәҗрибә алмашы бик кадерле.

Сәяхәт итәргә яратам – яраткан шөгылем әнә шул. Күптән түгел Кубадан кайттым. Ә моңа кадәр Якутиядә булдым. Россиядә матур урыннар бихисап, һәм мин әлеге фикерне алга сөрәм. Менә, мәсәлән, Пенза өлкәсендәге Тархан дигән урын. Анда баргач, шушы төбәктә балачагын үткәргән Лермонтовның ничек шундый танылган әдипкә әйләнүен аңлыйсың.

Фото: Юлия Зильберг

ҺӨНӘРЛЕ ХУР БУЛМАС

Язманың видеовариантлы да бар

Автор: Руфия Фазылова

АТЛАНМАЙ ЯСАУ

«Татарстан» журналы халкыбызның ата-бабадан килгән затлы һөнәрләрен, шөгыльләрен барлауны дәвам итә. Яшь буын да колагына киртләп куйсын. Онытсан булсак, яңартыйк! Бу юлы гөбедә май яздык – нәкъ элеккечә, әби-бабайлар ясаганча.

ГӨБЕ

Әйе, бүген гөбедә май ясамыйлар инде. Яшел Үзән районы Олы Ачасыр авылының ак әбие – Гөлсинә Галләмова бу эшкә безгә күрсәтер өчен генә алынды. Әбекәй улы Нуртдин, килене Фәния белән яши. Килен-каенана булып, бер түбә астында гомер итүләренә 38 ел булган.

– Мин сугыш чоры баласы – 1939 елда туганмын, – дип сүзен башлады Гөлсинә апа. – Безнең әти сугыштан кайтмады, мин аны хәтерләмим дә дияргә була. Әби белән үстек. Әни көне буе колхоз эшендә булганда, без өч баланы ашатты, тәрбияләде ул. Кечкенәдән май ачлаганны хәтерлим. Селкенмәсен дип, энем белән гөбене тотып тора идек. Ә әби, пешкәк белән лап-лоп итеп, май ясый иде. Соңрак инде үзебез дә пешкәкне кулга алдык...

Иң беренче шуны әйтим: майны ясауны төрле районда төрлечә атыйлар. Кайбер якларда аны «язалар», «атлыйлар» (атланмай сүзе дә шуннан ясалган), ә менә Апас, Яшел Үзән якларында «ачлыйлар». Шулай булгач, Ачасырда без атланмайны ачладык.

Галләмовлар гомер буе сыер асраган. Бүген дә каралтыларында сөтлебикә бар. Әле икешәр, өчәр сыер асраган чаклары да булган.

– Хәзер маллар янына чыкканым юк инде, – диде Гөлсинә апа.

Без килгәнче, әбекәйнең килене Фәния апа сөт өстен җыеп, каймакны әзерләп куйган иде. Гөбе дә юылып, киптереп куелган. Монысын Гөлсинә апа үзе эшләгән.

– Чисталыкны яратам, – диде ул. – Әллә ничә еллар эшсез торып, гөбе тузанга баткан иде. Аның белән соңгы тапкыр кайчан кулланганымны хәтерләмим дә.

– Балалар үстергәндә атланмайны шунда ясый идегезме? – дим.

– Юк, ул чакта бит сепаратлар (сепараторлар – авт. иск.) чыкты. Гөбедә май ачлау бик күп вакытны ала, көне буена бара дисәм дә була. Ә сепарат белән җайлы, тиз.

Бисмилласын әйтеп, Гөлсинә апа каймакны гөбегә салды. (Литр ярым чамасы булгандыр). Һәм әкрен генә агач пешкәкне төшерде. Шуннан каймакны «төя» башлады.

– Бу гөбе сезгә кайдан килгән? – дим Гөлсинә апага.

– Дөресен генә әйткәндә, белмим. Әлеге нигезгә 1958 елны килен булып төштем. Ул чакта бар иде инде. Берәр балта остасы ясаган булгандыр, дип уйлыйм.

– Авылыгызда гөбе ясаучы бар идеме соң?

– Әйтә алмыйм, бәлки, булгандыр да. Ул бик четерекле эш. Юкә агачын балта белән юнып, үзәген алалар, менә шундый куыш барлыкка килә. Агач диаметрында түгәрәк такта юнып, каймак агып чыкмаслык итеп, булачак гөбе - куыш юкәнең бер башын томалыйлар.

Гөбегә күз салам: бик шомартып эшләнгән. Моның өчен чынлап та балта остасы булу кирәктер. Әле бит пешкәк тә, гөбедән аз гына кечерәк итеп, дөрес ясалырга тиеш. Зур булса, гөбегә керми яки терәлеп кала, ә кечкенә икән, каймак кырыйларга чәчри икән.

«КОМУ КИСЛЫЙ МОЛОКА?»

Гөлсинә Галләмова Олы Ачысырда туып-үскән. Авылда 3–4 мең кеше яшәгән чакларны да хәтерли ул. Әбекәебез бар ихласлыгы белән эшкә алынды – сүзгә бик бүленәсе дә килмәде.

Фото: Лилиана Вәлитова

– Яшегез бар, ял итеп алыгыз, – дидек үзенә.

– Бала чакта май ачлаган чаклар искә төшеп китте, – дип елмайды ул. – Әбиле, ачлы-туклы чаклар. И-и хәзерге дөньяның рәхәтлекләре. Бер эш юк бит: мич якмыйбыз, су ташымыйбыз, кер юмыйбыз... Без черек бәрәңге крахмалын ашап үскән буын.

– Крахмалны ничек ашый идегез? – дим.

– Әниләр аннан кабартма сыман әйбер пешерде. Ул чакта черек бәрәңге коры булып кибә, ап-ак крахмалы барлыкка килә иде. Өлкәннәр шуңа су белән он кушып, камыр әвәли иде.

Гөлсинә апа ял иткән вакытта без дә пешкәк белән каймакны «төеп» карадык. Авыр түгел үзе, тик көне буе шулай утырсаң, әлбәттә, куллар арый. Шуңа да йорттагы бөтен кешегә җитте ул. Тик май төшәргә уйламады...

Гөбе кулдан-кулга йөргән арада Гөлсинә ападан сөт, катык сату турында сораштым. Ачасыр гомергомергә шул кәсеп белән көн итеп, дан казанган авыл бит. Хәтта чиләк-көянтә асып поездга килеп кергән хатын-кызлар турында төрле мәзәкләр дә йөргән.

– И, сөтне күп саттык инде, – дип сөйләде Гөлсинә апа. – Без күбрәк Яшел Үзән шәһәрендә сату иттек. Анда ике катлы бараклар күп иде. Шунда фатирдан фатирга кереп: «Кому кислый молока?!» – дип кычкырып йөрдек.

– «Кислое молоко» – әчегән сөтме ул?

– Юк, катык. Руслар аны шулай дип атыйлар иде.

– Ә атланмай, каймак сатмый идегезме?

– Бик сатмый идек. Сорау булмадымы икән, хәтерләмим дә. Менә катыкны яратып алалар иде. Безнең якта аны бик тәмле дә ясыйлар бит.

...Ике сәгатьләп вакыт үтте, тик каймагыбыз куерырга уйламый да. Кичкә кадәр Олы Ачасырда утырасы була ахрысы дип, кот очты...

Әбинең килене Фәния апа безне коткарды – киченнән атланмай ясап куйган икән!

– Мин аның шулай көн буена барасын белдем инде, – дип елмайды хуҗабикә. – Сөт өстеннән май озак ясала. Кичә сепараттан сөт аерттым да шул каймакны табакка салып болгаттым. Куе каймактан май бик тиз ясала, болай азапланып утырасы түгел.

Фәния апа өстәлгә бер йомарлак май китереп куйды. Кош тоткандай сөенештек!

– Ул чакта сепаратлар булмаган. Шуңа да майны гөбедә ясаганнар, – дип куйды Гөлсинә апа. – Әйтәм бит, хәзер дөнья рәхәте инде. И, безнең әбиләр, әниләр бигрәк зур хезмәт куеп яшәгән инде.

Дөрес сүзгә җавап юк, барыбыз да әбекәй белән килештек. Бер йомарлак май алу өчен, көне буе агач төеп утыр инде! Без хәзер тиз ритмда эшләргә, яшәргә өйрәндек бит.

Гөбедәге каймак онытылды. Иң мөһиме – эш рәтен аңладык, күрдек. Калганы...

– Кичкә кадәр вакыт бар, бергәләп ачлап бетерербез, – дип, Фәния апа гөбене читкә алып куйды.

Ә без майны авыз итәргә өстәл янына җыелыштык. Башта төсенә игътибар иттем: каймак, сөт диярсең, ак төстә.

– Кышкы сөттән ясалган май шулай ак төстә була, – диде Гөлсинә апа. – Ә менә җәйге сөтнеке сарырак була.

– Ни өчен? – дибез.

– Кышын сыерлар коры печән, салам гына ашый, яшеллек күрми. Шуңа да ак була.

– Безнең халыкта: «Көзге катык кызым белән кияүгә, язгы катык улым белән киленгә», дигән гыйбарә бар. Ни өчен әбиләр шулай дип әйткән? – дим.

– Әйе, андый гыйбарә бар. Янәсе, кыз белән кияү якынрак. Чынлыкта да шулай, көзге катык, димәк, сөт тә, майлырак, тәмлерәк була.

Ниһаять, майдан авыз итәбез... Нәкъ каймак. Тәмлелеге! Кибеттә мондый май сатмыйлар. Авызда эреп китә!

– Чын май шундый була инде ул, – диде Гөлсинә апа. – Авызда эрергә тиеш.

– Ә сез болай каймактан атланмай еш ясыйсызмы? – дим.

– Фәния ясый. Сепаратта аерта ул. Оныклар кайта, кучтәнәчкә биреп җибәрә. Алты онык, алты оныкчыгым бар минем. Әйе, сыер булгач, рәхәт инде. Катыгын, кортын да ясыйсың. Авыл җирендә сыер тотмаучыларга аптырыйм.

Катык дигәннән, биредә без катыктан да авыз иттек. Куе, тәмле иде ул. Моның сере бар икән:

– Сепараттан чыккан сөттән ясасаң, катык куе була, – диде Фәния апа. – Ә ашаганда каймак саласың. Безнең катыкка бик ис китми, ә эни ярата.

Фәния апа бер мөһим нечкәлек турында искәртте: май ясалгач та, салкын суга салып юасы икән. Шул рәвешле майны сары суыннан – әйрәннән аерып алырга кирәк. Баксаң, элек ул әйрәнне эчкәннәр.

– Ярып бәрәңге пешерәсең дә, әйрән белән ашыйсың. Аннан да тәмле әйбер булмый иде, – диде әбекәй.

...Гөлсинә апа тормыш дилбегәсен улы белән килене кулына тапшырса да, бу йортта аның киңәшеннән башка эш башламыйлар. (Фәния апа да каенанасы кебек зирәк.) Бездән теләк: әлеге гаиләнең тормышы алга таба да майлангандай барсын.

ЭШ БАРЫШЫ:

- Сөт өстен җыябыз;
- гөбегә салабыз;
- пешкәк белән «төябез»;
- май төшкәннән соң, әйрәненнән аерып алабыз;
- юабыз;
- атланмайны түгәрәклибез.

ФЕРДИНАНД СӘЛАХОВНЫҢ ТОРМЫШ ЛИНИЯСЕ

Автор: Руфия Фазылова

ВИЗИТ КАРТОЧКАСЫ

Фердинанд Сәлахов 1955 елның 15 сентябрендә Апас районы Чүри-Бураш авылында туган.
Апас урта мәктәбен тамамлагач, Казан дәүләт медицина университетына укырга керә. Анда дүрт курс укыганнан соң, армия хезмәтенә китә. Хәрби хезмәттән кайткач, Казан дәүләт консерваториясенә – Зөләйха Хисмәтуллина классына укырга керә. Өченче курстан Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә эшли башлый. Шуннан соң Татар дәүләт опера һәм балет театрының концерт бригадасында хезмәт куя. Бүгенге көндә филармониянең музыкаль-әдәби лекторие директоры. Татарстанның атказанган артисты (1993 ел), Татарстанның халык артисты (1999 ел).

Без гаиләдә биш бала идек – апам Фирдәвес һәм өч энем. Ни кызганыч, бүген аларның берсе дә дөньялыкта юк инде. Апам узган ел март аенда вафат булды.

Әти миңа унөч яшь булганда үлде. Әни озын гомерле булды – Аллага шөкер, туксанга кадәр яшәде. Үзем тәрбияләдем, соңгы юлга озаттым. Бүген иң кадерле кешеләрем – хатыным Раилә һәм улым Марат, оныкларым, киленем. Дөрес, тугандай якын күргән дусларым бар…

Кечкенәдән бик нечкә күңелле, әбием итәгенә ябышып йөргән малай булып тәрбияләндем. Әтием Габдулла нишләптер ир балалар арасыннан энем Хәмзәне аеруча яратты. Кечкенәдән артист булып уйнадым, әтигә бу бер дә ошамый иде. Аның каравы, Миңлебикә әбиемнең бик яраткан оныгы идем. Башкаларга охшамаган, күп итеп китап укый торган, малай булып үстем.

Олы сәхнәгә аяк бастыручы итеп күренекле җырчыбыз Зөләйха Хисмәтуллинаны саныйм. Аның белән беренче очрашуым 1973 елда булды. Казан дәүләт медицина институты шәкерте була торып, мине уку елы уртасында консерваториягә тыңларга алып килделәр. Һич онытмыйм: мөгаллимә мине тыңлап бетерде дә класстан чыгып китте. Шуннан бөдрә чәчле, күзлекле, күркәм бер ирне ияртеп керде. Мин аны башта танымадым. (Әле ярый танымаганмын, бөтенләй коелып төшкән булыр идем!) Ә ул СССРның халык артисты, татарның бөек композиторы Нәҗип Җиһанов булган икән! Аларга янә «Сәрвиназ»ны җырлап бирдем. «Мин сине подгруппага алам, ләкин бит армия белән проблема. Сине хәрби хезмәткә алып китәчәкләр», – диде Нәҗип Гаязович.

Шулай итеп, Казан дәүләт медицина институтының дүрт курсын тәмамлап, армиягә китеп бардым. Чөнки хыялым табиб түгел, җырчы булу иде. Урау юллар белән 1977 елда гына кабат консерватория ишеген ачтым, Михаил Федорович Кольцов классында, әзерлек курсында укый башладым. Ике ел укыганнан соң, Зөләйха Хисмәтуллина мине үз классына алды. Табигый яңгырашын югалткан тавышлы студентны биш елга канатың астына сыендырыр өчен түземлек, зур профессиональ гыйлем һәм… кешеләрне ярату кирәк.

Консерваторияне тәмамлап, эшли башлагач та, Зөләйха Хисмәтуллина янына осталыгымны шомартырга йөрдем. Ул мине беркайчан да кире бормады.

Укытучымның үлемен бик авыр кичердем. Инде шактый вакыт үтсә дә, аның киңәшләре, аналарча җылы мөнәсәбәте – гел күңелемдә.

> “
> – Һәр заманның үз проблемасы, шул исәптән үз җыры туа тора. Тик халкыбыз барыбер моңын, телен саклап калган. Өметле яшь җырчылар, моңлы тавышлар бар, шөкер!

Зөләйха Гатаулловнаны үз балаларыннан күп «урладык» без. Ул көне-төне эштә, консерваториядә иде, без – укучылары белән булды.

Мин бик бәхетле чорда эшли башладым. 1980 нче еллар башы – күп легендар җырчылар белән аралашырга, эшләргә туры килде. Җырчыларыбыз Хәйдәр Бигичев, Зилә Сөнгатуллина, Рафаэль Сәхәбиев, Клара Хәйретдинова, Айдар Фәйзрахманов, Равил Идрисов, Роза Үзбәковаларның шаулаган еллары. Сәнгать советлары (худсоветлар – авт. иск.) эшләп торган чор. Һәр җырыңны инә күзеннән үткәрәләр. Композиторлар берлегенең чәчәк аткан чагы, җырчының тавышына карап, махсус җырлар язалар…

Сәнгать советларын хәзер дә кирәк дип саныйм. Алар яшь җырчыларга зур ярдәм күрсәтте. Бүген дә сәнгать советларын кайтарып була дип саныйм. Медицинада лицензияләштерү дигән әйбер бар бит. Ә нишләп сәнгатьтә булмаска тиеш? Ул оешма җырларны кисеп утырыр өчен түгел, ә яшьләргә ярдәм итү максаты белән эшләде. Яшьләргә: «Бу композитор, шушы шагыйрь белән эшлә», – дип киңәш тә бирәләр иде.

Илһам Шакиров белән беренче очрашуым Казанның Пушкин урамындагы «Клуб госторговли» бинасында, концерт вакытында булды. Ул чакта Илһам абый репертуарындагы татар халык җыры «Җанкай-җанаш»ны җырладым. Концерт тәмамланганны да көтмичә, бөек җырчы яныма килеп, минем кайда, кемдә укуымны, кайсы яктан икәнлегемне сорашты. Җырда җибәргән хата-кимчелекләремне рәнҗетмәслек итеп, тыйнак кына санап китте. Тагын Илһам абый өстемдәге күлмәгемнең матур түгеллеген, костюмның да килешеп тормаганлыгын әйтте. Кая килешсен инде ул! Минем утыз җиделе муенга камыт кебек кидертелгән кырык икеле күлмәк. Тик башкасы юклыгын аңлатмадым да, акланмадым да, бары башым иеп тыңлап кына тордым. Чөнки аягымда Рәшит Сабировтан алып торган кырык икеле ярымитекне (мин утыз тугызынчы размер киям) дә күрер, дип курыктым.

Берничә ай узгач, Илһам абый белән бер концертта очраштык. Мин җырлаганда, пәрдә артында басып көтеп торган. «Улым, сиңа күлмәк алып кайттым. Иртәгә өйгә килеп алып кит әле, ярарга тиеш», – диде. Чехословакиядә тегелгән басылма якалы бу ап-ак күлмәкне кадерләп егерме елдан артык кидем…

Хәмдүнә апа белән бик күп гастрольләргә йөрергә туры килде. Союздаш республикаларга чыкканда, нишләптер Илһам абый гел икебезне алды. Хәмдүнә апа кызык, әчкерсез, та-

лантлы кеше иде. Әле менә гастрольдә йөргәндә булган бер очрак искә төште: Төмән–Мәскәү поездында кайтабыз. Купега, шар ярып, Хәмдүнә апа килеп керде. Без Әлфия Авзалова, Вафирә Гыйззәтуллина белән бер купеда идек.

– Сәлах, кызыл җебең бармы? Абзый синнән сорарга кушты. «Булса, Сәлахта гына бар», – диде. (Илһам абыйны «абзый» дип йөри идек.)

Бергә эшләгән бөекләрне саный китсәң, Гөлшат Зәйнашева турында әйтми кала алмыйм. Аның шигырьләре камил, үзләре үк җырлап тора. «Китмә, сандугач» – бу җырны чит җирләрдә яшәүче һәр милләттәшебез белә, күз яшьләре белән тыңлый. Көен Рөстәм Яхин язган. Гөлшат апа кеше буларак бик мәрхәмәтле, киңәш-табышлы, үзен яраттыра торган хатын-кыз иде. Аның белән гострольләрдә шактый йөрдек. Бәлки яшь җырчы булганга күрәдер, ул мине усал телләрдән саклап, яклап чыга иде. Ашарга булмаганда, кунакханәләрдә Гөлшат апа коймак белән күп сыйлады безне. Ә коймакны ул... үтүктә пешерә иде. Башта ике үтүкне кыздыра да, берсенең табанына коймак камыры сала. Камыр күперә башлауга, икенче үтүкне аның өстенә каплый. Коймак бик тиз пешеп чыга. Май булса, майлыйсың, булмаса, шул килеш тә бик тәмле бара. Хәтта шушы ысул белән кәтлитләр дә пешереп ашата иде ул. Табын янынннан: «Рәхмәт, Гөләни», – дип таралыша идек. Артистлар арасында кайгыртучан Ана булып яшәде ул. Шуңа күрә без Гөлшат апаны «Гөләни» дип йөрттек.

Үзгәртеп кору чоры башлангач, радио, телевидениедә дә үзгәрешләр башланды. Тарихыбызны, җырыбызны, шигъриятебезне бөтенләй оныта башладык. Консерватория, музыка училищесы, сәнгать академияләреннән чыккан махсус белемле сәнгатькәрләрнең тавышлары «неформат» булып, тарих шүрлегенә куелды. Хәер, мондый проблема Тукаебыз чорында да булган. Һәр заманның үз проблемасы, шул исәптән үз җыры туа тора. Тик халкыбыз барыбер моңын, телен саклап калган. Безнең заманда да әлеге проблема чишелер, дип уйлыйм. Өметле яшь җырчылар, моңлы тавышлар бар, шөкер! Дөнья аренасына чыгардай яшь җырчылардан Ярамир Низаметдиновны, Эльза һәм Артур Исламовларны, Алинә Шәрипҗанованы әйтә алам. Тагын Гүзәл Уразованы да әлеге исемлеккә кертер идем.

Бүген өметле яшь шагыйрьләр бар. «Кара әле, моңа бит романслар язып була», – дип уйлыйм кайчакта. Тик менә шул шәп шигырьгә көй язучы яшь композиторлар гына бик күренми. Урта буынга килгәндә... шигъриятне яхшы тоемлаучы Фирзәр Мортазин, Фәрит Хатыйпов бар. Шигъриятне белүче Марсель Иванов

бар иде, кызганыч, вафат инде... Апрель аенда филармониядә Хәсән Туфан кичәсен үткәрергә җыенабыз. Әлегәчә көй язылмаган шигырьләренә мөрәҗәгать итеп, яңа җырлар тудырырга телибез.

Әле күптән түгел генә 65 яшьне тутырдым. Шул уңайдан зал тутырып халык җыелды. Унтугыз җыр җырладым. Аллага шөкер, җырлый алам, дип сөенәм. Югыйсә сәламәтлек белән бәйле күп проблемалар булды... Тик барысын да җиңеп чыгарга Аллаһы Тәгалә көч бирде.

Мин беркайчан да диеталар тотып, ниндидер аерым көн тәртибе белән яшәмәдем. Әнкәем Зәйнәб әле 86 яшендә чардакта йөри иде. Нәселебез тиктормас, җитез безнең, куәсебез шундый...

АПАСЫ ФИРДӘВЕС ИСТӘЛЕКЛӘРЕННӘН...

«17 яшендә авылдан чыгып киткән егет безгә дә, әнкәйгә дә беркайчан мәшәкать ясамады, хәсрәт китермәде. Проблемалары булгандыр – сиздермәде. Үзе ач-ялангач студент елларында әнкәйне курчак кебек киендерде. Алай гына да түгел, 90 яшендә гөр иясе булган әнкәйне соңгы көннәренә кадәр үзе тәрбияләде. Безнең әнкәй затлы, хәлле нәселнең бик кадерле төпчек, иркә баласы булып үскән. Үзенә игътибарны яратты, көйсезләнгән чаклары да булгандыр. Әмма Фердинанд зарланмады, сабыр булды. Мин әнкәйне, авырып яткан-да, нибары ярты ел Мәскәүгә алып китеп тәрбияли алдым. «Апа, сиңа авыр була, үзем карыйм», – дип, миннән алып кайтып китте. Соңгы юлга әнкәйне Фердинанд фатирыннан бик зурлап озатып, туган авылга алып кайтып җирләдек. Әбиемнән, әнкәйдән догалы, хәерхаһлы теләкләр, бәхиллек алып калды ул». (2015 ел.)

Мәңгелек кыйммәтләр

Мәңгелек кыйммәтләр

Акыллы гамәлләр

Игелекле эшләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Татарстаннан читтәге татарлар **НИЧЕК** яши

Гүзәл Яхинаның «Сәмәркандка эшелон» романы **НӘРСӘ** турында

Йосыф Акчура татар тарихында **НИНДИ** эз калдырган

Кәгазь башмаклы авыл **КАЙДА** урнашкан

ТЫШЛЫ ТӘКМӘК СЕРЕ – БӘРӘҢГЕДӘ

Авторлар: Алсу Троицкая,
Олеся Бондаревская

Бу якларга өч йөз ел элек күчеп килгән Бәрәңге районы татарларының хәл-әхвәлләрен белешер, туган телне һәм гореф-гадәтләрне ничек саклауларын өйрәнер өчен, «Татарстан» күрше республикага юл тотты.

1931 елның апрелендә Мари Эл татарлары үтенече белән Татар районы төзелә. 1932 елда Татар районының исеме Бәрәңге районы дип үзгәртелә.

«БӘРӘҢГЕ» СҮЗЕ КАЯН АЛЫНГАН?

Риваятьтә әйтелгәнчә, «Бәрәңге» дигән атама «Беренгуйә» (фарсы телендә «Изгеләр авылы» дигән сүз) дип йөртелгән беренче торак пункт исеменә барып тоташа. Әмма Бәрәңге районының «Безнең тормыш» газетасы баш мөхәррире Фәнил Мусин фикеренчә, авылга исем янәшәдәге Бәрәнҗә елгасына бәйләп бирелгән булырга тиеш дигән фараз дөреслеккә якынрак кебек.

– Бәрәңге авылына 1550 нче елларда, руслар Казанны алганнан соңгы чорда нигез салынган дип санала. Әмма бер крестьян яшәгән һәм ясак түләп торган «Бәрәңге» торак пункты тәүге тапкыр 1699 елда телгә алына. Без бу язманы Алат юлының Бурыч кенәгәсендә таптык, – дип аңлата **Фәнил Мусин.**

Аның ерак бабалары – ясаклы Касыйм татарларыннан булган Мәмәтовлар нәселе – бу якларга XVIII гасыр башында килеп урнашкан һәм берничә авылга нигез салган. Редакциядә Мәмәтовлар шәҗәрәсе эленеп тора. Тамырлары – 1663 елда, ә ябалдашы –

2005 елда. Әңгәмәдәшем төрле тарихи тикшеренүләргә мөкиббән. Гомумән, бәрәңгелеләрнең аермалы ягы шунда: ике йөз ел элек, биш йөз ел элек булган нәрсәләр турында әле кичәге хәлләр кебек кенә сөйли ала алар.

– XIX гасыр башына кадәр «Параньга» архив документларында «Беренге» дип атала. Күпләр биредә бәрәңге үстергәннәр дип уйлый. Бу бик дөрес түгел. Мазарбашы авылы кешесе, туган якны өйрәнүче Наил Бариев мәгълүматларына караганда, безнең якларга бәрәңге беренче тапкыр 1842 елдан да иртәрәк килмәгән. Куныр авылына (хәзер Мазарбашы авылы, русчасы – Алашайка) аны Фәйзулла Гафтиев алып кайтып үстерә башлый, – дип сөйли Фәнил. – Бәрәңгенең җирле атамасы булмый, аны «Гафти шалканы» дип йөртәләр. Аны базарга алып чыга башлагач, товарның каян китерелүен сораштыра торган булганнар. Шул вакытта «Бәрәңге шалканы» дип җавап биргәннәр. Соңга таба «шалканы» төшеп кала. Шулай итеп, татар телендә бәрәңге безнең авыл исеме белән атала башлый, ягъни бәрәңге безгә түгел, без бәрәңгегә исем биргәнбез.

БУРАШ, ЧУРАШ ҺӘМ АЛАРНЫҢ НӘСЕЛЕ

Бәрәңге риваятьләре еш кына чып-чын булган хәлләрне бәян кыла. Мәсәлән, җирле халыкта: «Кабаланма, 60 яшьтә дә бала табалар», – дигән гыйбарә йөри. Мондагы төбәк тарихын өйрәнүчеләр, XIX гасыр метрикаларын тикшергәндә, Мазарбашында шундый бер гаилә яшәгәнлеген ачыклый: анда иргә – 35, хатынына – 72, ә кызларына 11 яшь була.

– 60 яшь турында әйтә алмыйм, ә минә әнием иң кечкенә сеңлебезне 46 яшендә тапты. Тагын шундый риваять бар: монда күчеп килгән беренче татар кешеләренең исемнәре Чураш һәм Бураш булган. Ә минем кыз фамилиям – Чурашева, – дип сөйли

Бәрәңгедә яшәүче **Фәүзия Мөхәммәтова.** СССР таркалганчы, ул парторг, район газетасы мөхәррире булып эшли. Соңыннан – ветераннар оешмасы рәисе, Бәрәңге тарихын теркәп баручы. Фәүзия ханым безгә үзенең дә өлеше кергән ике басма – районның тыл хезмәтчәннәре турында «Они ковали Победу» һәм «История сёл и деревень республики Марий Эл. Параньгинский район» китапларын күрсәтә.

Портянур авылындагы ФАП яңадан куллану проекты нигезендә төзелгән. Ул табиб килгәнче, кичектергесез ярдәм, шул исәптән ашыгыч акушерлык ярдәме күрсәтү өчен барлык кирәк-ярак белән җиһазландырылган. Әлеге ФАП Портянурның 800 дән артык кешесенә хезмәт күрсәтә. Стоматолог **Инзилә Мөхәммәтхановага** портянурлылар гына түгел, күрше-тирә авыл халыклары да бик шатланып килер иде – квалификациясе югары һәм, авыл кешеләре әйткәнчә, «кулы да җиңел».

– Үткәннәрнең барысы да бик тиз онытыла бара. Тел хезмәтчәннәре турында язганда, мәгълүматны бөртекләп җыйдык. Хәтта зиратлар буйлап йөреп, кешеләрнең яшәгән елларын язып алдык. Менә бу китапларыбыз – һәйкәлләргә тиң истәлек. Авылларның үткәне хакындагы басмада район яшәгән еллар дәвамында аның территориясенә кергән барлык 106 торак пункт искә алына. Хәзерге вакытта аларның 50се генә калды, – ди Фәүзия Мөхәммәтова. – Без бу китапны ике гасыр чигендә әзерләдек. Менә Фәнил Мусин аны үз хезмәтләре белән тулыландыра. Алга таба ни булыр? Кызык...

УРАКЧЫ КЫЗ

Бәрәңге районының Мазарбашы авылын таба алмыйча йөрмисең – аның юлын һәйкәл күрсәтеп тора. Постаментта исә кысып урак тоткан кулын өскә күтәреп торган кыз. Бу сынны мазарбашлылар тыл хезмәтчәннәре истәлегенә куйган. Республикада мондый бердәнбер һәйкәл ул.

– Мин үзем дә сугыш чоры баласы, 1942 елда туганмын. Әти фронтка киткән дә һәлак булган. Әни, апам, түтием хәлсезләнеп егылыр дәрәҗәгә җиткәнче басуда эшләгән. Сугыш вакытында алар шулай итеп Җиңүне якынайта, сугыштан соң – илне күтәрә. Минем кебекләр ул елларның нинди авыр чор булганын, ачлык-ялангачлыкны яхшы хәтерли. Бервакыт рәис урынбасары кырда черек бәрәңге җыйганым өчен чыбыркы белән эләктерде, – дип искә ала Мазарбашыннан **Рәис Салихов**. – Хуҗалыкны да, колхоз эшләрен дә тартып барып, көн-төн тылда хезмәт куйган хатын-кызлар булмаса, илебез җиңә алмас иде.

Бәрәңгелеләр «Уракчы кыз» дип йөрткән һәйкәл күбрәк әңгәмәдәшем тырышлыгы белән куелган дисәк тә була. Беренче тапкыр – 1980 елда. Ленин исемендәге колхоз рәисе Нурислам Фатыйхов, ул вакытларда баш инженер вазыйфасындагы Рәис Гаязович, Идрис Баһаветдинов, Гафифҗан Сабирҗанов, Илдар Әхмәтҗанов әлеге сынны булдыру башлангычы белән чыга. Еллар узу белән, һәйкәл таушала. Җил, кар, яңгырларның «Уракчы кыз»ны аяусыз талаганын күреп, Рәис Салиховның йөрәге әрни. Сынны колхоз куйдырган булгач, ул бернинди реестрларга да кертелмәгән, димәк, реконструкция өчен акчаны да беркемнән сорый алмыйсың. Җиңү-

“

Мазарбашы янәшәсендә – Куян авылы. Муса Җәлилнең булачак көрәштәше, немец әсирлегендәге яшерен оешма җитәкчесе Гайнан Кормаш шушы авылда мәктәп тәмамлый һәм 1937 елга кадәр укытучы булып эшли.

Хатиф Вафин авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү предприятиесен 30 ел җитәкли. Икмәк-күмәчләр моннан көн саен Мари Элның җиде районына – кибетләргә, балалар бакчаларына, мәктәпләргә һәм хастаханәләргә җибәрелә. Соңгы елларда предприятие продукциясенең таралу географиясе киңәя: аны Татарстан Республикасының өч районы ала башлый. – Икмәк пешерү – сүз өчен генә башкарыла торган эш түгел. Бар күңелне биреп кенә эшләп була! – ди Хатиф Гәрәевич. – Язмышым бик бәхетле юлдан бара: бизнесым гадел, якташлар табынына исә көн саен без пешергән табигый, бернинди химиясез ризык килеп тора...

Әлеге чал чәчле ир-атны бистә паркындагы променадта көн саен очратырга мөмкин. **Шамил Габдуллинны** Бәрәңгедә һәркем белә. Май аенда аңа 92 яшь тула. Аның бөтен тормышы туган җире белән бәйле. Әле малай чагында ук колхозда ат җигүче булып эшли. Лаеклы ялга исә район башкарма комитеты рәисе урынбасары вазыйфасыннан чыга. Озак вакытлар бистә советын җитәкли. Ул эшләгән чорда, 1978 елда, Совет РСФСР Күчмә Кызыл Байрагын яулый һәм ун мең сум премия белән бүләкләнә – анысы район үзәген төзекләндерүгә тотыла. Ветеранның мактаулы бүләкләре күп, әмма иң кадерлесе – беренчесе. Бу – «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы елларында фидакарь хезмәт өчен» медале. Габдуллин аны 15 яшендә ала.

нең 75 еллыгы алдыннан пенсионер абзый «Уракчы кыз»ны ничек тә булса саклап калырга карар кыла. Аның теләгән эре предприятие башлыгы – Салиховның Мәскәүдәге дусты һәм авылдашлары – кайчандыр сынны куюда тырышып йөргәннәрнең уллары күтәреп ала. Әмма профессиональ реставраторларны яллау өчен хәтта аларның ярдәме дә җитеп бетми. Эшләрне җирле осталар башкара. Әйтүләренчә, «Уракчы кыз» матуррак та килеп чыккан.

ТАБЫЛДЫК ЯРЫМАЙ

Рәис Салихов һәйкәл тарихын Мазарбашы Җәмигъ мәчетенең гыйбадәт залында сөйли. 200 ел элек мәчетне Йомышлы Оры авылының (хәзер – Татарстанның Арча районы Түбән Оры авылы) сәнәгатьче эшкуары, танылган хәйрияче Мөэмин Хуҗасәетов төзеткән, аны җирле сәүдәгәр һәм сәнәгатьче Мәмәтовлар белән туганлык мөнәсәбәтләре һәм эшлекле элемтәләр бәйләгән. Мазарбашы мәчете турында үз хезмәтләрендә Шиһабетдин Мәрҗани дә искә ала, аның сеңлесе җирле сәүдәгәрдә кияүдә була. Гыйбадәтханәдә 1935 елга кадәр намаз укыла. Соңрак исә хакимият Аллаһка ышануны тыю юлына баса.

– Манараны ярымае белән бергә кисәргә дигән фәрман килә. Бу эшне башкарырга алынган кяферләр дә табыла. Кискәндә, ай читкә егылып төшә. Әнә тегендә оча, – ди Рәис Салихов, тәрәзәдән күренеп торган ишегалдына ишарәләп.

Ул җирнең хуҗасы Гаяз Асапов кадерле ядкәрне табып, яшереп куя. Шул көннән соң мәчетнең ае турында мазарбашлылар «Аллаһ үзенә алды», – дип әйтә торган була. Совет елларында мәчетне ни рәвешле генә кулланмыйлар: монда складлар да була, колхоз идарәсе, тегү цехы, акушерлык пункты, хәтта электростанция дә урнаша. 1988 елда гына авыл халкы бинаны үзенең төп эшенә кайтаруга ирешә. Яңа ай белән манара күтәреп куела. Әмма Рәис Салиховны иске айның язмышы бик борчый. Асаповның улыннан әлеге иман символының сакланып калуын белгәч, Рәис Гаязович аны табу нияте белән яна башлый. Кишәрлектәге корылмаларны бер-бер артлы сүтәләр, әмма ядкәрнең эзенә төшә алмыйлар. 2018 елда Асаповлар нәселе иске гаражны сүтәргә керешә һәм югалган ай табыла! Рәис Гаязовичны чакырып, кадерле ядкәрне аңа тапшыралар.

– Без мәчеткә үз акчабызга һәм иганәчеләр ярдәме белән үзебез ремонт ясадык. Башта Мәдәният министрлыгы хуплаган иде, аннары төрле ризасызлык сүзләре ишетелә башлады, имеш, болдыр өстендәге түбәне алып ташларга, пластик тәрәзәләрне агачныкына алыштырырга кирәк, – дип сөйли Рәис Салихов. – Ә безгә кешеләрнең монда даими килеп йөрүе мөһимрәк. Без әле гыйбадәт залына пыяла витрина урнаштырып, иман ныклыгының һәрнәрсәдән өстен чыгу символы буларак теге ярымайны шунда куярга ниятлибез.

МАКСАТ – АВЫЛНЫ САКЛАП КАЛУ

Эшмәкәр **Фәдбир Хисмәтуллин** – Җәмигъ мәчетен торгызырга ярдәм иткән хәйриячеләрнең берсе. Берничә ел элек гаиләсе белән Ленин исемендәге колхозның җирләрен сатып алган ул. Кайчандыр илдә иң яхшылардан саналган алдынгы хуҗалыктан 90 нчы елларда бик аз нәрсә сакланып кала, ләкин Хисмәтуллинны бу туктатмый. Хәзер аның предприя-

тиесе хәләл ит продукциясен сәнәгать масштабында чыгара. Сатып алучыларның күбесе – Татарстаннан.

– Мин ике арада әллә ни аерма күрмим. Бәрәңге һәм Татарстан яшьләре табышып, гаилә коралар. Бу борын-борыннан шулай бара. Көндәлек аралашу телебез – татар теле. Без Татарстанның уңышларына бик сөенәбез. Казан юлында күп терлек асрый торган көчле хуҗалыклар күп, шуларны күрү дә бик күңелле. Калышмаска тырышабыз! – ди эшкуар. Аның предприятиесендә хәзер 30 кеше эшли.

– 90 нчы елларда эчүчелек тамыр җәйгән иде. Хәзер халык эчми. Мондый авыр заманда эчеп йөрсәң, бик тиз түбәнгә тәгәрәп төшәргә мөмкин икәнен кешеләр аңлый. Күпләр акча эшләргә Мәскәүгә китә иде, ә без колхозны сатып алганнан соң, монда эшкә урнаштылар, – дип сөйли Фәдбир Хисмәтуллин. – Әтиемне, аның яшьтәшләрен еш искә алам. Бүген һәр гаиләдә диярлек машина бар. Ә аларда нәрсә бар иде? Күп дигәндә – мотоцикл. Гаиләсен ашату, безгә бу җирне саклап калдыру өчен, алар иртә таңнан төнгә кадәр колхозда эшләде.

Эшмәкәр фикеренчә, яшьләр эш урыны булмаганга авылдан китә. Ул башка ике колхозны да сатып алып, яхшы хезмәт хакы түләнә торган эш урыннарын арттыру планнары белән йөри. Хәзер Мари Эл хөкүмәте дә авыл хуҗалыгына ярдәм итә башлаган. Авылга газ кергән, су белән дә тәэмин ителгән, уңайлы тормыш өчен бөтен шартлар бар. Фәдбир Хисмәтуллин Җәмигъ мәчетенә даими йөри. Гыйбадәтханәне төзекләндерү мәсьәләсеннән бигрәк, эшкуар аны карап тоту өчен борчыла.

– Безнең халык әнә нинди динле, социализм чорында да җимерелмәслек мәчет төзегән. Әмма мәчетне андагы хозурлык, матурлык түгел, ә анда йөргән кешеләр бизи. Динсез тормыш буш, мәгънәсез. Кеше иман белән яшәгәндә генә, тормыш максатын күрә, – ди ул. Хәзер Фәдбир Хисмәтуллинга 52 яшь. Гомер буе Мазарбашында яшәгән ул, китәргә җыенмый. Кешеләр гел шәһәргә китәргә омтылып тормаячак, дигән фикере нык. Аның кече улына – 5, ә кызына 2 яшь. Хисмәтуллинның максаты анык – авылны үз балалары өчен саклап калу.

2010 елгы халык санын алу нәтиҗәләре буенча Мари Элның Бәрәңге районында 22 милләт вәкиле яши. 14 мең кешенең 47,74%ы – татарлар, 43,15%ы – марилар, 8,06%ы – руслар һәм башка милләтләр.

БӘРӘҢГЕ ТАТАРЛАРЫНЫҢ ХӨРМӘТЛЕ РИЗЫГЫ

Бәрәңге районының мәдәният бүлеге җитәкчесе Наилә Гәрәева безне Яңавыл авылының «Ак калфак» фольклор коллективына кунакка алып килде:

– Сезгә үзешчән артистларыбызның җыр-биюен генә түгел, аларның нинди җирле, аутентик ризык әзерләвен дә күрсәтергә булдык. Без коллективта чыгыш ясаучы бер ханымның өенә барачакбыз. Алай күңелгә җылырак булыр. Коллектив җыелды инде, гармунчы да килде. Күңелегезне дә күтәрерләр, ашатып та җибәрерләр. Нәрсә инде ул клуб? Алар хәзер бөтен җирдә дә бертөрле – матур, җылы. Рәмзия ханым Гаязованың шундый тәмле ризыгын татып карарсыз, андыйны башка бер җирдә дә пешермиләр, чынлап әйтәм.

Инандык. Татар мичендә хуҗабикә **Рәмзия Гаязова** пешергән тышлы тәкмәк һәм балан бәлеше (балан катыгы) белән сыйланып ләззәтләндек. Әлбәттә, өстәл башка ризыклардан да сыгылып тора иде, әмма шул рә-

«Ак калфак» фольклор ансамбле.

ТАТАР ИЛЕ

вешле хәзерләнгән ике ризыкны нәкъ менә Бәрәңге татарларында гына авыз итеп була. Саранланып, яшереп тормыйча, безгә хәтта аларның рецептын да бирделәр, тик мәшәкате шулкадәр күп икән!..

– Ә менә Рәмзия аны эх дигәнче пешереп куя, – дип тынычландырды безне аның «Ак калфак» ансамблендәге дуслары җыр-биюләр арасындагы тәнәфестә. – Чыннан да, тәмле бит?

Тәмле генәме?! Иң гади продуктлардан ничек шундый тел йотарлык ризык китереп чыгарырга мөмкин, дигән соравыбызга йөзе мич янында кызарып киткән Рәмзия пышылдап кына җавап бирде:

– Бу эшне бик яратам мин. Һәм пешерә дә беләм.

ТАТУ КҮРШЕЛЕК – УРТАК ЭШ

Бәрәңге кебек күп милләтле районда милләтара татулыкны саклау һәм башка халыкларның гореф-гадәтләрен, мәдәниятен хөрмәт итү аеруча мөһим. Һәр халыктан өйрәнерлек нәрсәләр бар. Әйтик, аш-су мәсьәләсенә килгәндә, татарлар борын-борыннан камыр ризыклары белән дан тоткан. Гөбәдия, чәкчәк, бәлеш, коймак... Марилар һәм руслар күбрәк яшелчәләрне үз итә. Татарлар хәтта сугыш вакытында да гөмбә җыймаган – агуланудан курыкканнар. Хәзер биредә яшәүче һәр татар гаиләсенең табынында тозланган кыярын-кәбестәсен, гөмбәсен күрә алабыз, өстәвенә мондагы урманнарда гөмбә бик күп һәм бик төрле. Җирле татарлар әлеге гастрономик гореф-гадәтне марилар белән руслардан үзләштергән, үз чиратында тегеләрне ат ите ашарга өйрәткән. Сүз уңаеннан, Татарстанның чиктәш районнарын да ат итенә «күнектергән». Казылык турында да онытмыйк. Телеңне йотарлык итеп ясыйлар аны монда. Бәрәңгелеләр кунакка киләсе булса, алардан: «Үзегезнең казылыкны алып килегез», – дип сорыйлар икән. Көнкүрештә дә милләтләрнең үзара йогынтысы сизелә. Татарлар элек-электән яхшы, ныклы йорт, матур койма һәм капкалар, чиста урамнар һәм ишегаллары белән аерылып торган. Хәзер марилар аларны уздырып җибәрә, аларның авыллары еш кына татарныкыннан да матуррак, төзегрәк...

ТУГАН ТЕЛЕМ – ИРКӘ ГӨЛЕМ

Әйе, Бәрәңге районында элек-электән төрле халыклар иңгә-иң яшәгән. Бай милли төрлелек берничә гасыр дәвамында матди мәдәният һәм декоратив-гамәли халык сәнгатенең үзенчәлекләрен билгеләгән. Ләкин монда татар теленең саклануына үз милләтең кешесе белән гаилә кору гадәте аеруча уңай йогынты ясаган. Әле күптән түгел генә катнаш никахлар биредә бөтен авылда гыйбрәт итеп сөйләнә торган бер фаҗига дип саналган дисәк арттыру булмас. Дөрес, хәзер бу мәсьәләгә караш бераз йомшарды. Ярар, өйләнешкәннәр икән инде, яшәсеннәр. Яхшымы ул, начармы, без хөкем итәсе түгел. Бәрәңге районы хакимияте башлыгы **Әлфит Ибраев** та шундый фикердә. Ләкин өйләрендә алар гаиләсе, әйтик, татарча гына сөйләшә:

– Казаннан безгә кунакка кайткан оныклар да шулай. Ә хәзер күңелсез нәрсә турында әйтим. Казандагы оныгымның олысы мәктәпкә укырга кергәнче йөргән балалар бакчасында 180 баланың икесе генә татар телендә шигырь сөйли алган. Башка берәү дә юк. Йөрәк әрниме? Әлбәттә! Бәрәңгедәге балаларның 100%ы татарча сөйләшә дип әйтә алмыйм, ләкин күпләренең татарча белүе хак. Балаларыбыз төрле телдә бик җиңел сөйләшә. Әмма бездә һәрнәрсә дә бик шәп дигән сүз түгел. Ни аяныч, замана гаджетлары үз эшен эшли. Бүген хәтта авылларда да балалар, туган телләрен онытып, үзара русча аралаша башлый.

– Глобальләшү процессы, ни кызганыч, тел югалуга китерә. Ә телне югалтуга, халык бетә. Ул хәлгә калмаска иде. Без үзебездә гореф-гадәтләрне, телебезне сакларга тырышабыз, моның өчен беренче чиратта авылның яшәргә тиешлеген аңлап эш йөртәбез, – ди **Әлфит Ибраев.**

БЕР ГАИЛӘ БУЛЫП

Бәрәңге районы хакимияте башлыгы Татарстандагы барлык зур чараларда катнаша. Һәм һәрвакыт диярлек туган тел турындагы мәсьәләнең үзәктә булуын күрә:

– Марилар өчен дә актуаль ул. Глобальләшү процессы, ни кызганыч, тел югалуга китерә. Ә телне югалтуга, халык бетә. Ул хәлгә калмаска иде. Без үзебездә гореф-гадәтләрне, телебезне сакларга тырышабыз, моның өчен беренче чиратта авылның яшәргә тиешлеген аңлап эш йөртәбез...

Бүген Бәрәңге халкы җанисәпкә әзерләнә. Милләтләр хакында җыелган мәгълүматлар уку-укыту программаларының нәтиҗәлелеген бәяләргә, туган телне укытуга һәм милли мәктәпләргә ихтыяҗны ачыкларга мөмкинлек бирер, дип өметләнә. Мондый күпмилләтле район өчен бу бик мөһим, дип саный Әлфит Габделхакович:

– Әгәр дә миннән Бәрәңге районын бер җөмлә белән тәкъдим итүемне сорасалар, күп милләтле хезмәт сөючән халык яши торган урын, дип әйтер идем. Татарлар, марилар, руслар – барысы бер гаилә кебек. Үз гомеремдә милләтара ызгышның бер очрагын да хәтерләмим. Без моның белән горурланабыз, гасырлар буе җайланган, корылган мөнәсәбәтләрне саклыйбыз.

Бәрәңгедә хәтта Сабантуй да мариларның Пеледыш пайрәме һәм русларның Каен бәйрәме белән бер көнне үткәрелә. Берьюлы өч милли бәйрәм кунаклар күңеленә бик хуш килә, ә алар күрше Татарстаннан аеруча күп килә.

ПЕДАГОГИК СӘФӘР

Аның бу гамәле бездә аеруча зур кызыксыну уятты. Ник әле адәм баласы озын-озак еллар яшәгән, җайлаган урыныннан җен олаккан тарафка күченергә карар кылган?

Әлфия Фәйзрахманова Мари Эл Республикасының Бәрәңге районыннан Чукоткага күченгән. Мондагы башлангыч мәктәптә балалар укыту өчен.

– Вакансияләр һәм шактый яхшы хезмәт хакы бар иде, – дип аңлатты чыбыкның Казаннан мең чакрым ераклыктагы аргы очыннан аның арыган тавышы.

Арыганлыгын җиңел аңлатып була: вакыт аермасы – 9 сәгать. Хәзер Чукотка районының Лаврентия авылында инде төн уртасы узган. Әмма күңелгә якын татарча сүзләр ишеткәч, Әлфия җанланып китте:

– Чукча балаларына татар халык авыз иҗатын һәм телен өйрәтермен дип, берничә ел элек күз алдына китерә ала идемме? Юк, әлбәттә. Әмма бу хак. Җирле мәктәпләрнең җиһазлар белән тәэмин ителеше миндә бик уңай тәэсир калдырды: биредә бөтен нәрсә укытучыларга да, укучыларга да кулай булсын өчен эшләнгән. Ләкин шунысы аеруча гаҗәпкә калдырды: чукча балалары туган телләрендә бөтенләй сөйләшми диярлек. Ике тел – русча һәм татарча белүемне ишеткәч, күзләре маңгайга менде. Биредә чукча теле укытучылары коточкыч дәрәҗәдә җитми, ә гаиләдә һәм көнкүрештә русча сөйләшәләр. Кыскасы, чукча теле, никадәр кенә кызганыч булмасын, юкка чыгып бара. Минем туган ягымда мондый хәл булмас дип ышанасы килә. Бәрәңге районындагы һәр татар баласы диярлек туган телен һәм әдәбиятын белә. Ә туган телне ничек өйрәнәләр? Берничек тә. Эшнең асылы бик гади – ул телдә сөйләшәләр. Һәрвакыт. Бу – норма.

Әлфиянең укучылары татар мәдәнияте белән үзләре кызыксына башлый. Барысы да бер кызга шәхси дәрес бирүдән башлана, аның әнисе татар булып, кызының туган телне онытуын теләмәгән. Аннан тумышы белән Казаннан булган тагын бер укучы барлыкка килә. Һәм менә инде түгәрәккә 13 бала йөри – чукчалар һәм руслар. Әкиятләр, мәкальләр, көнкүреш әйберләре һәм гореф-гадәтләре, ә иң мөһиме уен белән катнаштырылган татар җырлары – тел өйрәнү дәресләре нәкъ менә шулай оештырыла. Педагог фикеренчә, нәкъ менә уеннар аның укучылары өчен иң яхшы «кулланма» булып тора.

– Балаларга, беренче чиратта, кызыклы булырга тиеш. Аларның башында белемнәр кызыксынучанлык нәтиҗәсендә барлыкка килә. Алар уен белән, читтән басым тоймыйча, үз сорауларына үзләре җавап тапканда, шуннан шатлык тойганда, дөньяны танып-белә, яңаны үзләштерә. Шулай итеп, без алар белән чукот телен дә, татарчаны да өйрәнәбез. Шуны да искә алыйм: балалар сүзне бик яхшы сизә. Хәзер Муса Җәлил иҗаты буенча март аенда узачак фәнни-гамәли конференциягә әзерләнәбез. Онлайн режимда булса да, без анда катнашачакбыз. Өч ел элек ясаган тәвәккәл адымым бүген бөтенләй көтелмәгән нәтиҗәләргә китерә булып чыга.

P.S. Бәрәңге районы һәм Татарстан бер-берсеннән ерак булса да, һәрчак тыгыз бәйләнештә – бу борын-борыннан шулай килә. Элекке вакытлардагы кебек, Бәрәңге районы һәм Татарстан яшьләре табышалар, гаилә коралар, Бәрәңге эшкуарлары республикабызда үзләренә сатып алучылар таба, безне туган тел һәм мәдәниятне саклау мәсьәләсе бер үк дәрәҗәдә борчый. Без һәрвакыт иңгә-иң атлыйбыз...

Әлфия Фәйзрахманова Мари Эл Республикасының Бәрәңге районыннан Чукоткага күченгән. Мондагы башлангыч мәктәптә балалар укыту өчен.

facebook.com/protatarstan

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

twitter.com/protatarstan

instagram.com/protatarstan

Реклама 16+

БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

УЗЫП БАРУЧЫ КЫШНЫҢ «МИНУСЛАРЫ»

Ни өчен мәктәптә «Җәйне ничек үткәрдем» дигән инша борын-борыннан елның иң җылы фасылына багышланган? Чөнки дүрт ел фасылын да белгәннәргә җәй аеруча матур булып тоела – ягымлы кояш, рәхәт һава, җылы су, өф итүгә очып китә торган тузганаклар, ап-ак ромашкалар, бакчадагы кыяр-помидорлар, ял, каникуллар. Һәм урамда һәрвакыт «плюс» тора. Шәп вакыт! Ләкин безнең киңлекләрдә кыш та матурлык ягыннан калышмый, бигрәк тә быелгы шикеллесе – кояш, аяз күк, боз, суык, кар-бураннар, чыршы бәйрәмнәре, каникуллар... Һәм урамдагы даими «минус». Күзләр камашырлык! «Татарстан» гаделлекне торгызу максаты белән мәҗбүри өй эше итеп бирелмәгән «Кышны ничек үткәрдем» темасына үз иншасын яза.

Асылда аны «Татарстан» фотографлары яза, бу кыш аларга үзен аеруча яхшы сиздерде. Фотоаппаратларында карлы декабрь, салкын гыйнвар һәм буранлы февраль төшкән кадрларны өшегән бармаклары белән актара-актара: «Кыш шәп быел!» – дип елмая алар.

Проект авторлары: Александр Ефремов, Александр Гәйнетдинов

ДЕКАБРЬ –22°

САБА РАЙОНЫ.

САБА УРМАН ХУҖАЛЫГЫ.

Иң әкияти чыршылар...

ГЫЙНВАР –38°

ЯШЕЛ ҮЗӘН РАЙОНЫ.
ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛЫ.

в 2020 ух

ФЕВРАЛЬ –26°

МАМАДЫШ. SUNNYFEST-2021





P.S. «ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫННАН ҖЫЛЫ КҮЧТӘНӘЧ

Быелгы салкын кышта иң җылы бүләк – «Татарстан» журналыннан Татарстан символлары төшерелгән киез итекләр – Чаллының «Машина времени» командасына эләкте. SunnyFest-2021 креатив чаналар фестивалендә Станислав Бывальцев һәм Сергей Григорьев юл-патруль хезмәткәрләре образында «Куып бару» дип исемләнгән иң кызыклы сюжетны тәкъдим итте. Фанерадан ясалган юл-патруль хезмәте машинасы «кара бандит» «Мерседес»ны таудан куып төшә. Кара битлекле «җинаятьчеләр» (аларның ролен «гаишник»ларның балалары башкарды) ата-ата кача... Шарт-шорт атышу, төтен, куа бару, авария... Чаналар әйләнеп каплана һәм «җинаятьчеләр» үзләрен әле яңа гына эзәрлекли килгән автомобильне таудан этеп чыгарырга булыша.

– Туйдырды бу коронавирус, – ди шат күңелле Чаллы егетләре. – Нинди дә булса кызыклы нәрсә уйлап табасы килде. Менә уйлап таптык та! Киләсе елга тагын да үзенчәлеклерәк берәр нәрсә ясап карарбыз. Безгә кабатлану хас түгел! Шаккатырып торачакбыз!

ШӘФЫЙКА КОТДУСОВА: «СӨЕП ҺӘМ СӨЕКЛЕ БУЛЫП ЯШӘДЕМ...»

Автор: Ландыш Әбүдәрова

Фотолар Филүсә Арсланованың «Шәфыйка Котдусова» китабыннан алынды

1940 елның 8 ноябрендә Акмәчет (Симферополь) шәһәреннән поездда Казан вокзалына килеп төшкәндә, Шәфыйка Котдусованың кулында музыка училищесы дипломы белән бер чемодан гына була. Йөрәгендә – опера җырчысы булу хыялы. Хыял дигәнең шулкадәр көчле ки, ул бирегә, ире Абдраимны, уллары Җәвит белән Эрнстны вакытлыча Кырымда калдырып, икеләнүләрен, шик-шөбһәләрен җиңеп килде, димәк, ялгышырга хакы юк. Күр, әнә Казан ничек каршы ала аны: урамнарда кичәге бәйрәм шаукымы дәвам итә – музыка, транспарантлар, Ленин, Сталин, Ворошилов, Молотов, Каганович, Берия һ.б. юлбашчыларның портретлары җилферди... Әйтерсең лә, Нежданов, Собинов, Шаляпин җырлаган сәхнәләр аны күптән көткән, зур вәгъдәләр биреп, үзенә дәшә...

БЕЛЕШМӘ

Шәфыйка Котдусова, җырчы (лирик-колоратур сопрано), 1910 елның 18 мартында Таврия губернасының Акъяр (Севастополь) шәһәрендә туа.
1931–1941 елларда – Керчь һәм Симферополь шәһәрләрендә радио концертмейстеры һәм Кырым татарларының җыр һәм бию ансамбле солисты.
1941–1951 еллар – Татар опера һәм балет театры солисты.
1951–1954 елларда Татар филармониясе солисты.
1954–1956 елларда – Олег Лундстремның джаз коллективында җырчы, СССРның Москонцерт оешмасы солисты, Татар эстрада бригадасын оештыручы.
Төп эшләре: Н. Җиһановның «Алтынчәч» операсында Алтынчәч партиясе, Җәүдәт Фәйзинең «Башмагым» музыкаль комедиясендә Сәрвәр, Дж. Россининың «Севильский цирюльник» операсында Розина, М. Юдинның «Фәридә» операсында Фәридә партияләре һ.б.
ТАССРның атказанган артисты (1950 ел).
1956 елның 18 апрелендә Мәскәүдә вафат була.

КИСЕЛГӘН ӨМЕТ: АЛТЫНЧӘЧ

Гәрчә татар совет опера сәхнәсенең үзенең дә эле түл җыйган мәле. 1925–1930 нчы елларда Солтан Габәшинең «Сания», «Эшче» опералары язылу, Салих Сәйдәшевнең музыкаль драмалары куелу татар мәдәниятендә беренче опералар барлыкка килүгә юл сала. Ул чорда үзеңнең милли опера сәнгатенә ия булу мәдәни яктан җитлеккәнлекне раслый торган критерийларның берсе санала, татар профессиональ музыка сәнгате барлыкка килгәнгә дә ярты гасыр. Салих Сәйдәшев, Мансур Мозаффаров, Җәүдәт Фәйзи, Заһид Хәбибуллин кебек олы композиторлар иҗат итә. Боларның нәтиҗәсе – ТАССР Халык комиссарлары советы 1934 елда Казанда опера һәм балет театры оештыру турында карар кабул итә. Бер төркем иҗатчы Мәскәүдә укый башлый. 1939 елның 17 июнендә ул Нәҗип Җиһановның «Качкын» операсының премьерасы куела.

Яңа тормыш төзүчеләрнең планнары зурдан: Казан 1941 елда Мәскәүдә узарга тиешле Татар сәнгате декадасына әзерләнә. Анда, һичшиксез, музыка сәнгатенең тагы – опера да күрсәтелергә тиеш. Мәскәү тамашачысы өчен Җиһановның Муса Җәлил либреттосына иҗат иткән «Алтынчәч» операсы сайлап алына. Дөресрәге, Җәлил либреттоны Мәскәүдән үк язып алып кайта һәм яшь композиторга ышанып тапшыра. Алтынчәч партиясенә Советлар Союзының төрле почмакларыннан килгән җиде вокалистка дәгъва итә. Шәфыйка Котдусова да алар арасында.

Дөресрәге, Шәфыйканы бу рольгә чакырып китерәләр. 1940 елда Кырымга Җәүдәт Фәйзи җитәкчелегендә музыкантлар төркеме килеп төшә. Максатлары -булачак декадага опера җырчылары эзләү. Комиссия Кырымның җыр һәм бию ансамбле солисткасы, түгәрәк йөзле, кыйгач кашлы, лирик-колоратур сопрано тавышлы Котдусованы сайлап ала.

Казанга килгәннең икенче көнендә үк ул опера һәм балет театрына ашыга. Туп-туры директор Ильяс Әүхәдиев кабинетына килеп керә. Ә анда җиде ир-егет һәм үз-үзен шактый кыю, хәтта тәкәббер тоткан бер хатын-кыз була. Заһид Хәбибуллин рояльдә уйный, Шәфыйка аларга җырлап күрсәтә. Барысын да ошаталар, әмма мишәр акцентын сәбәп итеп, Шәфыйканы кире боралар...

Шәфыйка ире Абдраим, улы Җәвит белән. 1930 ел.

Филармония директоры Абдуллиннан янә Казанга чакырып, хат килгәнче, айлар уза. Бу айларны нинди авыр хисләр белән үткәргәндер, әмма хат килүгә, Шәфыйка ханымның күзләрендә яңадан очкын кабына. Бу юлы инде алар гаиләләре белән татар мәркәзенә күчеп килә. Икенче көнне алар урнашкан «Совет» кунакханәсендәге номерларының ишеген икәү килеп кага. Яшь җырчы аларның берсен таный – Абдуллин, ә икенчесе үзен «Җиһанов» дип таныштыра.

-Мин сезне ноябрь аенда ук ошатып калган идем, Алтынчәч партиясен сез генә башкара алыр идегез, – дип мөрәҗәгать итә яшь композитор Шәфыйкага. Шул ук көнне Котдусованың опера һәм балет театрында эшләячәге хәл ителә, һәм хыял сәхнәсенә Алтынчәч образында аяк баса ул.

– Сез, Шәфыйка ханым, чишмә суы кебек саф кыз бала образын уйнарга тиеш, ул менә-менә чәчәк атарга әзерләнгән ак чәчәк бөресе кебек, – дип, киңәшләрен бирә аңа Җиһанов һәм рояльдә уйнап

Шәфыйка Котдусова Джильда ролендә («Риголетто» операсының афишасы).

күрсәтә. Тирә-як язгы кояш нурларына күмелгәндәй була. Шәфыйка ханым үзенең Алтынчәченең гүзәллеген шунда ук тоемлап ала.

«Алтынчәч» операсының беренче составында Алтынчәчне -Галия Кайбицкая, Җикне Нияз Даутов башкара, Шәфыйка Котдусова белән Фәхри Насретдинов икенче составка билгеләнә. Репетицияләр дәвам итә, 17–18 июнь көннәрендә театр ачылышының ике еллыгын билгеләп үтә, анда «Алтынчәч»нең Мәскәүдә куярга әзер булуы игълан ителә. Әмма дүрт көннән соң башланган Бөек Ватан сугышы бөтен планнарны, өмет-ышанычларны сызып ташлый. Декада турында да онытырга туры килә.

Шулай да сугыш башланып, 20 көн узгач, Казанда «Алтынчәч»нең премьерасын уздыралар. Җәйге Казан бу вакытта сугышның ни дәрәҗәдә дәһшәтле булуын эвакуацияләнеп килгән кешеләрдән генә ишетеп белә. Сугышны дүрт елга сузылыр дип, берәү дә уйламый, әлбәттә. Өченче сезон, дүртенче сезонда да Шәфыйка Алтынчәчне җырлый, «Башмагым»нан Сәрвәрне, Кави Нәҗми либреттосына эвакуациягә килгән композитор Михаил Юдин иҗат иткән «Фәридә» операсында Фәридәне һәм башка партияләрне өйрәнә. Җиһановның «Түләк» операсындагы Су-Сылу партиясенә әзерләнә башлый. Иренең һәлак булуы турындагы хәбәрне алган көнне дә сәхнәдә була ул. Кара кәгазь килгән көнне Шәфыйка «Башмагым»дагы Сәрвәрне уйнарга тиеш була. Бик дулкынланып, бөтен составны үзе артыннан ияртеп башкара ролен. Дошманга үч итеп, нәфрәт белән...

АКЛАНМАГАН ӨМЕТ: АВТОБИОГРАФИЯ

Көннәрдән бер көнне 1944 елның апрель ахырларында Шәфыйканы театрның музыка җитәкчесе Нәҗип Җиһанов кабинетына чакырып ала һәм аңа республиканың атказанган артисты исеме бирү турында документлар җыя башларга кирәклеген әйтә. Шул көнне артистка Кырым АССРның Югары Советыннан да Симферополь театрына чакыру алган була. Һәм куанычыннан дулкынлана-дулкынлана автобиографиясен язарга утыра.

Совет чорында автобиографиядән дә кыйммәтлерәк документ булдымы икән? «Гади крестьян гаиләсеннән» яки «пролетариат баласы» дигән сүз урынында башка төрлерәк социаль статус торганда, аның бәһасе гомер белән, озакка сузылган ГУЛАГ еллары белән үлчәнгән очракларның да бихисап икәнлеген яхшы беләбез. Менә тагын... 1944 елның маенда ул туган җире Кырымдагы коточкыч фаҗигаләрдән бихәбәр булып, тормыш юлын кәгазьгә төшереп утыра.

1910 елның 18 мартында Акъяр (Севастополь) шәһәре мулласы Йосыф Рәхимовның ишле гаиләсендә бер кыз бала туа. Җиде бала үсә алар. Алтынчы булып туган сабыйга Йосыф әфәнденең якын дусты, аркадашы Исмәгыйль Гаспралының кызы хөрмәтенә Шәфыйка дип исем кушалар. Кечкенәдән җыр-моңга һәвәс булып үсә кыз. «Тәфтиләү», «Тукай марш»ларын һәр кичне гаилә концертларында җырлый торган була. Әтисе кызының музыкага җитди мөнәсәбәтен күреп, аңа музыка дәресләре бирү өчен поляк кызы Остроменская Елена Францевнаны яллый. Шопен, Чайковскийларны фортепианода уйнарга бергәләп өйрәнәләр һәм озакламый шәһәрдә концертлар бирә башлыйлар. Үзенең тамашачылары барлыкка килү Шәфыйкага канатлар куя – үзенең музыка укытучысы Ленапа киңәше белән ул Мәскәү консерваториясенә

Шәфыйка Котдусова. 1940 ел.

М. Юдинның «Фәридә» операсы. Шәфыйка Котдусова (Фәридә ролендә) һәм Кәшифә Шәмсетдинова.

укырга керергә карар кыла. Әнә шунда 1925 елның 9 июлендә дә бер автобиография язган иде ул. Кабул итү комиссиясе алдында Чайковскийның «Баркарола»сын уйнап күрсәтеп, комиссия әгъзаларын таң калдырса да, «пролетар чыгышлы булмаганы өчен» аны кире борганнар иде...

Мәскәү Шәфыйканың ышанычын акламаса да, җыр һәм театр сәнгате турындагы хыял канатларын кисә алмый. 1926 елда Акъяргa беренче гастрольләре белән Кырым Татар театры килгәч, ул вакытта әле Рәхимова театрга гашыйк була. Әтисе белән әнисенә үзенең артистка буласы килүен әйтүгә, Йосыф мулла театрның сәнгать җитәкчесе Җәләл Маиновны өйләренә кунакка дәшә. Шунда Акъярда да драма түгәрәге оештыру турында сүз куешалар. Түгәрәкне абыйсы Камил Рәхимов җитәкли, музыка җитәкчесе Ленапа – Елена Францевна була. Җәләл Маинов аларга азәрбайҗан драматургы Узеир Гаджибәковның «Аршин мал алан» пьесасын алып килә. Акъяр тамашачысы Шәфыйканың Гөлчәһрәсен аеруча яратып кабул итә. Тамашачылар арасында булачак ире – Абдраим Котдусов та булган икән. Көннәрдән бер көнне спектакльдән соң өенә кайтып барганда, аны Абдраим куып тота да үзе гашыйк булып өлгергән «Гөлчәһрә»гә шунда ук кияүгә чыгарга тәкъдим ясый. Йосыф Рәхимов кызының ВКП(б) әгъзасы булган кызыл большевик Абдраим Котдусовка кияүгә чыгуына каршы була. Әмма кыз һәрвакыттагыча карарында нык тора, һәм мулла әтисенең яшь парга качып кына никах укудан башка чарасы калмый. 1928 елда Котдусовларның уллары Җәвит, 1934 елда Эрнст туа. Шул рәвешле Шәфыйка бөтенләе белән гаилә мәшәкатьләренә чума, көннәрен кечкенә улларына багышлый: көн саен диңгездә коендырырга алып бара, җырлар җырлый, дөньяның матурлыгына сабый күзләре белән карап, аны яңадан ача. Әмма сәхнә тәмен татып өлгергән, җыр-моң дәрьясында йөзгән, иҗат дөньясында яшәгән Шәфыйканың күңеле ире яшәгән Керчька гына сыеша алмыйча, еракларга – йолдыз биеклегенә ымсына...

Менә аның хыялы тормышка аша: 1936 елда ул Симферополь музыка училищесына берьюлы ике – вокал һәм фортепиано бүлекләренә укырга керә. Бу юлы «Котдусова» фамилиясе белән язылган автобиографик анкетасында әтисен -«каравылчы», әнисен «хуҗабикә» дип күрсәтә. Ә нигә? Тырнак очы кадәр дә ялган юк монда: энциклопедик белемле, Коръән белгече, француз, гарәп һәм башка телләрдә иркен сөйләшә белгән Йосыф Рәхимов чыннан да уен кораллары остаханәләрендә каравылчы булып эшли, алты ел элек инде аның мәчетенең манарасын кистеләр, үзен муллалыктан алдылар. Иренең дә рәсми хакимият белән каршылыкка кергән чагы Абдраимның яшь чагында ук әле революциягә каршы булган әтисе Котдусны большевиклардан яшереп җирләве ачыкланып, аны да партиядән чыгаралар, ул эш эзләп, эзәрлекләүләрдән качып, Мәскәүгә китә.

1940 елның 7 августында Котдусова җырчы дипломы белән Кырым радиокомитетына эшкә урнаша. Шунда эшләгән вакытта аны Җәүдәт Фәйзи күреп, Казанга чакыра да инде...

СОҢГЫ ӨМЕТ: МӘСКӘҮ

Милли операларда төп партияләрне генә башкарса да, Шәфыйка Котдусованың репертуарында дөнья классикасы бик аз була. Ә моның өчен белемнәрне тирәнәйтергә, тәҗрибә тупларга кирәк. Җиһанов аңа консерваториядә укып чыгарга киңәш бирә. Шулай итеп, 38 яшендә Шәфыйка Котдусова студент булып китә һәм, өч ел эчендә программаны үзләштереп, 1951 елда аны тәмамлый.

Нәҗип Җиһановның «Алтынчәч» операсы. Алтынчәч ролендә – Шәфыйка Котдусова. 1941 ел.

Эш белән уку, уку белән өй арасында йөгереп, ул театрда үзенә карата мөнәсәбәтнең үзгәргәнен, алай гына да түгел, суынып киткәнен сизмәгән дә икән. Спектакльләргә сирәгрәк куя башлаганнар, репетицияләре дә азайган икән бит аның. Ишетмәгән дә, артыннан «кырым татары» дип сөйләнеп калалар түгелме соң? Бик күпләре аның белән очрашмаска тырышып урап уза...

Кырымнан булса да, Кырым татары түгел ул югыйсә. Әтисе – Буа яклары мишәре. Хәер, 1936 елда радиодан Сталинның яңа Конституцияне укуын тын да алмый, якты киләчәккә өмет итеп тыңлаганнар иде. Ул вакытта Сталин социалистик система җиңеп чыкты, хәзер һәркем азат, һәркемнең үзе теләгәнчә яшәргә хакы бар, дип сөйләгән иде. Шул ук елның 12 декабрендә әтисе Йосыф мулланы алып киттеләр, ул лагерьда вафат булды. Әнисе Фатыйма 1937 елда кызы Шәфыйка янына күчеп килде. Әле кайчан гына социаль чыгышы аркасында булган мөмкинлекләрдән колак кагарга туры килгән иде, менә хәзер милләте өчен дә җавап тотасы була микәнни? Ире – Кырым татары Абдраимының кара кәгазенә «Совет илен фашист илбасарларыннан азат итү өчен сугышта батырларча һәлак булды» дип язылган. Улмы соң инде хыянәтче, йә? Улларын ниләр көтә икән? Шундый шөбһәле уйлар белән яшәгән көннәрдә аңа ТАССРның атказанган артисты исемен биреп куялар. Әмма шатлыкның төсе уңган була инде: шушы истәлекле көннән соң барыбер аңа Алтынчәчне дә, дөнья классикасы партияләрен дә башкарырга туры килми. 1951 елның 20 декабрендә атказанган җырчыны театрдагы вазыйфасыннан азат итәләр. Әйе, «азат итәргә», дип язылган була боерык кәгазендә.

Шәфыйка Котдусова әнисе һәм улы Җәвит белән.

Шуннан соң Шәфыйка Котдусова бик озак авырый, тавышын югалта. Әмма өметен өзми һәм Мәскәүгә дәваланырга китә. Озакламый ул Мәскәүдә Салих Сәйдәшев концертында «Наемщик»тан Гөлйөзем ариясен башкара. Биска җырлаталар. Концерттан соң, Салих Сәйдәшев аның янына килеп рәхмәт әйтә. Шул бәйрәмнән аны Алексей Мамай – Шәфыйка Котдусованың булачак икенче ире озата кайта. Алексей Мамай Котдусова әле йолдыз булганчы ук аның иҗатына гашыйк зыялы бер кеше була. Бу концертка да афишада аның фамилиясен күреп килә. Узган очрашуда Котдусова ирле хатын булса, бу юлы Алексей Григорьевич бәхетен кулыннан ычкындырмый. Уллары да, әнисе дә бу никахка фатихаларын биргәч, 1953 елда ул Мәскәүгә күчеп килә. Талантлы җырчыны тиз генә эшкә алмыйлар. Олег Лундстремның джаз коллективында җырлап йөри, бары тик вокалистлар конкурсында җиңү яулагач кына, Котдусова Москонцерт оешмасына эшкә урнаша ала. Анда татар эстрада бригадасын оештыра. Бригада белән күп шәһәрләргә гастрольләргә чыга.

1953 елда аны Казанга «Алтынчәч»не яздырырга чакырып алалар. Теге вакытта аны театрдан җибәрүгә үз өлешен керткән дирижер Исаак Шерман нинди талантны кулдан ычкындыруын шунда гына аңлый. Шул ук елны СССР халкы Сталин белән хушлаша.

1954 елда яман шеш авыруына операция ясатканнан соң, Салих Сәйдәшев вафат була. Шәфыйка аның янына хәлен белергә барып йөри торган була. Салих абыйсы аннан Гөлйөзем ариясен җырлата.

1955 елның августыннан 1956 елның февраленә кадәр Шәфыйка Котдусова туксан концерт бирә... Ә 18 мартта аның туган көне була. Шул көнне авыруы үзен каты сиздереп, аны Склифосовский хастаханәсенә салалар. Яшәү дәрте, иҗат нуры белән янып торган Шәфыйка сөекле ире Алексейны да, улларын да, дусларын да «яшим әле» дип тынычландыра. Үлем турында уйлап та карамый ул. Кая уйласын! Тормышы җайланып, яши генә башлады бит әле ул! Әмма бавырындагы яман шешне җиңәрлек булмый инде. 1956 елның 19 апрелендә Шәфыйка Котдусованың гомере өзелә.

Аның сәхнә тормышы гөлт итеп кабынып, балкып янган йолдыз гомерен хәтерләтә. Ә йолдызлар үзләре янса да, аларның яктылыгы тирә-юньне балкыта. Татар операсы да Шәфыйка Котдусова йолдызы яктылыгында 15 ел яшәп кала. Милли операның иң биек үрләренә күтәрелгән чагы...

Шәфыйка Котдусова әнисе Фатыйма абыстай һәм сеңлесе Нурия белән. 1952 ел.

ИСТӘЛЕКЛӘР

Дилявер Осман, «Йолдыз» кырымтатар әдәби журналының баш мөхәррире, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Кырымның атказанган сәнгать эшлеклесе:
– Танылган җырчы, кабатланмас талант иясе Шәфыйка Котдусова бүген дөньяда «татар» исемен саклап калган, аны яшәткән Кырым һәм Казан арасында татар мәдәниятенең ялкынлы илчесе булып кала. Ул татар дөньясының күгендә мәңге балкып торган бер йолдыз, җырчы һәм шәхес буларак сәнгатебез, тарихыбызда урын алды.
Кырым һәм Казанны, татар дөньясын тоташтыручы, татар җыры, опера сәнгатенә гомерен багышлап, аны зур югарылыкка күтәрә алган Шәфыйка Котдусовага (Рәхимовага) чорның кара көчләре рәхимсез булды, ә замандашлары аны яклый алмады...

Әлфия Айдарская, балерина, Сара Садыйкованың кызы:
– Без тулай торакта яшәгәндә, Шәфыйка Котдусова безнең күршедә торды. Әнием белән бик дуслар иде. Икесе дә югары колоратур сопрано буларак, операларда бергә уйныйлар, бездә әнием белән чәй артында сөйләшеп утыралар, аралашалар иде. Шәфыйка Мәскәүгә киткәч, әнигә язган җылы хатлары дәүләт архивында саклана. Аның Зәйнәп Хәйруллинага, Әхмәт Фәйзигә язган хатлары да архивта бар...

Фагыйлә Тимерова, опера җырчысы, Татарстанның атказанган артисты:
– Без консерваториядә укыганда Шәфыйка Котдусова анда концертмейстер булып эшләде. Аны мин бик тә матур, зәвык белән киенгән хатын-кыз дип беләм. Фортепианода бик әйбәт уйный иде. Шуны белдем: ул консерваториядә вокал бүлегендә дә укыган булган икән...

«...Мин бәхетле. Дөньяда мин юкка яшәмәгәнмен. Сәнгатькә, сөекле халкыма хезмәт иттем. Бик акыллы ике ул үстердем. Сөеп һәм сөекле булып яшәдем. Мин беркемгә дә ачу сакламыйм. Хушыгыз, туганнарым һәм газизләрем».
(Шәфыйка Котдусованың соңгы хаты)

ГҮЗӘЛ ЯХИНА: «ЯҢА ӘСӘРЕМ – КЕШЕЛЕКЛЕЛЕК ТУРЫНДА»

«Сәмәркандка эшелон» – Гүзәл Яхинаның шушы көннәрдә басылып чыккан романы шулай атала. Соңгы берничә ел эчендә ике бестселлер язган автор укучыны бу юлы ни белән гаҗәпләндерер икән? «Татарстан» журналы яңа әсәр турында язучының үзеннән сорашты.

– Гүзәл Шамилевна, яңа романыгыз – Идел буенда 1920–1921 нче еллардагы ачлык турында. Ни өчен шушы теманы сайларга булдыгыз?

– Күпләр өчен әлеге тема нәсел тарихында да, ил тарихында да һаман билгесез булып кала. Артта биш миллион кешене йоткан «караңгы базә» була торып, алга бару мөмкин түгел (1920 нче елларда ачлыктан иза чигеп үлгәннәрнең санын бәяләгәндә, тарихчылар Совет үзәк статистика идарәсенең халык дефициты турында китергән шушы мәгълүматына таяна).

«Сәмәркандка эшелон» – ул 1920 нче еллардагы ачлык турында маҗаралы тарих итеп сөйләнелгән дөреслек. Эвакуация эшелоны начальнигы Деев Казаннан Төркестанга, ач үлемнән коткарыр өчен, биш йөз баланы илтергә боерык ала. Икмәкле Сәмәркандка хәрәкәт иткәндә Деев батырлыкка тиң гамәлләр кылырга тиеш: балаларга ризык, паровозга ягулык, дарулар, сабын табарга, тимер юл кинәт кенә өзелгәч, эшелонны чүлдән алып чыгарга... Мондый структура тылсымлы әкиятне яки антик мифны хәтерләтә, бу хәлләр төп каһарманның җиңүе белән тәмамланыр дигән өметне сүндерми. Психологик яктан бу укучыга эшне – катлаулы, урыны белән фаҗигале материалны «ерып чыгу»ны җиңеләйтә. Минем өчен сюжетның укучыны үз артыннан мавыктыруы, материалның авырлыгыннан өстенрәк булуы мөһим иде. Шуңа күрә каһарманнарымның маҗараларын мавыктыргычрак итеп бирергә тырыштым.

Романдагы вакыйгалар алты атна вакытны колачлый, шул арада эшелон дүрт мең чакрым юл уза һәм бик күп төрле бәндәләргә юлыга. Бу адәмнәр – чекистлар, бандитлар, продармия хезмәткәрләре, тимерьюлчылар, басмачылар – бер-берсен үтерергә әзер булган кан дошманнар. Ләкин ахыр чиктә алар барысы да кеше булып чыга – үлем хәлендәге балаларны коткарырга ярдәм итә. Биш йөз баланың Сәмәркандка барып җитүе ул – эшелон начальнигының гына түгел, ә юлда очраган барлык кешеләрнең казанышы. Хәвефле сәфәрнең ахыр максаты – балалар гомере, ә бу инде очраган һәрбер өлкән кешенең кешелелеге дәрәҗәсенең күрсәткече булып чыга.

«Сәмәркандка эшелон»ны шулай ук совет режимының ике яклылыгы турындагы роман, дип тә әйтә алам. Төп каһарман Деев совет режимының һәм караңгы, һәм якты ягын гәүдәләндерә: ул үтерүче дә, коткаручы да. Дөрес, ихтыярсыздан үтергән ул: аның яшьлеге шундый вәхши елларга туры килгән. Гражданнар сугышында катнашучы буларак, соңыннан продармия солдаты буларак. Коткарырга үз теләге белән алына. Беркемне дә үтермичә, илдәге ачлык белән көрәшергә дип, тимер юлга эшләргә килә. Кырыс ирония: ул коткара торган балалар, шул исәптән аның аркасында да йортсыз-җирсез, ятим калган. Йә сугыш чорында аларның ата-анасын үтергән булырга мөмкин ул, йә халыктан икмәк җыю кампаниясендә ач-ялангач калдырган. Ихтыярсыздан үтерүчегә әйләнгән – крестьяннарны азык-төлек салымын түләмәгән өчен аскан-кискән, ГУЛАГта репрессия сәясәтен тормышка ашырган «деевлар» меңәрләп исәпләнгән.

– Әсәрне язганда кайсы чыганакларга мөрәҗәгать иттегез?

– Тарихчылар хезмәтләре минем өчен «өстән караш» булды. Беренче нәүбәттә, профессор Вячеслав Поляковның «Голод в Поволжье» докторлык диссертациясе. Шулай ук архив документларыннан торган ике зур җыентык та ярдәм итте. Беренчесе «Советская деревня глазами ВЧК–ОГПУ–НКВД» дип атала һәм ЧК хезмәткәрләренең илдәге ачлыкка карашын ачып күрсәтә. Икенчесе – «Голос народа. Письма и отклики рядовых советских граждан о событиях 1918-1932 гг.» җыентыгы – тирә-юньдәге хәлләргә карата крестьяннарның хис-тойгылары. Вазгыятькә карата әлеге ике төрле карашны: ачтан интегүчеләр һәм ачлык нәтиҗәләре белән көрәшүчеләр фикерен чагыштыру кызыклы (кайчагында аяныч та) булды.

Кайбер нәрсәләрне мин шушы чор газеталарыннан алдым – мисал өчен, «Красная Татария»нең 1926 елгы тупланмасын тулысынча өйрәндем. Шулай да иң тетрәндергеч чыганак – Самарада 1922 елда басылган «Книга о голоде» китабы булды. Ачлыктан газапланган авторлар иҗат иткән әдәби-публицистик материаллар (пьесалар, ши-

Фото: Александр Ефремов

гырьләр, хикәяләр) җыентыгы иде ул. Гаҗәеп көчле текстлар – акылдан язарлык дәрәҗәдә, алар әдәби генә дә түгел.

– «Сәмәркандка эшелон» китабы өлкән яшьтәге аудиториягә исәпләнгәнме?

– Бу роман өлкәннәр өчен һәм җитди нәрсәләр турында. Ләкин аны уку үсмерләргә дә кызыклы булыр, дип өметләнәм, чөнки романда маҗаралар сызыгы көчле: персонажлар йә бер эшелон ач бала-чагага азык һәм яңа туган сабыйга сөт эзли, йә вагоннарга рөхсәтсез утырткан сукбай балаларны контролерлардан качыра, йә басмачылардан кача.

Мәхәббәт сюжеты да бар. Йомшак Деевка ярдәмгә балалар комиссары Белая – ирләр холкына ия кырыс хатын куелган. Холкы белән Деевның капма-каршысы. Ул ачлык белән көрәшүдә профессионал, меңләгән кешене үлемнән коткарган. Аның гамәлләре – кешене кызгануыннан түгел, ә белемле булуыннан. Ир-ат образында – хисчәнлек, йомшаклык, эмпатия; хатын-кыз образында коры һөнәрмәндлек, рух көче, катгыйлык гәүдәләнгән. Шушы ике полюс арасында очкын кабынып китә, танышу, беренче үбешүдән башлап аерылышуга хәтле гыйшык хәлләре бәян ителә.

Романда балалар – коллектив персонаж. Күп кенә балаларның характерлары уйлап чыгарылмаган, шул еллардагы мемуарлардан алынган. Мисалга, бер малайның бик озак вакытлар бердәнбер «дусты» булган, кулдан ясаган пәкесенә «береккәнлеге» турындагы хикәят. Яисә бер баланы куркыныч төшләренә кереп эзәрлекли торган килбәтсез зур, уйлап чыгарылган Бет турындагы кыйсса. Яисә малайлар-кызларның «өйләнешеп» уйнавы, «гаилә тормышы»н «коруы» турындагы сюжет. Яки ачлык елны балаларын салкын ызбаларда үләргә калдырып «Юпитерга» китеп барган крестьяннар...

– Романдагы вакыйгалар кайда һәм кайчан җәелеп китә?

– Романымдагы вакыйгалар 1923 елда бара. Китапта соңгы биш елдагы фаҗигале тәҗрибә гомумиләштерелгән. Эшелонда хәрәкәт итүче биш йөз баланың балачагы – ачлык. Ачлык шулай ук «Сәмәрканд эшелоны» романының персонажы, дип әйтергә мөмкин. Поезддагы балаларның милләте бик чуар. Эшелон Нух пәйгамбәр көймәсенә әверелә. Әлеге көймәнең географиясе бик киң – Идел буе һәм казах далаларыннан Арал диңгезе ярларына, Аралдан Кызыл ком чүленә һәм Төркестан тауларына кадәр җәелә.

Ачлыктан үлемне ул чакта беркем дә санамаган, әмма иң зур югалтулар Самара һәм Чиләбе губерналарында, Татарстан һәм Башкортостанда булган. «Хәрби коммунизм» чаралары, азык-төлек терроры һәм тулаем Совет республикасының азык-төлек сәясәтеннән иң зур зыянны шул җирләрдә яшәүче крестьяннар күргән.

– Хәзерге заман әдәби әсәрләренең бик сирәгендә генә стандарт интим күренешләр тасвирланмый кала. Менә әсәрнең синопсисыннан күренгәнчә, «Сәмәркандка эшелон» китабында да баш каһарманнар арасында гыйшык-мыйшык дөрләп кабына. Тик монда сүз дә тирән, чын хисләр турында бармый...

– «Сәмәркандка эшелон»да сурәтләнгән тарихи чорда, ягъни 1920 нче елларда «гаилә» төшенчәсе үзе үк большевикларның коммунистик идеологиясе басымы астында аздан гына чәлпәрәмә килми. Анда инде Россиядә, шул исәптән шәрекъ республикаларында да, Татариядә дә хатын-кызларның эмансипацияләшү процессы кызу тизлектә бара, 1917 елдан безнең илдә хатын-кызлар хокуклары буенча ирләр белән абсолют рәвештә тигезләштерелә. Ә совет идеологиясе әлеге эмансипацияне тырыша-тырыша хуплый, чөнки яшь дәүләткә эшче көчләр кирәк иде – хатын-кызлар станок янына басарга, иген кырларында һәм төзелешләрдә эшләргә – социализм төзүдә ирләр кебек үк актив катнашырга тиеш. Большевиклар төзегән яңа дөнья барлык социаль институтларны, шул исәптән никах һәм җенесләр арасында мөнәсәбәтләрне дә яңача аңлауга китерә. 1920 нче елларда мәхәббәткә алдынгы караш никахлашып яшәүне күздә тотмый, ә киң таралган «бер стакан су теориясе» хәтта яхшылып таныш та булмаган яшь кешеләр арасында сексуаль бәйләнешләрне мөмкин итә. Шуңа күрә, әгәр «Зөләйха күзләрен ача» һәм «Сәмәркандка эшелон» романнарына җентекләп эзләнүчән тарихчылар күзлегеннән карасак, геройлар арасындагы мөнәсәбәтләрдә без бары тик шушы еллардагы тарихи дөреслекнең чагылышын гына күрербез. Һәм Зөләйханың өйдәге кәнизәктән, колдан алып аучы хатын-кызга тикле үткән психологик юлы – шулай ук тарихи дөреслекнең чагылышы ул, ягъни совет хакимиятенең беренче елларында хатын-кызларның актив рәвештә эмансипацияләшүен күрсәтү.

Субъектив, гаять тирән интим «чын мәхәббәт» төшенчәсен мин бүген мәгънәсе бик тә көпшәкләнгән, үзгәргән «гаилә кыйммәтләре» җыелмасы белән бергә аралаштырып карамас идем. Татар хатыны Зөләйханың сыйнфый дошманы рус Иванга мәхәббәте – араларында рәсми теркәлгән никах булмаса да – чын хисләр. Анна Каренинаның Вронскийга гыйшкы кебек. Яисә Аксиньяның Григорий Мелеховка булган хисләре кебек. Яисә классик әдәбиятның антик мифларындагы меңәрләгән геройларныкы кебек үк.

Әлбәттә, хисләр, мөнәсәбәтләр һәм интим күренешләрне тасвирлаганда автор үзенең чама хисенә таяна. Минемчә, үз әсәрләремдә бу темага язганда әдәп кысаларын саклыймдыр кебек.

– Әдәби әсәрләрегез тукымасына илнең совет дәверенә хас вакыйгаларны «үрүегез» сизелә. Язучы буларак, совет тарихының тагын кайсы чорлары белән кызыксынасыз, кайсына багышлап әсәр язар идегез?

– Әйе, өч романымны да: алар тарихи дип тә, тарихи түгел дип тә укылырлык итеп язарга, ягъни конкрет чорны тасвирлаганда вакыт йогынтысына бирелмәслек темаларны ачарга тырыштым. Зур Тарих фонында «кечкенә кеше» портреты килеп чыксын дип түгел, ә Зур Тарихка кеше тарихы үрелсен, геройның шәхси тарихын алга этәрсен, үстерсен, дип яздым. «Зөләйха күзләрен ача» романымда кулаклар белән көрәшү, аларны сөргенгә җибәрү һәм ГУЛАГ системасында хезмәт поселокларының яшәеше хатын-кызның өйдәге колдан ирекле кешегә әверелүен гәүдәләндерә. «Балаларым минем» романымда Идел буе немецлары тарихын һәм азсанлы милләтләргә «халыклар юлбашчысы» Сталинның мөнәсәбәтен гомере буе тарихи процесстан качарга тырышкан, куркуга бирелгән авыл укытучысы карашы аркылы күрсәттем. «Сәмәркандка эшелон»да 1920 нче еллардагы ачлык баш каһарман – «ирексездән палач»ка әверелүченең фаҗигасе белән үрелә, ә исән-имин сакланырга тиешле 500 бала гомере барлык өлкән персонажларның да кешелеклелек дәрәҗәсен бизмәнгә сала.

Әлегә миңа Советлар Союзының беренче дистә еллары кызыклы. Хәзерге заман турында язып булырмы-юкмы – анысын әйтә алмыйм. Шулай да бик язып карыйсы килә.

Әңгәмәдәш: Рузия Сафиуллина



ЙОСЫФ АКЧУРА: ТОРМЫШ СӘХИФӘЛӘРЕ

Автор: Илдус Заһидуллин

Фикерләрен ачыктан-ачык сөйләп йөрүче егетне хәрби училищеның икенче курсында укыганда, Госманлы мәмләкәтен Европача демократик яңарган дәүләткә әйләндерү өчен көрәшүче «Яшь төрекләр» оешмасы белән аралашуда шикләнеп, 45 көнгә кулга алалар. Иң яхшы укучы булуы гына куылудан коткарып кала Йосыф Акчураны.

Күренекле татар интеллектуалы, сәяси төркичелек теориясенә нигез салучы, Төркия президенты Мостафа Кемальнең мәдәният һәм сәясәт буенча киңәшчесе сыйфатында яшь республиканың дөньяви үсеш идеологы булган шәхес ул.

БЕЛЕМ ТУПЛАУ ЕЛЛАРЫ

Йосыф Акчура – мәшһүр фабрикантлар нәселеннән. Беренче булып йон тукыма фабрикасын көйләп җибәргән Сөләйман Акчураның улы Хәсән күренекле Казан бае Габдерәшит Юнысовның Бибикамәрбану исемле кызын икенче хатын итеп ала. Шушы никахтан берничә бала туа, тик 1876 елның 2 ноябрендә Сембер каласында дөньяга килгән Мөхәммәт-Йосыф кына исән кала.

Гаиләгә бер-бер артлы кайгы килә. Хәсән 1879 елның 10 декабрендә кинәт вафат була. 1882 елда, Сембер–Казан юлында аты дулап чанасы капланагач, Бибикамәрбану нерв авыруы ала һәм, табиблар киңәшен тотып, дәваланырга җылы климатлы Ставропольгә бара. Шуннан 1883 елда улы белән Истамбулга күченә. Галимнәр фикеренчә, Бибикамәрбану Төркиягә ире Хәсәннең бурычларына бәйле суд эзәрлекләвеннән качып китә.

Истамбулда 7 яшьлек Йосыф Акчура өчен яңа тормыш башлана. Әнисе Дагыстаннан күченеп килгән Йосыф исемле кумыкка тормышка чыга. Үги этисе улына дини һәм мәктәп тәрбиясе бирергә тырыша. Малай башлангыч мәктәптә, тугыз яшеннән гаскәри урта мәктәптә укый.

1889–1890 елларда 14 яшьлек Йосыф бер елга якын туган илендә яшәп ала. Ул әнисе белән Зөябашта, Сембердә, Уфада, кымыз белән дәвалау үзәге булачак дан алган Дәүләкән авылында, Касыймда, шулай ук Мәкәрҗә ярминкәсе көннәрендә Түбән Новгородта була. Бу сәяхәттән яшүсмер беренче булыр өчен нык эшләү кирәклеген аңлап кайта һәм, бик тырышып, күңел биреп укый башлый.

1892–1896 елларда хәрби училищеда укыган вакытта ул тагын берничә тапкыр туган ягына кайта, Бахчасарайда туктап, туганы Зөһрә апасының гаиләсендә кадерле кунак була, аның ире «Тәрҗеман» газетасы редакторы, Россиядәге төрки халыкларның яңарышы идеологы Исмәгыйль Гаспринский белән якыннан аралаша, соңрак җизнәсен Остазым дип атый.

Нәкъ менә хәрби училищеда укыганда, «Яшь төрекләр» оешмасы белән аралашуда гаепләп, 45 көнгә кулга алалар да аны. Чынлыкта ул бу оешма белән бәйләнмәгән, әмма дәүләтнең әүвәлге шанлы заманнарын кайтару юллары турында уйлаучы фикерле егет була.

1895 елда әнисе вафатыннан соң Йосыф өчен мөстәкыйль тормыш башлана. 1895 елда уку йортын тәмамлагач, өлкән лейтенант дәрәҗәсе алган яшь белгеч штаб хезмәтенә билгеләнә. Ләкин 1897 елда, хөкүмәткә каршы эш алып баруда гаепләнеп, кулга алына һәм Ливиядәге Триполи шәһәре төрмәсенә җибәрелә. Хәрби дәрәҗәсе кире кайтарылып, шәһәрдә йөрү мөмкинлеге тугач, Йосыф ике дусты белән көймәдә Туниска кача, аннан Франциягә килә. 1899-1903 елларда Парижның Сәяси белемнәр ирекле мәктәбендә укый: танылган галимнәрнең лекцияләрен тыңлый, сәясәттән тыш, фәлсәфә, тарих, социология, филология фәннәре белән дә якыннан кызыксына һәм Сорбонна университетының төштән соңгы дәресләренә дә йөри. Студент Йосыф, Госманлы солтаны эзәрлекләвеннән качып, Парижка килеп сыенган «Яшь төрекләр» оешмасы вәкилләре белән дә аралаша.

1902 елда Казаннан Сорбонна университетының хокук факультетына укырга дип Садри Максуди килә. Бу ике татар студенты «Тәрҗеман» газетасының 20 еллык юбилее уңаеннан 27 битлек текст

Фотолар автордан алынды

язып, аны 100 данә күбәйтеп, күренекле шәхесләргә җибәрәләр һәм Бакчасарайда төрки-татар җәмәгать эшлеклеләренең беренче зур мәҗлесен оештыралар. Бәйрәм чарасы кысаларында төрки халыкларның бүгенге хәлəте һәм киләчәге, модернизация шартларында милли мәдәниятне һәм телне саклау һәм үстерү турында җитди сөйләшү була. Садри Максуди соңрак 1903 елгы әлеге мәҗлесне Россиядә төрки халыкларның азатлыгы өчен көрәшнең башлангыч ноктасы дип бәяли.

«ӨЧ ТАРЗЫ СӘЯСӘТ» ХЕЗМӘТЕ

Сәяси белемнәр иректе мәктәбендә Акчура яклаган диплом эше «Госманлы империясенә нигез салучылар тарихы» дип атала. Фәнни хезмәттә дәүләт оешмаларының эшчәнлеген яхшырту тәкъдимнәре берничә принциптан чыгып билгеләнә, шул рәвешле Йосыфның милләт мәсьәләсенә карашы формалаша башлый.

Егет, укуын тәмамлап, 1904 елның мартында Зөябаш авылына кайткач, тирән кризис халәтендә булган Госманлы мәмләкәтенең киләчәге турында «ерактан карап» уйлап, «Өч тарзы сәясәт» («Өч төрле сәясәт») исемле мәшһүр мәкаләсен яза.

Акчура Төркиянең киләчәгендә өч мөмкин булган юлны билгели. Беренчесе – илдә яшәгән башка халыкларны ассимиляцияләп госманлы милләтен төзү. Икенчесе – солтанның дини башлык, хәлиф булуыннан файдаланып, дөнья мөселманнарын бер дәүләткә туплау. Өченчесе – этник факторга корылган төрки сәяси милләте булдыру.

Киләчәктә Шәрыкка багышланган хезмәтләрдә «госманчылык», «исламчылык» һәм «төркичелек» фикер хәрәкәте һәм сәясәте турында сүз чыкканда, яшь татар галиме тәкъдим иткән атамалар кулланыла, ягъни Акчураның бу теоретик хезмәте сәясәт фәне өчен методологик әһәмияткә ия була.

Чынбарлык «төркичелек» («пантюркизм») концепциясенең XX гасыр башында популяр булган «панисламизм», «исламчылык», «бөтендөнья пролетар революциясе», «коммунизм җәмгыяте төзү» һ.б. күпсанлы теорияләр кебек үк, утопия икәнлеге расланды. Биредә галимнең әле традицион җәмгыять кысаларында яшәп яткан төрки халыкларның киләчәктә алгарыш идеологиясе милләтчелеккә корылачак, дигән фикере фәнни әһәмияткә ия.

1904 елда Акчура Казанга күченеп килә һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә тарих, география һәм Госманлы әдәбияты фәннәрен укыта башлый. 1906 елда «Гыйлемнәр һәм тарих» исемле Европа тарих фәне методикасына багышланган хезмәтен бастыра.

Акчураның Россиягә кайтуы рус-япон сугышының кызган, халыкның канәгатьсезлеге нык көчәйгән заманга туры килә. Җәмгыятьне тынычландыру максатында император Николай II 1904 елның 12 декабрендәге указында киң масштабта реформалар уздырылачагы, дини кимсетүгә корылган кануннар юкка чыгарылачагы хакында белдерә.

Яңа иҗтимагый шартларда хокукый яктан төгәл демократик таләпләр куела, башкала түрәләре белән бәхәсләшер дәрәҗәдә белемле шәхесләрләргә ихтыяҗ туа. Шул сәбәпле күбрәк дини хокуклар турында гына сөйләүче татар байлары үз сафларына заманча белемле милләттәшләрен җәлеп итә. Яңа буын әйдәманнары арасында, 1906 елда Садри Максуди Париждан укуын тәмамлап кайтканчы, бердәнбер Европа белемле шәхес Йосыф Акчура була. Ул алдынгы

Йосыф Акчура Исмәгыйль Гаспринский белән Гарзуфта. 1908 ел.

фикерләре һәм көндәлек хезмәте белән татар элитасы арасында тиз арада олы хөрмәт казана.

1905 елда Россия мөселманнарының петиция бирү хәрәкәте нәкъ менә Казанда Габдерәшит Ибраһимов һәм Йосыф Акчура катнашында башлана. Акчура Галимҗан Баруди һәм Әхмәт Хөсәенов белән киңәшкәннән соң, 50–60 кеше чакырылган мәҗлес петиция төзү өчен өч кешедән (Акчура, юрист Сәетгәрәй Алкин һәм мулла Габдулла Апанаев) торган төркем сайлый. 28 гыйнварда шул ук көн тәртибе буенча Әхмәтҗан бай Сәйдәшев өендә 200 кеше катнашында уздырылган мәҗлестән соң, аларга йорт хуҗасы да өстәлә.

Казан депутациясе, Россия мөселманнары арасында беренче булып, Министрлар комитеты рәисе С.Ю. Витте белән очраша. Мөселманнар тарафыннан сайланган мөфти җитәкчелегендә дини-мәдәни автономияне киңәйтү, газета-журналлар бастыру, татар китабын иркенләп сату, шәхси мәктәпләрне һәм мәктәп мәдрәсәләрне һәр җирдә ачу, Төркестанда татарларга кучемсез милеккә ия булу хокукы бирү һ.б. турында гариза бирә. Петиция тексты «Тәрҗеман» (Бакчасарай) һәм «Каспий» (Баку) газетларында басыла һәм киң җәмәгатьчелеккә барып ирешә. Казан депутациясе тагын ике мәртәбә Витте белән очраша. Сәяси памфлет сыман яңгыраган петиция тексты башкаланың «Русь» исемле газетасында дөнья күрә.

С.Ю. Витте руханилар катнашында мәҗлес ясап, көнүзәк мәсьәләләрне тикшереп, «бер нәрсә» әзерләп, хөкүмәткә җиткерү зарурлыгын күрсәтә.

«Йосыф Акчура мирасы һәм заман» Халыкара фәнни конференциясенең шәрәфле кунаклары: Йосыф Акчураның оныгы Хәсән Акчура һәм Исмәгыйль Гаспринский белән Зөһрә Акчурина оныкчыгы Гөлнара Сәитвәниева. Ульяновск.

Бу мәҗлес Мәхкамәи шәргыядә 39 рухани катнашында 1905 елның 10-15 апрелендә уза. Шушы уңайдан Уфа каласында төрле төбәкләрдән 60–70ләп сәүдәгәр, дворян вәкилләре, студентлары җыела. Алар рәсми җыелышларга кертелмиләр, ләкин кичке якта корылтайда катнашучылар белән фикерләшәләр. Зыялыларның һәм байларның бер төркеме – Йосыф Акчура, Абусогуд Әхтәмев, Ибраһим Акчура, Сәетгәрәй Алкин, Мәхмүт Хөсәенев, Мөхәммәтзакир Рәмиев, Мөхәммәтйосыф Дибердиев корылтайга 46 маддәдән торган тәкъдимнәрен җиткерә.

Проектның төп яңалыгы – Мәхкамәи шәргыя каршында 20–30 галимнән һәм җәмәгать эшлеклеләреннән торган һәм елга бер-ике тапкыр җыелачак «Голәмәләр шурасы» оештырудан гыйбарәт була. «Голәмәләр шурасы»ның төп бурычы заман билгеләгән һәм тормыш күрсәткән мөһим мәсьәләләрне шәригатькә нигезләп хәл итү була. Аның карарлары халыкка җиткерелергә һәм руханилар тарафыннан исәпкә алынырга тиешлеге белдерелә. «Голәмәләр шурасы» мәктәп-мәдрәсәләргә реформа уздыру, аларның программаларын, бер яктан, халыкның дини һәм көндәлек тормыш ихтыяҗларын, икенче яктан, рус уку йортлары һәм академияләре дәрәҗәсе җиткерүне күздә тотып эшләү бурычы куела. Шулай ук аңа булачак руханиларга имтихан программалары төзеп, аларны укытуда исәпкә алсыннар дип, мәдрәсәләргә җиткерү һәм мулла-мөәзиннәрнең халык арасында дәрәҗәләрен һәм абруйларын күтәрү өчен тырышу йөкләнә. Бу эшләрнең барысында да Йосыф Акчура актив катнаша.

СӘЯСӘТЧЕ ӘЙДӘМАН

Казанда 1905 елның 28 гыйнварында петиция бирүгә багышланган мәҗлеснең икенче көнендә бер төркем җәмәгать эшлеклесе, Россия мөселманнарының берләшү съездын оештыру өчен, Кырым, Кавказ, Казах, Төркестан әйдәманнарына мөрәҗәгать итәргә карар кыла. Казанда узган шушы мәҗлестән ил мөселманнары арасында үзара элемтә урнаштыру, «Иттифак әл-Мөслимин» партиясен төзү эше башланып китә.

Билгеләнгән вакытка Кырым һәм Баку вәкилләре Санкт-Петербургка килеп җитә алмау сәбәпле, съездны уздыру 1906 елның августына Түбән Новгородтагы Мәкәрҗә ярминкәсе ачылган вакытка билгеләнә.

Либерал рухлы «Иттифак» партиясенең максаты итеп сәяси, икътисади, дини, иҗтимагый өлкәләрдә ил мөселманнарын гамәли эштә берләштерү билгеләнә.

Йосыф Акчураның Истанбул зиратындагы каберe.

Йосыф Акчура, сәясәтче буларак, Дәүләт думасына сайлану һәм анда максатка ирешү өчен фикердәшләр кирәклеген яхшы аңлый һәм конституцион демократлар партиясенең җитәкчелегә белән якынаю юнәлешендә адымнар ясый. Ул кадетлар партиясенең Казандагы комитет әгъзасы буларак, бу партиянең 1906 елның 5–11 гыйнвар көннәрендә Петербургта узган II съездында катнаша һәм аның Үзәк Комитеты әгъзасы итеп тә сайлана. «Иттифак»ның кадетлар белән берләшү шарты дип түбәндәге таләпләрне куя: мөфти җитәкчелегендә мөселман руханиларына тулы үзидарә урнаштыру; туган телдә белем алу; ил күләмендә сайлау хокукы барлык хатын-кызларга бирелгән очракта, аны мөселман хатын-кызларына да тарату һәм шәригать буенча сайлый алсыннар өчен, хосусый кагыйдәләр булдыру.

I Дәүләт думасына сайлаулар игълан ителгәч, хакимият, Акчураны депутатлыкка сайланудан читләштерү өчен, 5 март төнендә нахакка гаепләп кулга ала һәм шәһәрдә вәкилләр сайлау тәмамланганчы 43 көн төрмәгә ябып тота. Йосыф Акчура урынына депутат итеп Сәетгәрәй Алкин сайлана.

Кадетлар һәм иттифакчылар I һәм II Дәүләт думасына сайлаулар чорында бергә хәрәкәт итәләр, бу тактика ике як өчен файдалы хезмәттәшлек итү чарасы була.

Татар либераллары 1905 елның 29 октябрендә Сәетгәрәй Алкин редакторлыгында иҗтимагый-сәяси һәм әдәби «Казан мөхбире» газетасын гамәлгә куя. Чынлыкта аны чыгаручы Йосыф Акчура була, тирән эчтәлекле мәкаләләре белән сәясәтче журналист булып танылa.

1907–1908 елларда Акчура Россиянең төрле төбәкләренә, Көнбатыш Европага һәм Мисырга сәяхәт итә. Аның «Үкенечле 3 июнь вакыйгалары» исемле Россия хакимияте сәясәтен тәнкыйтьләгән хезмәтен (1907) цензор В.Д. Смирнов, «матбугат канунын бозу» дип бәяләп, прокуратурага тапшыргач, автор Кырымда җизнәсенең «Тәрҗеман» газетасы редакциясенә эшкә урнаша. Бирелә газетаның 25 еллык бәйрәмендә чыгыш ясый. Госманлы мәмләкәтендә революция турында хәбәр алгач, вак-төяк эшләрен ашык-пошык тәмамлап, 1908 елның октябрендә Истанбулга китә.

Төркиядә вакытта Акчура Россиядәге милләттәшләре белән элемтәләрне саклый. «Вакыт» газетасының чит илдәге хәбәрчесе сыйфатында күпсанлы мәкаләләр бастыра. 1909 елда берничә айга Петербугка килә, биредә көткән сәяси үсеш күрмәгәч, кире кайтып китә.

1908-1913 елларда Төркиядә төреклеклеккә һәм төркичелеккә корылган «Төрек җәмгыяте түгәрәге» (1908), «Төрек йорты җәмгыяте» (1911), «Төрек учагы җәмгыяте» (1912) һәм «Төрек белем җәмгыяте» (1913) кебек иҗтимагый фәнни-мәдәни оешмаларны нигезләүдә Йосыф Акчура турыдан-туры катнаша, аларның гыйльми эшчәнлеген җәелдерүдә үзәк фигура буларак олы хезмәт куя. «Төрек йорты җәмгыяте»нең матбугат басмасы «Төрек йорты» журналының 1911–1917 елларда алыштыргысыз мөхәррире була.

Акчура Россиядә Гражданнар сугышы барганда, Госманлы дәүләтенең «Кызыл Ай» җәмгыяте вәкиле буларак, 1918 елның 13 гыйнварыннан 1919 елның 10 февраленә кадәр Россиядә яши. Башта Петроград һәм Мәскәүдә, аннары Идел буенда калган төрек әсирләрен тиз арада Ватаннарына кайтуларын оештыру, акчалата һәм азык-төлек белән ярдәм итү өчен, Түбән Новгородта, Казанда, Сембердә, Самарада, Уфада була.

1923 елда оешкан Төркия Республикасында Йосыф Акчураның тормыш юлы махсус өйрәнүне сорый.

КӘГАЗЬ БАШМАКЛЫ АВЫЛ...

Автор: Руфия Фазылова

Кешеләрнең кушаматы булган кебек, авылларның да чын исемнәреннән башка, халык теленә кергән атамалары була. Минем туган авылымны «Кытайлар» дип йөрткәннәр, чөнки халык күп яшәгән. Ә менә Апас районының Урта Балтай авылын «Кәгазь башмаклар» дигәннәр. Җирле халык белән танышканнан соң, аларга ни өчен шундый кушамат тагылганы бик яхшы аңлашыла...

Фото: Лилиана Вәлитова

УРТА БАЛТАЙ

МӘДӘНИЯТЛЕ ТӨБӘК...

Урта Балтай авылына сәяхәтне Мәдәният йортыннан башладык. Ни өчен дигәндә, ул авылның йөзек кашы кебек, капиталь төзекләндерүдән соң балкып тора. Әмма төп хикмәт бинаның үзендә түгел иде, ә кешеләрендә. 2012 елдан бирле авыл китапханәсе каршында «Рәйхан» ансамбле эшләп килә икән. Шунда йөрүче апалар безне көтеп торалар иде. Җырлап каршы алдылар! Киемнәре... Аннан бигрәк мөләем йөзләре! Безнең татар апаларыннан да сөйкемле хатын-кызлар бармы икән?!

«Рәйхан» ансамблен элеккеге китапханәче Рузалия Хисамова оештырган. Утыз ел буе Урта Балтай авылы кешеләрендә матур әдәбиятка, гомумән укуга мәхәббәт тәрбияләгән ул. Бүген исә аның эшен Эльвира Җәббарова дәвам итә.

– «Балкыш» фестивале оешкан мәлләр иде, – дип искә алды Рузалия Хисамова. – Өлкәннәрне җыеп, конкурска әзерләргә кирәк, диделәр. Ә бездә нәрсә, кемне алсаң да, сәхнәгә алып чыгарлык. Җырлыйлар, бииләр, гармунда да уйныйлар. Тик бөтен авылны да алып бару мөмкин түгел, чөнки әллә ничә номер була. Шуннан менә ансамбль оештырыйк, дигән фикергә килдек. Ул заманда әле гармунчы ир-атлар да бар иде. Хәзер бабайларыбыз сәхнәгә чыкмый, олыгайдылар.

Тик рәйханлылар гармунчысыз түгел – Мәрьям апа Гатина ансамбльнең зур бизәге. Гармунда уйный, хатын-кызлар өчен калфаклар чигә, күлмәкләр тегә. Тагын әле иҗатка да якын. Мәрьям апа ансамбльгә

Тугыз ел эчендә «Рәйхан» ансамбле Татарстанда гына түгел, Россиянең күп кенә төбәкләрендә дә чыгыш ясаган.

Эльвира Җәббарова. Казан дәүләт мәдәният университетын тәмамлап, үз һөнәре буенча китапханәче булып эшли.



Раилә белән Рамил Сибгатуллиннар икесе дә Урта Балтайда туган. Кечкенәдән бер-берсе белән аралашып үскән.

Алсу Нуруллина 51 еллык педагогик стажга ия. Ул әле бүген дә Урта Балтай төп белем бирү мәктәбендә укыта.

йөрүче хатын-кызларның иң өлкәне дә икән – җитмеш дүрт яшен тутырган.

Тугыз ел эчендә «Рәйхан» ансамбленең чыгыш ясаган җирләрен, җиңүләрен санап китсәң... Бик күп. Татарстанда гына түгел, Россия төбәкләренә дә барган алар. Бүген дә актив эшлиләр. Авылда, районда буласы берәр чарага әзерләнергә кирәк икән, тиз арада җыелалар.

– Һич яшермим, бу апалар минем таянычым, зур ярдәмчеләрем, – диде авылның китапханәчесе Эльвира Җәббарова. – Алар ялындырып тормый, бер шалтыратуга килеп җитәләр. Без хәтта пандемия чорында да репетицияләрне туктатмадык. Мәдәният йортыбыз капиталь төзекләндерүгә ябылгач, кичләрен репетициягә мәктәпкә йөрдек.

2019 елда Урта Балтай авылы китапханәсе «Авыл җирендә урнашкан иң яхшы китапханә» номинациясендә җиңеп, 100 мең сум грант откан. Һәм шул акчага өстәл-урындыклар алып кайтканнар.

– Безнең китапханә биш авылга хезмәт күрсәтә, чөнки Мәдәният йорты бары Урта Балтайда гына. Калган авылларда зур булмаган клублар, – диде Эльвира Җәббарова. – Өлкәннәр белән генә түгел, балалар белән дә эшлибез. Алар өчен төрле түгәрәкләр оештырабыз. Төрле акцияләрдә катнашабыз...

Сүз уңаеннан, Эльвираның махсус белеме бар – Казан дәүләт мәдәният университетын тәмамлаган, китапханәче булырга укыган.

Авыл хатын-кызлары турында сүз чыккач, шуны әйтәсе килә: алар динле дә. Шул ук ансамбльгә йөрүчеләрнең барысы да намазда.

– Бездә Коръәнне гарәпчә укый белмәүче хатын-кыз юктыр, – диде авылның остабикәсе Мөнирә Гыйззәтуллина. – Мәчет каршындагы мәдрәсәгә йөреп, хатын-кызларыбыз дин сабакларына өйрәнде. Аллага шөкер, мәдәниятле генә түгел, динле дә без. Балалар да дин сабакларын укый.

КИЛЕН КАЙНАНА ТУФРАГЫННАН...

Апас районында өч Балтай бар – Югары Балтай, Түбән Балтай, Урта Балтай авыллары. Соңгысы үзәк булып санала. Гомер-гомергә шулай булган. Бүген Урта Балтайда 387 кеше яши, 214 йорт бар, шуларның утыз икесе ел әйләнәсе ябык тора. Авылда 12 яшь гаилә гомер итә (кырык яшькә кадәрле). Мәктәп яшендәге 55 бала бар. Аңлашылганча, йорт саны әллә ни күп булмаса да, халык саны чагыштырмача аз түгел. Дистәдән артык яшь гаилә яши, балалар саны күп булу сөендерә.

Шундый яшь гаиләләрнең берсе – Сибгатуллиннар белән таныштык. Өч буын бер түбә астында тату гомер итә. Өлкәннәр – Камил абый, Резидә апа, ул белән килен – Рамил, Раилә, оныклар – Әмир, Әнвәр. Килен кайнана туфрагыннан ярала, диләр бит, бу менә нәкъ шул очрак.

Камил абый белән Резидә апа утыз алты ел бергә яши. Гаилә башлыгы гомер буе механизатор булып эшләгән, хуҗабикә исә күп еллар Урта Балтай авылы җирлегендә сәркатип вазыйфасын башкарган. Хәзер дә эшли. Бер ул, бер кыз үстергәннәр. Олы кызлары Ләйсән гаиләсе белән Казанда яши, өч бала тәрбияли. Яшьләр – Рамил белән Раилә икесе дә бередә туган. Кечкенәдән бер-берсе белән аралашып үскәннәр. Аннан очраша башлаганнар.

– 2012 елда никах укыттык, – дип сөйләде Раилә. – Әле мин ул вакытта студент идем. Соңрак туй ясадык. Без башта Казанда яшәдек. Дүрт ел элек, олы улыбыз Әмиргә бер яшь тулгач, авылга күченеп кайттык.

– Мин кыстадым инде, – дип сүзгә кушылды Резидә апа. – Болын кадәр йортта Камил белән икәү торып калдык. Эшләгән кешегә авылда да эш бар бит ул.

Чынлап та, яшь гаилә туган авылларында тиз арада эш таба. Рамил әтисе белән үзләренең гаражында автосервис ача. Махсус җайланмалар сатып алалар. Югары белем алган егет соңрак рәсми рәвештә эшкуар булып – үзмәшгульлек программасы буенча теркәлә.

– Эшсез торганыбыз юк. Ерак авыллардан да киләләр, – ди Рамил.

– Бөтен төр ремонт эшләрен дә башкарасызмы? – дим.

– Әйе, эти техниканы бик яхшы белә. Мин дә һөнәрем буенча инженер. Шулай эти белән киңәшләшеп эшлибез инде.

Рамилнең тормыш иптәше Раилә Урта Балтай төп белем бирү мәктәбендә укытучы икән. Дипломы буенча эшли – информатика, физика укыта.

Сөйләшү барышында иң нечкә кылларны тибрәтергә тырышам – килен-кайнана мөнәсәбәтләре. Резидә апа әле үзе дә яшь, чәчрәп тора дияргә була. Раилә дә үткен, төшеп калганга охшамаган.

– Аш-су бүлмәсенә кайсыгыз хуҗа? – дим.

– Раилә, – дип елмая Резидә апа. – Кулыннан килмәгән эше юк. Бер кулында баласы, бер кулында кәстрүле. Авыл советында эш күп бит, иртән чыгып китәм, кич кайтам. Аларга ышанып тапшырган.

– Без әни белән үпкәләшеп, сүзгә килеп утырмыйбыз, – диде Раилә. – Әйтергә дә куркам, тату яшибез. Башкача булса, бергә тормас та идек. Юктан проблема чыгарып утырмыйбыз. Эш күп булгач, бер-беребезне бик күрмибез дә.

Бу гаиләдә ирләр дә акыллы. Камил абый ипле, тыныч кеше. Рамил исә көләч, елмаеп кына тора. Хатын-кызлар өлгермәгәндә, йорт эшләрендә дә булышалар икән. (Өйдә генә эшлиләр бит).

Сибгатуллиннарның тракторлары да бар. Язын, көзен тыкрык бакчаларга җир эшкәртергә чыгалар. Кыскасы, Резидә апа әйткәнчә, теләгән кешегә авылда да эш табарга була. Алар тапкан.

АБРУЙ

Урта Балтай гомергә зур сала саналган. Ике мәчете, мәдрәсе, атаклы муллалары белән дан тоткан ул. Бирегә ерак авыллардан да килеп укыганнар. Россиядә волостьлар барлыкка килгән заманда (XX гасыр башы), Урта Балтайда да оеша ул. Аның төгәл вакыты да билгеле – 1923 ел.

– Урта Балтайның зурлыгы, мәдәниятле булуы турында тагын бер факт сөйли – 1990 нчы елларга кадәр урта мәктәпкә 17 авылдан килеп укыганнар, – диде 51 ел гомерен Урта Балтай мәктәбенә багышлаган Алсу Нуруллина. – Тирә-як авылларда башлангыч яки сигезьеллык мәктәпләр генә булган. Урта Балтай мәктәбенең абруе зур саналды. Хәер, әле дә шулай. Әлбәттә, балалар саны азрак, алтмышка да тулмый. Элек өчәр параллель класс була иде. Бик кызганыч, яшьләр калмый бит. Күрше авыллардан килүче балалар саны нык кимеде.

Урта Балтай – Советлар Союзы Герое Рем Абзаловның кендек каны тамган җир. Туган авылында урта мәктәпне тәмамлаган кыю егет Бөек Ватан сугышында зур батырлыклар күрсәтә. Украина, Румыния, Болгария, Югославия һәм Венгрия җирләрен азат итүдә катнаша. Татар егете – рота командиры гвардия өлкән лейтенанты Рем Абзалов Дунай елгасын кичүне оештыра. Хәрби бурычын үрнәк дәрәҗәсендә

Баш табиб биредә 26 ел эшли. Казан дәүләт медицина университетының стоматология бүлеген тәмамлап кайткан булган.

Авыр очракларда реанимация ярдәме күрсәтү өчен, махсус аппарат та кайтартылган.

башкарганы, кыюлыгы һәм тәвәккәллеге өчен аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Ул күпсанлы орден-медальләр иясе. Аңа сугыш кырын исән-сау кичеп кайтырга насыйп була. Җирле халык бүген дә Ремлы булулары белән горурлана. Урта Балтай мәктәбе Рем Абзалов исемен йөртә.

Авыл чишмәләргә бай. Хәер, бу якларлагы авылларның күбесенә бәхет елмайган – авылларга терәлеп үк Чирмешән елгасы ага, дистәгә якын чишмә бар. Балтайлылар чишмәләрнең исеме, аларның тарихы турында бик тәмләп сөйләде. Биредә чокырлар да исемле – «Окоп чокырлары», Кызыл яр чокыры», «Поварня чокыры». Соңгысының тарихы үзенчәлекле. Баксаң, ул чокырда әлек җирле халык сумала эреткән. Һәм шул сумаланы бүкәннәргә сылап, юлларга тезгәннәр. Юлны төзекләндерүнең бер ысулы булган бу. Юлларның атамалары да кызыклы. Мисал өчен, урманга илтүчесе – «Хөррият юлы». Халыкка йорт салу өчен урманнан агач алып кайтырга рөхсәт ителгәннән соң, халык сөенечтән шундый атама уйлап чыгарган. Балтайлыларның үз авылларына караган һәр атаманың килеп чыгышын белүләре, теркәп барулары, киләчәк буыннарга тапшырулары мактауга лаек күренеш.

ШӘҺӘР ХАСТАХАНӘЛӘРЕННӘН ЯХШЫРАК!

Урта Балтай мәктәбе белән генә түгел, үзенең дәвалау үзәге белән дә дан тоткан. Хәер, амбулатория үзәге бүген дә бар. Алай гына да түгел, республика программасы нигезендә, аңа капиталь төзекләндерү үткәрелгән. Бүген ул заманча дәвалау үзәгенә әйләнгән. (Казанның күп поликлиникалары аның янында бер хәрабә кебек тоела.)

– Төзекләндерү эшләре 25 миллион сумга төште,- диде Урта Балтай амбулатория үзәгенең баш табибы Айрат Рәхмәтуллин. – Бер якта – көндезге стационар, икенче якта ятып дәвалана торган бүлек урнашкан. Соңгылары өчен өч тапкыр ашату, укол, системалар кую, массаж, барысы да каралган.

Дөрес, амбулаториянең ятып дәвалана торган ягы төзекләндерүдән соң ачылмаган. Әлегә дә баягы, пандемия сәбәпче икән.

– Озакламый ул ягын да ачарбыз, дип ышанам, – диде Айрат Рәхмәтуллин. – Әлегә төгәл көне билгеле түгел. Ә болай көненә утыз-кырык кешегә хезмәт күрсәтәбез, безгә барлыгы унтугыз авыл карый.

Баш табиб биредә егерме алты ел эшли икән. Казан дәүләт медицина университетының стоматология бүлеген тәмамлаган, аннан яңадан терапевт булырга укыган.

– Ул вакытта колхозның көчле чагы иде, – диде табиб. – Колхоз рәисе Мәхмүт Сәләхов мине үзе чакырып кайтарды. 2003 елга кадәр монда участок хастаханәсе иде. Аннан амбулаториягә әйләнде. Мин кайтканда бу бина яңа иде әле, 1993 елда салынган. Ул чакта халык күп, коллектив та зур, гөрләтеп эшләдек.

Коллектив дигәннән, ике ел элек амбулатория ябылгач та, дистәгә якын кеше эшсез калган. Шәфкать туташларының берничәсе Апас район хастаханәсенә йөреп эшли башлаган. Ә кайберләре өйдә тора – мал-туар асрый. Шулай булгач әлеге үзәкнең ачылуын түземсезлек белән көтәләр. Җирле халык дәваланырга зарыкса, шәфкать туташлары эш көтә.

Баш табиб белән яңартылган амбулаторияне карап чыктык. Барысы да заманча – ике кешелек палаталар, күтәрелә, төшә торган караватлар, күннән ясалган матраслар. Аерым бүлмәдә плазмалы телевизорга кадәр бар. Анысы да монысы, авыр очракларда реанимация ярдәме күрсәтү өчен махсус аппарат кайтартылган. Дәваланучының кисәк кенә хәле начарайганда яки ашыгыч ярдәм таләп ителгән очракларда бик кирәкле җайланма.

Казанның күп поликлиникалары аның янында бер хәрабә кебек тоела.

...Урта Балтайны кеше сөйләве буенча гына түгел, якыннан беләм, туган авылыма орынып тора. Без үскәндә теләсә кайсы мәдәни чарада алар беренчелекне бирми иде. Хәзер дә шулай икән. Моның сәбәбен җирле халык аңлатты. Баксаң, әле чабаталы заманнарда ук хатын-кызлар бәйрәмнәргә башмак теккән: күне, тукымасы булмаса, кәгазьдән ясаган. Һәм халык җыелган җирдә чабата өстеннән шул матур башмакны киеп куйганнар. Менә культура каян башланган! Бүген кәгазь башмаклар тарихта калса да, сәнгатькә тартылу, аны аңлау, аңардан тәм табу күрәсең, шул заманнардан ук килә.

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

Алсу Нуруллина, Урта Балтай төп белем бирү мәктәбе укытучысы:

– Урта Балтайның төгәл оешу датасы билгеле түгел. Тик шунысы мәгълүм: ул Явыз Иван Казан ханлыгын алганнан соң оешкан. Халык, чукындырудан качып, тау-таш арасына, куе урман үскән җирләргә килеп урнашкан. Безгә килеп җиткән риваятьләр буенча, авылның исеме Балтай исемле бабай белән бәйле. Бирегә ул өч улын ияртеп килә. Олы улы белән үзе өскә – Югары Балтай урынына урнаша, уртанчысын, кечесен Түбән Балтай җирендә калдыра. Иң яхшы җирләр соңгысында була. Беренче оешканда авыл өстәрәк, тау башында була. Тик анда еланнар күп, җирләр дә бик уңдырышлы булмый. Өстәвенә, ваба авыруы чыга. Шуннан соң кешеләр аскарак, Чирмешән елгасы ярынарак төшеп урнаша. Һәм биредә төпләнеп кала.

«ТАТАРСТАН»НЫҢ ТАТАРСТАН БУЙЛАП СӘЯХӘТЕ

«Татарстан» журналының 100 еллыгына багышланган күргәзмә үзенең республика буйлап сәяхәтен Әлки районыннан башлады. Ул исемлек башында торганга гына да түгел. Әлеге районда журналны укучылар һәм яратучылар күп яшәгәнгә. Биредә «Татарстан» журналын өйләренә яздырып укучылар санының күплеге нәкъ менә шул турыда сөйли.

Базарлы Матакта, ТРның Әлки муниципаль районы Советының V утырышы алдыннан, «Татарстан» журналының 9 гомере» күргәзмәсен ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов карады. Экспозиция белән танышкач һәм журналның йөз елда тугыз тапкыр үзгәргән бөтен исемнәрен – «Вестник Татарского областного комитета РКП (б) », «Спутник агитатора», «Коммунистический путь», «Путь Ильича», «Причал», «Спутник партийного активиста», «Татарстан большевигы», «Татарстан коммунисты», «Татарстан» – кызыксынып атап чыккач, Марат Готыф улы: «Бу журналның тарихы кызыклы, язмышы катлаулы. Ул һәрвакыт республиканың төп басма органы булган. Бүген аңа иҗтимагый-сәяси басма буларак бик кыенга туры килә – аудиториясе бик тар. Әмма мондый журнал кирәк, шунлыктан республика хөкүмәте аңа һәрвакыт хәерхаһлы», – диде.

– Без «Татарстан» журналын яратабыз, ул безнең район тормышы хакында гел дөресен һәм кызыклы итеп яза. Без аны даими укыйбыз, – дип өстәде Әлки районы башлыгы Александр Никошин. – Журналга инде йөз яшь тулуын һәм аның республикабыз кордашы булуын белеп алгач, без редакцияне бик теләп үзебезгә кунакка чакырдык – күргәзмәне карап, районыбыз халкы да республиканың төп журналы тарихындагы кызыклы фактлар белән танышсын әле.

Фото: Александр Ефремов

2021

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

8 мартта Татарстанда Масленица бәйрәмнәре башлана.

2021

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

* Татарстаннан кайнар сәлам! (грузин теленнән тәрҗемә)

Татарстанда 1478 грузин кешесе яши
(2010 елгы халык санын алу нәтиҗәләре буенча).